# *Туган телдә сөйләшәбез*

***4–5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек***

Инновацион технологияләр үзәге
Казан, 2013

**УДК 811.512.145(075.2)**
**ББК 81.632.3я70** **ISBN 978-5-9222-0743-0**
**Х 84**

**Авторлар:**
***Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибулина***

**Рецензентлар:**
Казан шәһәре Совет районының 415 нче номерлы муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире
***Р. Ә. Кадыйрова***
Икътисад, идарә итү һәм хокук институтының Яр Чаллы филиалы доценты
***З. М. Зарипова***

Туган телдә сөйләшәбез: методик әсбап / Ф. В. Хәзрәтова,
З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибулина. – Казан:
Инновацион технологияләр үзәге. – 2013. – 256 б.

Методик әсбапта уртанчылар төркеменә йөрүче балаларның сөйләмен үстерү һәм аларны ана теленә өйрәтүнең методик нигезләре һәм хәзерге технологияләре бирелгән. Әсбапта дүрт-биш яшьлек балаларның сөйләм үсеше һәм Федераль дәүләт таләпләреннән чыгып, аларның сөйләмен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләре ачыклана. Эшчәнлекне оештыру конспектлары Н. Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясендә басылган “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Әлеге әсбап танып белү, коммуникация, матур әдәбият уку, белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балаларның белем бирү өлкәләре эчтәлеген ни дәрәҗәдә үзләштерүләрен ачыклау максатыннан диагностик методикалар бирелә. Методик әсбап мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренә, урта, югары һөнәри белем алучы студентларга, мәктәпкәчә белем бирү сферасында эшләгән мөгаллимнәргә, эти-әниләргә тәкъдим ителә.

***@ с Хәзрәтова Ф. В., Шәрәфетдинова З. Г., Хәбибулина И. Җ.,***
2013 с Инновацион технологияләр үзәге, 2013

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Әлеге әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләм телен үстерү буенча төзелгән “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик комплектның өченче өлеше. Өйрәтү-методик комплект үз эченә методик кулланманы, аудиоязмалар җыентыгын, күрсәтмә материалларны, эш дәфтәрен ала. Бу комплект 2010–2015 елларга Мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм телен үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелә. Комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Сез кулыгызга алган әсбап балалар бакчасында бишенче яше киткән балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә методик кулланма буларак тәкъдим ителә. Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н. Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Методик әсбапта Федераль дәүләт таләпләре буенча танып белү, сөйләм үстерү (коммуникация), матур әдәбият белән таныштыру буенча өч белем бирү өлкәсе карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомум кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерелешле өйрәтү, өйрәтү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ. б. төп педагогик принципларга таянып эшләнде. Гуманлылык принцибын исәпкә алып, белем бирү процессы бала шәхесен ихтирам итүгә һәм психологик якланганлык хисләре булдыруга юнәлдерелә.

Принципларның тагын берсе – үстерелешле өйрәтү принцибы, ягъни өйрәтү нәтиҗәсендә белемнәр үзләштерелеп, күнекмәләр генә формалаштырылып калмый, ә тоемлау, кабул итү, хәтер, игътибар, сөйләм, фикерләү белән бәйләнешле булган барлык танып белү процесслары да, шулай ук ихтыяр һәм эмоцияләр үсеше өчен дә шартлар тудырыла – бала шәхесенең тулысынча үсеше алып барыла.

Соңгы елларда үстерелешле өйрәтү мәсьәләләре балаларның төрле төр эшчәнлеген интеграцияләү белән тыгыз бәйләнештә карала. Бу бигрәк тә оештырылган эшчәнлек төрләренең танып белү, сөйләм телен үстерү (коммуникация) кебек белем бирү өлкәләренә хас. Өйрәтүне "*якындагы үсеш зонасына*" ориентирлашып алып барганда гына, ул үстерешле нәтиҗә бирә (Л. С. Выготский.) Бу очракта, кагыйдә буларак, бала белемнәрне өлкәннәрнең кечкенә генә ярдәме нигезендә үзләштерә. Тәрбияче "*якындагы үсеш зонасының*" баланың яше белән генә түгел, ә индивидуаль үзенчәлекләре белән дә бәйле булуын истә тотарга тиеш. Өйрәтү барышында баланың фикерләвенә зур игътибар бирү сорала.

Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең *сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә.

Балалар белән эшләү процессында *сүзлек эше* зур урын ала. Сүзлек эше – бәйләнешле сөйләм нигезе. Эшчәнлек конспектлары сүзлек эшенең өч бурычын чишә.

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрне атау) сүзлек запасын баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.

3. Сүзлекне активлаштыру.

*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбиячenең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм

сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүз ясалыш ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сулышы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.

*Бәйләнешле сөйләм телен үстерү* сөйләмнең ике формасын – диалоглы һәм монологлы сөйләм үстерүне күздә тота. Диалоглы сөйләмне үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны *матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* – сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру процессында без түбәндәге бурычларны чишәргә тырыштык:

1) дөньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру;

2) әдәби сөйләмне үстерү;

3) эстетик зәвыкны, әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.

Бишенче яше киткән балаларның сөйләм үсешенә характеристика биреп китик. Бу яшьтәге балаларның сөйләм үсешенең төп юнәлеше – бәйләнешле, монологлы сөйләмгә өйрәтү.

Сүз ясалышын үзләштерүдә дә мөһим үзгәрешләр барлыкка килә.

Балаларның сүзлеге сыйфат һәм фигыль сүз төркемнәре хисабына байый. Балалар предметларның кулланылышын, функциональ билгеләрен аера алалар (“туп – уенчык, аның белән уйныйлар”.) Алар капма-каршы мәгънәле сүзләрне сайлап ала башлыйлар, предметларны һәм күренешләрне чагыштыралар, гомумиләштерүче сүзләр кулланалар.

Баланың сөйләм активлыгы арта. Бу яшьтәге балалар бик кызыксынучан булалар. Сүз байлыгы җитәрлек балалар сүзләрне төрле грамматик формаларда һәм бәйләнешләрдә күрсәтәләр, үзләренең фикерләрен катлаулы җөмләләр белән

белдерәләр, сөйләмдә кереш җөмләләр кулланалар, төрле тасвирламалар һәм сюжетлы хикәяләр төзергә өйрәнәләр.

Сөйләм теле бәйләнешле һәм эзлекле була бара, сөйләмнең мәгънә ягын аңлау, җөмләнең синтаксик төзелеше, сөйләм теленең аваз ягы, ягъни бәйләнешле сөйләм телен үстерү өчен кирәк булган осталыклары камилләшә.

4–5 яшьлек балалар бик теләп рифмага тартылалар. Бала сүзләрне рифмага салса да, бу кайчакта аларның мәгънәсе югалуга китерә. Ләкин бу эшне мәгънәсез дип әйтеп булмый, чөнки ул сөйләмнең ишетү үсешенә ярдәм итә, яңгырашы буенча якын сүзләрне сайлау осталыгы формалаша.

Баланы сүз белән таныштыру буенча махсус эш оештыру сүзнең мәгънә һәм аваз ягы турында күзаллау формалаштыруга китерә. Сүз һәрвакыт нинди дә булса предметны, күренешне, сыйфатны белдерә һәм авазлардан тора, яңгырый.

Балалар “сүз”, “аваз” терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлыйлар, сүзгә игътибарлары арта, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табалар, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтәләр.

Шул ук вакытта бу яшьтәге балаларның сөйләмендә кимчелекләр дә очрый. Барлык балалар да чыжылдаучы һәм сонор авазларны дөрес әйтмиләр, кайберләренең интонацион сәнгатьлелеге тиешле дәрәҗәдә түгел.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар практик рәвештә телнең грамматика кагыйдәләрен, морфологик чараларын, сүз ясалышының кайбер ысулларын үзләштерәләр.

Мәктәпкәчә урта яшьтәге балаларның сөйләме тотрыксызлык һәм хәрәкәтчәнлек белән аерыла. Аларны сүзләрнең мәгънә ягы кызыксындыра, ләкин шул ук вакытта сүзнең мәгънәсен һәрвакытта да аңлатып бирә алмыйлар.

Күпчелек мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тасвирлама һәм сюжетлы хикәя төзү осталыгы тиешле дәрәҗәдә түгел. Алар хикәяләрнең структурасында, эзлеклелегендә хата җибәрәләр, җөмләләрне һәм хикәянең аерым өлешләрен бәйли алмыйлар.

Системалы һәм планлы эш алып бару нәтиҗәсендә балаларның сөйләме әкренләп бәйләнешлерәк һәм эзлеклерәк була бара.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә, өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. 4–5 яшьлек балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.

Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә, тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар, истә калдыру максатыннан, аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль. Эшчәнлек төрләрен оештыру Федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга юнәлдерелә: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләре үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә белүчән; кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомум кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен саклый белгән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән; кирәк булган осталык һәм күнекмәләр үзләштергән бала шәхесе тәрбияләү.

4–5 яшьлек балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик принципка нигезләнә. План ел дәверендә “Белем бәйрәме”, “Көз”, “Мин – дөньяның бер кешесе”, “Минем шәһәрем, минем Ватаным”, “Яңа ел бәйрәме”, “Кыш”, “Ватанны саклаучылар көне”, “8 март”, “Халык җәүһәрләре”,

“Яз”, “Җиңү бәйрәме”, “Җәй” кебек темалар үзләштерүне күздә тота.

Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Без, авторлар коллективы, өйрәтү-методик комплектта тәкъдим ителгән материаллар балаларга туган телне өйрәтүдә һәм аларның сөйләм телен үстерүдә тәрбиячеләргә ныклы ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз. Әлеге методик әсбап милли балалар бакчасында эшләүче педагогларга, тәрбиячеләргә, эти-әниләргә, педагогик белем бирү йортларында укучы студентларга адреслана. Алардан киңәшләр, тәкъдимнәр көтеп калабыз.

# ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ ҺӘМ СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ ЮНӘЛЕШЕ БУЕНЧА БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ ТӨРЛӘРЕ

## 1. ТАНЫП БЕЛҮ ӨЛКӘСЕ

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.–10.09.** | **Белем бәйрәме** | Без балалар бакчасында | 1) балаларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыруны дәвам итү; ягымлы сүзләр куллану хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) балаларда дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | Безнең китаплар | 1) балаларда китапка карата кызыксыну формалаштыруны дәвам итү; сыйфат билгеләрен куллану хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) балаларда китапка карата хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Безнең яраткан апабыз | 1) тәрбияче ярдәмчесе һөнәре турында балаларның күзаллауларын формалаштыруны, таныш һөнәрләр атамасын ныгытуны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) балаларда зурлар хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **11.09.–30.09.** | **Көз** | Басуга бару | 1) балаларны транспорт (поезд) һәм аның төп билгеләре (төс, материал) белән таныштыруны дәвам итү; яшелчәләр (кишер, чөгендер) турындагы белемнәрне ныгыту;<br>2) яшелчәләрнең тышкы күренеше, тәме, формасы буенча (кишер, чөгендер) аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү, [у] авазын дөрес әйтүләренә ирешү;<br>3) балаларда табигатькә уңай караш тәрбияләү. |
| | | Куян күчтәнәчләре | 1) балаларның көз, көзге уңыш турындагы күзаллауларын киңәйтү; яшелчәләр (кыяр, суган, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) яшелчәләрне (кыяр, суган, помидор) тышкы күренеше буенча аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |
| | | Көзге яфраклар. Күгәрчен | 1) балаларны көзнең характерлы билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; көзге яфраклар турындагы белемнәрне тирәнәйтү; күгәрченнең тышкы кыяфәте турындагы белемнәрне, хәрәкәтләрен ныгыту, [ш], [г] авазлар әйтелешен активлаштыру; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) балаларда пөхтә эшләү теләге һәм кошлар турында кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **1.10.–20.10.** | **Мин – дөньяның бер кешесе** | Әти, әни һәм мин | 1) балаларның гаиләләре турындагы күзаллауларын киңәйтү;<br>2) балаларның фикерләвен, хәтерен, хәрәкәт активлыгын үстерү;<br>3) балаларда туганлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Мин һәм кешеләр | 1) балаларга кешенең үсеше турында күзаллаулар бирү, төрле яшьтәге һәм җенестәге кешеләрне аерырга өйрәтү; кешеләрнең бер-берсеннән аерылып торуын (яше, җенесе белән генә түгел, ә характер үзенчәлекләре, киеме, шөгыле белән дә аерылуын) аңлату;<br>2) сөйләмнәрен, логик фикерләүләрен үстерү;<br>3) әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | Мин – үзем өчен иң кадерле кеше | 1) балаларда үзләренең уникаль (бердәнбер) һәм кабатланмас шәхес булулары турында күзаллаулар формалаштыру;<br>2) балаларның үзаңнарын үстерү;<br>3) тышкы кыяфәтләренә игътибарлылык тәрбияләү. |
| **21.10.–04.11.** | **Минем шәһәрем, минем Ватаным** | Минем данлыклы шәһәрем | 1) балаларны туган шәһәр белән таныштыруны дәвам итү, шәһәрнең тарихы, Татарстан Республикасы турында белем |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | бирү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалоглы сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда туган шәһәр белән горурлану хисләре, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Минем Туган илем – Рәсәй | 1) балаларда туган ил, аның тарихы, әләм флаг турында күзаллаулар формалаштыру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3) балаларда туган илгә мәхәббәт, төгәллек тәрбияләү. |
| **15.11.–31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Кар кызы, Кар бөртеге бездә кунакта | 1) Яңа ел уңаеннан балаларның тирә-юнь турындагы күзаллауларын киңәйтү, курчак киемнәре белән таныштыруны дәвам итү, төзү детальләрен аеру һәм атауны (куб, пластина, кирпеч, брусок) ныгыту, аларны төзүдә кулланырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, диалогик сөйләмен, төзү материаллары белән эшләү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру, курчакларга карата кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Яңа ел уенчыклары | 1) балаларны Яңа ел бәйрәмен каршыларга әзерләү, чыршы уенчыклары белән таныштыру, пыяладан ясалган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | уенчыкларның, предметларның билгеләрен ачыклау (үтә күренмәле, төсле, шома, салкын, ватылучан);<br>2) балаларның сенсор сәләтләрен һәм кызыксынуын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү. |
| | | Яңа ел килә | 1) балаларда Яңа ел бәйрәме турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сенсор билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерү осталыгын ныгыту;<br>2) балаларның чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләү, диалоглы сөйләмен, сорауларга җөмлә белән җавап бирү осталыгын, хисси тәҗрибәсен, кабул итүләрен үстерү;<br>3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре уяту. |
| | | Киемнең үткәне һәм бүгенгесе | 1) балаларны киемнең билгеләнеше һәм функцияләре белән таныштыру, кием материалы һәм аны куллану ысулы арасындагы бәйләнешне урнаштырырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, диалоглы сөйләмен, кызыксынуын, иҗади сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда зәвык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Хуш киләсең, карлы кыш! | 1) балаларның кыш, Яңа ел турындагы белемнәрен тирәнәйтү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>2) кабул итүне, игътибарны, сүзлекне, бәйләнешле сөйләмне үстерү;<br>3) биремнәрне үтәүгә кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Миләш һәм балан җиләкләре | 1) балаларның Яңа ел турындагы күзаллауларын киңәйтү, үсемлекләрнең җимешләре, аларның табигатьтәге һәм кеше тормышындагы роле белән таныштыру;<br>2) танып белүгә кызыксыну үстерү, сүзлекне баету һәм активлаштыру;<br>3) кошларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| **01.01.–31.01.** | **Кыш** | Кыш билгеләре | 1) балаларның кыш турында белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның күрсәтмә образлы фикерләвен үстерү;<br>3) туган табигатькә мәхәббәт һәм эстетик хисләр тәрбияләү. |
| | | Кар бабай | 1) балаларның кышкы күренешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, геометрик фигураларның – түгәрәкнең, өчпочмакның атамасын ныгыту, детальләрне зурлыгы буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, фикерләвен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | үстерү;<br>3) балаларда уңай эмоциональ халәт булдыру, эстетик хисләр тәрбияләү. |
| | | Җәнлекләр кышка әзерләнә | 1) балаларны җәнлекләрнең кышкы табигатьтә яшәү рәвеше белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның грамматик яктан дөрес сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда тере табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Җәнлекләр кышкы урманда | 1) балаларның кыргый хайваннар турында күзаллауларын формалаштыру; табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) бәйләнешле сөйләм үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>3) хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. |
| **01.02.–23.02.** | **Ватанны саклау-чылар көне** | Без – солдатлар! | 1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру; очкычның (самолёт), вертолётның өлешләрен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; солдат, очучы, диңгезче, очкыч, вертолёт, кораблы сүзләре хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын үстерү;<br>3) балаларда очучы, диңгезче, хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | патриотик хисләр, малайларда көчле, кыю булу теләге тәрбияләү. |
| | | Безнең армия | 1) балаларда илне саклаучы сугышчылар турында күзаллау формалаштыру; “Ватанны саклаучылар” төшенчәсен ачыклау; кайбер хәрби һөнәрләр (диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчысы) белән таныштыру;<br>2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын үстерү;<br>3) хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләре тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Бакчабыз ның балта остасы | 1) балаларны олылар хезмәте белән таныштыруны дәвам итү (балта остасы хезмәте), хезмәт кораллары турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү, хезмәт коралларын классификацияләү осталыгын, игътибарын, олылар хезмәтенә карата кызыксынуын үстерү;<br>3) өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| **24.02.–08.03.** | **8 март** | Музыка җитәкче сендә кунакта | 1) балаларның әниләр бәйрәме, әниләре турындагы белемнәрен киңәйтү; музыка җитәкчесенең done бербөтен образын тудыру; музыка коралларының төп билгеләрен ачыклау;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, диалоглы сөйләм формасын, шигырьләрне сәнгатьле сөйләү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда әниләргә, музыка җитәкчесенә карата ихтирам, хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Әнием турында сөйлим | 1) бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү; әниләр турында тасвирлама төзү осталыгын формалаштыру;<br>2) кабул итүне, хәтерне, игътибарны, сүзлек байлыгын үстерү, сәнгатьлелек чараларын куллануда күнектерү;<br>3) әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **09.03.–20.03.** | **Халык җәүһәрләре** | Савыт-саба | 1) татар авылы көнкүреше белән таныштыру; хәзерге һәм элекке заманда кулланылган савыт-саба турындагы белемнәрне ныгыту;<br>2) кабул итүләрен, фикерләүләрен, хәтерләрен, сүзлек байлыгын үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>3) татар халкының көнкүреш предметларына кызыксыну тәрбияләү. |
| **01.04.–20.04.** | **Яз** | Кар бабай язны эзли | 1) балаларның ел фасыллары, кыш, яз билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнеш турындагы күзаллауларын формалаштыру, “кояш”, “кошлар”, “умырзая чәчәге”, “җир казый”, “орлык чәчә” кебек сүзләр һәм сүзтезмәләр хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын, фикерләвен, хәрәкәт активлыгын үстерү;<br>3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Яз бүләкләре | 1) балаларның яз, аның билгеләре турындагы белемнәрен, “бер”, “күп” төшенчәсен куллануларын ныгыту; бишкә кадәр санарга өйрәтү, “киң”, “тар”, “яңгыравык”, “күңелле”, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | “тыныч тавыш”, “кычкырып” дигән сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнешләрне аңлатуны һәм яз көне башкарыла торган эш турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү; куркынычсызлык кагыйдәләре турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, ишетү сәләтен, кабул итүләрен үстерү;<br>3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык, үзара дуслык хисләре тәрбияләү. |
| | | Яз килә, яз! | 1) балаларның яз, аның айлары, билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; эшчәнлектә кулланган сүзләр хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру; табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнеш турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын, фикерләвен, хәрәкәтен, кабул итүләрен үстерү;<br>3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **21.04.–09.05.** | **Җиңү бәйрәме** | Татарстан байрагы | 1) Татарстан байрагының төсләрен ныгыту, агач һәм тукыманың билгеләрен ачыклау; кәгазь белән эшләү алымнарын камилләштерү; Җиңү көне турында мәгълүмат бирү;<br>2) балаларның сүзлек байлыгын активлаштыру, игътибарын, хәтерен, кабул итүләрен, флагта төсләрне дөрес урнаштыру осталыгын үстерү;<br>3) Татарстан байрагына карата горурлык хисләре, Җиңү бәйрәменә кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Җиңү бәйрәме | 1) балаларның Җиңү көне турындагы күзаллауларын формалаштыру; сугышчыларның батырлыгы турында сөйләү; кайбер хәрби һөнәрләр (диңгезчеләр, танкчылар, очучылар, чик сакчылары) белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотлык, горурлык хисләре тәрбияләү. |
| | | 9 майны каршылап... | 1) балаларның Җиңү көне турындагы күзаллауларын формалаштыруны, хәрби һөнәрләр, аларның баш киемнәре белән таныштыруны дәвам итү; сугышчыларның |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | батырлыгы турында сөйләү, хәрби техника турында белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның диалоглы сөйләмен, конкрет-образлы фикерләвен, игътибарын, кызыксынуын, конструктив осталыкларын үстерү;<br>3) хәрби һөнәрләргә, ветераннарга карата хөрмәт, патриотлык, горурлык хисләре тәрбияләү. |
| **10.05.–31.05.** | **Җәй** | Чәчәкләр | 1) балаларны җәйге табигатьтәге үзгәрешләр, чәчәкләрнең характерлы билгеләре белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) сорауларга тулы җәенке җөмләләр белән җавап бирү осталыгын, логик, образлы фикерләүләрен, хәтерен, игътибарын, вак моториканы үстерү;<br>3) чәчәкләргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Үрдәк бәбкәсе Бак-Бакны тасвирлау | 1) уенчыкны эзлекле тасвирлап, кечкенә хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) бәйләнешле сөйләм телен, кабул итүләрен, игътибарларын үстерү;<br>3) хикәя төзүгә кызыксыну тәрбияләү. |

## *Беренче бүлек.*
# БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ

## Тема: БЕЗ БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА

**Бурычлар:**

1)балаларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыруны дәвам итү, ягымлы сүзләр куллану хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;

2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү;

3) балаларда дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** балаларның кычкырган, шаулаган тавышлары язылган аудиоязма, А4 форматында иллюстрацияләр: балалар аш өстәле артында матур итеп утыралар, балалар калакны дөрес итеп тотканнар, пөхтә итеп ашыйлар, балалар уенчыкны урынына куялар, уенчыкны бер-берсенә бирәләр. Бергә дус уйныйлар.

### Эшчәнлек барышы

Балаларның кычкырган, шаулаган тавышлары язылган аудиоязма яңгырый. Төркемгә Йомшаккай (уенчык кулланырга мөмкин) килеп керә.

Тәрбияче. Балалар, сез берәр нәрсә аңлыйсызмы? Бу нинди тавыш? Безгә кем килгән? *(Йомшаккай.)* Йомшаккай, син нишләп шулкадәр кычкырып сөйләшәсең?

Йомшаккай. Мин һәрвакыт шулай кычкырып сөйләшәм. Ай, мин кая килеп эләктем соң әле?

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккайга ярдәм итик әле, ул кая килде? *(Балалар бакчасына.)* (Балаларны активлаштыру.) Безнең янга килеп кергәч, Йомшаккай нәрсә эшләргә онытты? (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, ул исәнләшергә онытты. Әйдәгез, Йомшаккайны исәнләшергә өйрәтик әле. Йомшаккай, безнең балалар исәнләшә беләләр, алар бакчага килгәч, төркемгә башка кеше керсә, һәрвакыт исәнләшәләр. Балалар, исәнләшеп

күрсәтик әле. *(Исәнмесез, исәнме, Йомшаккай!)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Белмәмеш, син дә җавап бир.

Йомшаккай. Исәнмесез!

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккай безгә кунакка килгән. Ә кунакны чәй белән сыйлыйлар. Йомшаккай, әйдә утыр, чәй эч.

Йомшаккай өстәл артына утыра, ләкин үз-үзен тота белми: урындыкта селкенә, авызын чапылдата.

Тәрбияче. Балалар, Йомшаккай өстәл артында үз-үзен дөрес тотамы? *(Юк.)* (Балаларны активлаштыру.) Өстәл артында үз-үзеңне ничек тотарга кирәк? *(Матур итеп утыралар, ашаганда сөйләшмәскә, авызны чапылдатмаска, ашыкмыйча, ризыкны яхшылап чәйнәргә кирәк.)* (Балаларны активлаштыру.) (Балалар җавап биргәндә, тәрбияче иллюстрацияләр күрсәтә.) Йомшаккай, балаларның киңәшләрен ишеттеңме, исеңдә калдырдыңмы? Булдырдыгыз! Йомшаккай, әйдә уйнап алабыз.

Йомшаккай ашыга, йөгерә, абынып егыла, елый.

Тәрбияче. Балалар, ни булды? Йомшаккай ник елый? *(Ул егылды.)* Йомшаккай, син ашыктың, шуңа егылдың. Балалар, бу хәл башка кабатланмасын өчен, нәрсә эшләргә кирәк, Йомшаккайга сөйлик әле. *(Бүлмәдә йөгермә, тыныч итеп кенә йөр.)* (Балаларны активлаштыру.) Йомшаккай, син исеңдә калдырдыңмы? Кабатла әле. (Йомшаккай кабатлый.) Әйдәгез хәзер бергәләп уйныйк инде.

Йомшаккай уенчыкларны ыргыта, балаларның уенчыкларын тартып ала.

Тәрбияче. Балалар, безнең төркемгә ни булган? Уенчыклар таралып ята. Йомшаккай уенчыкларны урынына куя белми икән. Әйдәгез, аны уенчыклар белән уйнарга өйрәтик. *(Уенчыкны ташлама, һәрвакыт урынына куй. Уенчык белән үзең генә уйнама, иптәшеңә дә бир. Бергә дус уйнарга кирәк.)* (Балалар җавап биргәндә, тәрбияче иллюстрацияләр

күрсәтә.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, Йомшаккай, әйдәгез, уенчыкларны бергәләп урынына куйыйк. Йомшаккай, безнең балалар сине балалар бакчасында үз-үзеңне тоту тәртибенә өйрәттеләр, аларга рәхмәт әйт.

Йомшаккай. Балалар, сез бик зурлар, акыллылар, тәртиплеләр икәнсез, үз-үзеңне тоту кагыйдәләренең барысын да беләсез. Мине дә күп нәрсәгә өйрәттегез: исәнләшергә, өстәл янында үз-үзеңне тотарга, дус уйнарга, рәхмәт әйтергә. Рәхмәт сезгә! Миңа китәргә вакыт, сау булыгыз!

## Тема: БЕЗНЕҢ КИТАПЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларда китапка карата кызыксыну формалаштыруны дәвам итү, сыйфат билгеләрен куллану хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү;

3) балаларда китапка карата хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** өстәлдә төрле кәгазьләр: ак, төсле, калын, юка, пергамент салфетка, сырлы.

### Эшчәнлек барышы

Төркем бүлмәсендә “Китапханә” үзәге оештырылган. Тәрбияче белән балалар бер-берсен сәламлиләр.

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә табышмаклар әйтәм, игътибар белән тыңлагыз:

Юк аягы, юк күзе,
Сөйли, өйрәтә үзе,
Телгә аннан оста юк,
Аннан якын дус та юк. *(Китап.)*

(Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар! Теле юк, үзе аңлата. *(Бу да китап.)* (Балаларны активлаштыру.)

Булдырдыгыз, балалар! Балалар, ә китапны нәрсәдән ясыйлар икән? *(Китапны кәгазьдән ясыйлар.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, балалар! Балалар, өстәл янына килегез әле. Сез монданиләр күрәсез? *(Төрле кәгазьләр.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, монда нинди кәгазьләр бар. *(Ак, төсле, калын, юка, салфетка, сырлы.)* Булдырдыгыз, балалар! Балалар, китаплар нинди кәгазьләрдән ясала икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе балалар, тышлыгы өчен калын, ә битләре өчен юка кәгазьләр кирәк. Балалар, монда бер тартма бар. Ул гади түгел, тылсымлы. Бу “серле тартма”ны ачыйк, анда нәрсә бар икән? Балалар, монда бит китаплар бар икән. Мин сезгә “серле тартмадагы” китапларны күрсәтәм, ә сез аларның нинди китаплар икәнен әйтерсез. *(Бу – юка китап, бу рәсемле, бу – калын һ. б.).* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.)

Балалар, бу “серле тартмада” безгә хат бар. Әйдәгез, бергәләп укыйк: “Китапларны саклап тот! Китап укыганны ярата. Китап – белем чишмәсе. Китапны ертма! һ. б.” (Хәкимҗан Халиковның “Китаплар докторы” шигырен укый).

Әбиләр дә авырый,
Бәбиләр дә авырый.
Салкын тисә аз гына,
Дару кирәк барсына.
Чирли хәтта китап та.
Ник көләсең? Чынлап та
Бите төшә, ертыла,
Ул бит көн дә тотыла,
Тотам шуңа сак кына.
Авырдымы чак кына,
Чирен шундук күрәм мин,
Дәвасын да беләм мин,
Төбе төшсә, төплим мин.
Әйткәнне һич көтмим мин,
Китапларың чирләсә,
Үз кулыңнан килмәсә,

Миңа китер туп-туры
Мин – аларның докторы.

Менә нинди матур киңәшләр биргәннәр безгә. Балалар, сез матур сөйләдегез, акыллы җаваплар бирдегез.

## Тема: БЕЗНЕҢ ЯРАТКАН АПАБЫЗ

**Бурычлар:**

1) тәрбияче ярдәмчесе һөнәре турында балаларның күзаллауларын формалаштыруны, таныш һөнәрләр атамасын ныгытуны дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү;

3) балаларда өлкәннәр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** төрле предметлар сурәтләнгән рәсем яки слайд: 1) кәстрүл, тәмле ризык, газ плитәсе, 2) балалар, уенчык, 3) градусник, шприц, витаминнар, 4) кер юу порошогы, кер юу машинасы, үтүк, 5) тырма, көрәк, себерке; А5 форматында карта-схемалар: а) тәрбияче ярдәмчесе ашарга бүлә, б) идән юа, в) идән себерә, г) савыт-саба юа; туп, себерке, тузан суырткыч, чүпрәк, чиләк.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, бер-беребезгә карап, елмаеп сәламләшик. (Балалар бер-берсенә карап елмаялар, башларын ияләр.) Без бүген сезнең белән һөнәрләр, профессияләр турында сөйләшербез. Нәрсә соң ул һөнәр, профессия? Бергәләп кабатлыйк: профессия, һөнәр, хезмәт. (Балаларны активлаштыру.) Профессия, һөнәр ул – зур кешеләр башкара торган эш, хезмәт. Бар кеше дә хезмәт итә, эшли. Хезмәт кешене көчле, матур итә. Һәрбер эш, хезмәт мөһим. Балалар, безнең балалар бакчасында да төрле һөнәр ияләре бар. Әйдәгез искә төшерик әле, кемнәр алар? *(Тәрбияче, тәрбияче*

*ярдәмчесе, мөдир, шәфкать туташы, пешекче, музыка җитәкчесе һ. б.).* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, булдырдыгыз! Тагын әле безнең бакчада каравылчы, хуҗалык җитәкчесе, өлкән тәрбияче, урам себерүче, кер юучы һөнәрләре бар. Күрәсезме, күпме һөнәр ияләре бар. Һәр һөнәр иясе нинди дә булса предмет белән бәйле. Бу предметларны күреп, кешенең нинди һөнәр белән шөгыльләнгәнен әйтергә мөмкин. Хәзер без сезнең белән "Бу нинди һөнәр иясе?" уенын уйнарбыз. Мин сезгә рәсемнәр күрсәтәм, ә сез андагы предметларны атагыз һәм кайсы һөнәргә туры килүен әйтерсез.

Тәрбияче төрле предмет сурәтләнгән рәсем яки слайд күрсәтә, балалар бу предметларны атыйлар һәм предметка карап, аның нинди һөнәргә караганын әйтәләр.

1. Кәстрүл, тәмле ризык, газ плитәсе. *(Пешекче)*
2. Балалар, уенчык. *(Тәрбияче)*
3. Градусник, шприц, витаминнар. *(Табиб, шәфкать туташы)*
4. Кер юу порошогы, кер юу машинасы, үтүк. *(Кер юучы)*
5. Тырма, көрәк, себерке. *(Урам себерүче)*

Тәрбияче. Балалар, булдырдыгыз! Барлык һөнәрләрне дә дөрес әйттегез. Балалар, без көн саен, бакчага килгәч, Наилә Кәримовна белән очрашабыз. Әйтегез әле, ни өчен ул көн саен бакчага килә икән? *(Наилә Кәримовна балалар бакчасында эшли.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар. Әйдәгез, Нилә Кәримовна һөнәре турында үзе сөйләсен әле.

Тәрбияче ярдәмчесен һөнәре турында сөйләвен үтенәләр.

Тәрбияче ярдәмчесе. Әйе, балалар, мин балалар бакчасында эшлим. Минем эшем бик күп. Балалар, ә сезнең игътибар иткәнегез бармы, мин нәрсәләр эшлим? *(Идән юасыз, савыт-саба юасыз, безгә ашарга бирәсез, киенергә ярдәм итәсез.)* (Балаларны активлаштыру.)

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Әйе, тәрбияче ярдәмчесе көн саен иртәдән кичкә кадәр, армый-талмый,

сезнең өчен тырыша һәм тәрбиячегә булыша, шуңа күрә аны тәрбияче ярдәмчесе дип атыйлар. Бергә кабатлыйк: тәрбияче ярдәмчесе. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, Наилә Кәримовнаның карта-схемалары бар, сез, аларга карап, аның көне буе нәрсә эшләвен әйтә алырсыз.

Балаларга тәрбияче ярдәмчесе эшчәнлеге сурәтләнгән карта-схемалар тәкъдим ителә.

Тәрбияче. Балалар, бу рәсемнәрдә тәрбияче ярдәмчесе нәрсә эшли? (Тәрбияче бер-бер артлы рәсемнәр күрсәтә.) *(Тәрбияче ярдәмчесе ашарга бүлә, идән юа, идән себерә, савыт-саба юа.)* Булдырдыгыз, балалар!

Тәрбияче ярдәмчесе. Әйе, балалар, минем эшем күп, әгәр минем ярдәмчеләрем булмаса, миңа авыр булыр иде. Минем ярдәмчеләрем турында сезнең беләсегез киләме? Мин сезгә табышмаклар әйтәм, җавапларын тапсагыз, минем ярдәмчеләремне белерсез.

Балалар табышмак җавапларын әйткәч, тәрбияче ярдәмчесе шул предметларны балаларга күрсәтә.

Сакалы бар, кашы юк,
Гәүдәсе бар, күзе юк.
Сакалын җирдән сөйри,
Бүлмә эчендә йөри. *(Себерке.)*
Йөри-йөри паластан,
Эшли ул гел уттан.
Ул эшләсә, тузан юк,
Аның да тамагы тук. *(Тузан суырткыч.)*
Шкафны да сөртә ул,
Идәнне дә җитешә. *(Чүпрәк.)*
Аңа су да салалар,
Аңа чүп тә салалар.
Ул комны да, керне дә,
Ни салсаң да күтәрә. *(Чиләк.)*

Булдырдыгыз, балалар! Бу предметлар барысы да миңа төркемне чисталыкта тотарга ярдәм итәләр, үзләре дә тәртип яраталар. Аларны урыннарына алып куйыйк.

Тәрбияче. Балалар, Наилә Кәримовнаның ярдәмчеләрен истә калдырдыгызмы? Әйдәгез уйнап алабыз. Түгәрәккә басыгыз, мин сезгә туп ыргытам һәм предмет исемен атыйм, ә сез аның тәрбияче ярдәмчесенә кирәкме, әллә юкмы икәнен әйтерсез.

1. Көрәк. *(Юк.)*
2. Чүпрәк. *(Әйе, савыт-саба юар өчен, тузан сөртер өчен.)*
3. Себерке. *(Әйе, идән себерергә.)*
4. Җилем перчаткалар. *(Әйе.)*
5. Китап. *(Юк.)*
6. Будильник. *(Юк.)*
7. Тузан суырткыч. *(Әйе, палас чистартырга.)*
8. Сумка. *(Юк.)* һ. б.

Булдырдыгыз, балалар! Наилә Кәримовнаның ярдәмчеләре булса да, аның эше бик күп, без дә аңа ярдәм итәргә тиеш. Булышабызмы? (Балаларның җаваплары.) Балалар, сез уенчыкларыгызны җыеп куйсагыз, идәнне чүпләмәсәгез, ашагач, савыт-сабаларны алып куйсагыз, сезнең ярдәм шул була. Аңа хезмәте өчен зур рәхмәт әйтик (Балаларны активлаштыру.) Балалар, барлык һөнәрләр дә кирәк. Һәр кеше үз эшен яхшы итеп башкарырга тырыша. Без бүген сезнең белән тәрбияче ярдәмчесе хезмәте турында күп нәрсә белдек.

## *Икенче бүлек.*
## КӨЗ

### Тема: БАСУГА БАРУ

**Бурычлар:**

1) балаларны транспорт (поезд) һәм аның төп билгеләре (төс, материал) белән таныштыруны дәвам итү; яшелчәләр (кишер, чөгендер) турындагы белемнәрне ныгыту;

2) яшелчәләрнең (кишер, чөгендер) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү; [у] авазын дөрес әйтүләренә ирешү;

3) балаларда табигатькә уңай караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** паровозы һәм вагоннары төрле төстә булган поезд, басу күренеше, кәгазьдән ясалган кишер һәм чөгендер түтәле, яшелчәләр (кишер, чөгендер).

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче өстәлендә паровозы һәм вагоннары төрле төстә булган поезд тора.

Тәрбияче (поездга күрсәтеп). Балалар, бу нәрсә? *(Поезд.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу поезд. Поездның паровозы һәм вагоннары бар. Әйдәгез, поездны игътибар белән карыйк әле. Бу паровозның нәрсәсе? (Балалар паровозның өлешләрен атыйлар: *торба, тәгәрмәчләр*.) Паровоз нинди төстә? (Балаларны активлаштыру.) Вагоннар нинди төстә? (Тәрбияче балаларны өстәл янына чакыра һәм кулга вагонны алып, аны карарга һәм өлешләрен атарга тәкъдим итә.) Сез ничек уйлыйсыз, безнең поезд кая бара икән? (Балаларның җаваплары.) Кемнең поездда барганы бар? Илдар, син поездда кая бардың? Кем белән? Поезд нинди иде? (Активлаштыру.) Балалар, поездны нинди материалдан ясаганнар? (Балаларны активлаштыру.) Әйе, поездны металлдан ясаганнар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, поездның тәгәрмәчләрен нинди материалдан ясаганнар? (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар поездда баралар. Поезд зур һәм матур. Поездның тәрәзәләре чиста һәм якты. Поезд тиз бара. Балалар, хәзер без дә поездда барырбыз. Мин паровоз булам, сез вагоннар булырсыз.

Балалар, тәрбиячегә тотынып, берсе артына икенчесе басып, поезд кебек баралар.

Алга таба барабыз:
Тик-так-так!
Тик-так-так!
Гөрләп чаба паровоз:
Юл тап-тап,
Юл тап-тап,
Ак төтен артта кала:
Пух-пах-пух!
Пух-пах-пух!
Вагоннар җырлап чаба:
Ах-ах-ух!
Ах-ах-ух!
Сыбызгы яңгырап китә:
Ту-ту-ту!
Ту-ту-ту!
Тавышы еракка җитә:
Уу-уу-уу!
Уу-уу-уу!

Менә килеп тә җиттек. Поезд безне басуга алып килде.

Тәрбияче балаларны басу кебек ясалган урынга алып килә. Анда “кишер”, “чөгендер” өемнәре.

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, тыңлагыз. Җавабын табарга тырышыгыз.

Өсте яшел, асты кызыл,
Җирдә үсә.

Кем белә, бу нәрсә? *(Кишер.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу кишер. (Кишер күрсәтә.) Кишер кайда үскән? *(Кишер басуда үскән.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бергәләп кабатлагыз әле: “Кишер басуда үскән”. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, һәрберегез берәр кишер алыгыз. Кишер нинди төстә? *(Кызгылт сары.)* Әйе, кызгылт сары кишер. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кишерне кулыгыз белән

тотып карагыз әле. Менә шулай. (Тәрбияче үзе күрсәтә.) Ул шомамы? *(Шома.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә хәзер бармакларыгыз белән басып карагыз. Ул йомшакмы яки катымы? *(Каты.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, кишер үзе шома, үзе каты. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйбыз: шома һәм каты кишер. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Кишердән нәрсәләр ясыйлар? *(Сок, салат ясыйлар, пирог пешерәләр, ашка салалар, кәбестә тозлаганда салалар, пылау пешергәндә турыйлар һ. б.)*. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.)

Балалар, бу нәрсә? (Тәрбияче балаларга чөгендер күрсәтә.) Әйе, чөгендер. (Балаларны активлаштыру.) Чөгендер нинди төстә? *(Кызыл.)* Әйе, чөгендер кызыл. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлау.) Чөгендер нинди формада? *(Шар формасында.)* Әйдәгез, кулларыгыз белән шар ясап күрсәтегез әле. (Балалар күрсәтәләр.) Балалар, чөгендер шарга охшаган. Ә тагын нәрсәгә охшаган? (*Түгәрәккә охшаган.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, бармакларыгыз белән чөгендергә басып карагыз әле. Менә шулай. Чөгендер катымы яки йомшакмы? *(Каты.)* (Балаларны активлаштыру.) Чөгендерне кулыгыз белән тотып сыйпап карагыз әле. Чөгендер кытыршымы әллә шомамы? *(Шома.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, чөгендер нинди? *(Чөгендер кызыл, түгәрәк, каты, шома.)* (Балаларны активлаштыру.) Чөгендер кайда үсә? *(Чөгендер басуда үсә.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Чөгендердән нәрсәләр ясыйлар? *(Салат, винегрет ясыйлар, борщ пешерәләр.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, кишер һәм чөгендер – яшелчәләр. Яшелчәләрне язын утырталар, җәй буе аларга су сибәләр, аларны карыйлар. Көз җиткәч, казып алалар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Яшелчәләрне һәрвакыт юып ашарга кирәк. Ә хәзер мин сезне кишер белән сыйлыйм. Ашап карагыз әле, кишернең тәме нинди? *(Баллы, тәмле.)* (Балаларны активлаштыру.) Кишер кетер-кетер киләме? *(Әйе, кишер кетер-кетер килә.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Хәзер бакчага кайтабыз. Бер-берегезгә тотыныгыз. Менә шулай.

## Тема: КУЯН КҮЧТӘНӘЧЛӘРЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның күз, күзгә уңыш турындагы күзаллауларын киңәйтү; яшелчәләр (кыяр, суган, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;

2) яшелчәләрне (кыяр, суган, помидор) тышкы күренеше буенча аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү;

3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык куян, кыяр, суган, помидор, “тылсымлы тартма”, салат ясау өчен савыт, пычак, ашъяулык.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, уң кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең уң кулыгыз! Уң кулыгызга сокланып карагыз! Сул кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең сул кулыгыз! Уң кул бармаклары чиратлап сул кул бармаклары белән исәнләшәләр:

Саумы, кояш!
Саумы, һава!
Саумы, иртә!
Саумы, йомшак җил!
Саумы, Туган ил!

Балалар, бүген бездә кунак бар. Нинди кунак икән? Табышмакка җавап тапсагыз, бик тиз белерсез.

Йөртә ул озын колак,
Үзе гаҗәеп куркак.
Уйланма инде озак,
Нәрсә ул? Йә, уйлап бак.

Нәрсә ул балалар? *(Куян.)* Дөрес, Куян-озынколак. Әйдәгез, куян-озынколак белән исәнләшегез! *(Исәнме, Куян-*

*озынколак!)* (Тәрбияче Куян-озынколак исеменнән исәнләшә.) Исәнмесез, балалар! Балалар, Куян-озынколак үзе белән кәрҗин алып килгән. Карагыз әле, нинди матур кәрҗин! (Күрсәтә: кәрҗин ашъяулык белән капланган.) Аның эчендә нәрсә дә булса бар дип уйлыйсызмы? Куян сезгә яшелчәләр алып килгән. Мин әйткән табышмакларның җавабын белсәгез, кәрҗиндәге яшелчәләрне сезгә күрсәтермен. Балалар, Куян-озынколак нәрсәдер әйтергә тели.

Тәрбияче Куянны янына китерә. Куянны утырта, кәрҗинне өстәлгә куя.

Тәрбияче. Балалар, куян бик оста яшелчә үстерүче. Яз көне ул җирне казыган, тырмалаган, түтәлләр ясаган һәм анда төрле яшелчә орлыклары чәчкән. Җәй буе су сипкән, чүпләрен утаган. Куян, синең тартмада нәрсә бар? Балалар, куян сезгә табышмак әйтергә тели.

Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт.

Кем белә, бу нәрсә? *(Кыяр.)* (Куян кыяр алып күрсәтә.) Куянкай, безнең балалар моның кыяр икәнен барысы да яхшы беләләр. Балалар, кыяр нинди төстә? *(Яшел.)* Әйе, яшел кыяр. (Балаларны активлаштыру.) Кыярның формасы нинди? *(Озынча түгәрәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кыярга бармакларыгыз белән басып карагыз әле, ул йомшакмы яки катымы? *(Каты.)* (Балаларны активлаштыру.) Кыяр нинди, кытыршымы, шомамы? *(Шома.)* Кыярның кытыршысы да була. Менә бу (күрсәтә) кытыршы кыяр. Килегез әле, кытыршы кыярны тотып карагыз әле. (Тәрбияче кулындагы кыярны балалар тотып карыйлар.) Балалар, димәк кыяр шома гына түгел, кытыршы да була. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: кытыршы. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлау.) Балалар, кыярдан нәрсәләр ясыйлар? *(Салат ясыйлар, кыярны тозлыйлар, яшелчә ашы пешергәндә кыяр салалар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, киселгән кыяр белән кул, бит тиресен чистартырга була. Балалар, кыярның исе бармы? Иснәп карагыз

әле! *(Кыяр хуш исле.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Кыярны ашаганда нинди тавыш барлыкка килә? *(Кетер-кетер.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлау.) Куян, синең тартмада тагын нәрсәдер бар бугай әле? Куян, әйдә әйтеп кара әле табышмагыңны.

Җир астында җирән ат,
Аның тиресе җиде кат,
Суясың да турыйсың,
Тураганда елыйсың.

Кем белә, бу нәрсә? *(Суган.)* (Куян суган алып күрсәтә.) Куянкай, безнең балалар аның суган икәнен барысы да яхшы беләләр. Суган нәрсәгә охшаган? (Балаларның җаваплары.) Суган нинди формада? *(Шар формасында.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, суганның кабыгы бар. Менә ул. (Күрсәтә.) Суганның кабыгы нинди төстә? *(Кызгылт көрән.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, мин суганның кабыгын әрчедем. Суганның кабыгын әрчегәндә, суганны тураганда күздән яшь тама. Суган ачы һәм сусыл. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Карагыз, суган нинди төстә? *(Ак, саргылт.)* Әйе, саргылт суган. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, суганга бармакларыгыз белән басып карагыз әле, ул йомшакмы яки катымы? *(Каты.)* (Балаларны активлаштыру.) Суган нинди, кытыршымы, шомамы? *(Шома.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, суганнан нәрсәләр ясыйлар? *(Салатка, ашка салалар, барлык ризыкларга да кушалар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, суган бик файдалы яшелчә. Ул микробларны үтерә. Авырган чакта суган ашарга кушалар. Суганның яшел сабагын ашка, салатка салалар. (Тәрбияче балаларга суганның яшел сабагын күрсәтә.) Балалар, суганның исе бармы? Иснәп карагыз әле! *(Ачы исле.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Суганның ачы исе микробларны үтерә. Менә нинди файдалы суган үстергән безнең куян! Куян-озынколак, синең кәрҗиндә тагын нәрсәдер бар бугай. Күрсәт әле! Күрсәтәм, күрсәтәм! Башта яшелчә турында табышмак әйтәм:

Итләч, йомры, яшелен
Өзеп алдым, яшердем;
Гаҗәпләндем бераздан,
Кояшсыз да кызарган.

Кем әйтә ала, бу нәрсә икән? Әйе, помидор. (Куян помидор күрсәтә.) Помидор нинди төстә? (*Кызыл.*) Әйе, кызыл помидор. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Помидор нинди формада? *(Шар формасында.)* Әйдәгез, кулларыгыз белән шар ясап күрсәтегез әле. (Балалар күрсәтәләр.) Балалар, помидор шарга охшаган. Ә тагын нәрсәгә охшаган? *(Түгәрәккә охшаган.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Алсу, кил әле, помидорга бармакларың белән басып кара әле. Менә шулай. Помидор катымы яки йомшакмы? *(Йомшак.)* (Балаларны активлаштыру.) Дамир, помидорны кулың белән тотып сыйпап кара әле. Помидор нинди? *(Шома.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, куянга әйтеп күрсәтегез әле, помидор нинди? *(Помидор кызыл, түгәрәк, йомшак, шома.)* (Балаларны активлаштыру.) Помидор кайда үсә? *(Помидор яшелчә бакчасында түтәлдә үсә.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Помидордан нәрсә ясыйлар? *(Салат, сок, помидорны тозлыйлар, яшелчә ашы пешергәндә салалар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, кыяр, суган, помидор – яшелчәләр. (Балаларны активлаштыру.) Аларны көз җиткәч җыеп алалар. Балалар, яшелчәләрне һәрвакыт юып ашарга кирәк. Куян-озынколак, әйдә яшелчәләрдән балаларга салат ясыйк. Ярдәмгә Галия апабызны да чакырыйк.

Тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе белән кыяр, суган, помидордан салат ясыйлар. Төш вакытында балаларны шушы салат белән сыйлыйлар.

Тәрбияче. Балалар, сез куянга да бик ошадыгыз. Сорауларга матур һәм дөрес итеп җавап бирдегез. Әйдәгез, балалар, күчтәнәчләре өчен Куян-озынколакка рәхмәт әйтик. (Балаларны активлаштыру.) Куян яшелчәләрне бик тырышып үстергән: су сипкән, чүпләрен утаган. Шуңа күрә яшелчәләр бик тәмле булып өлгергәннәр. Яшелчәләрне яратып ашарга кирәк, аларда

витаминнар күп. Яшелчәләрне ашагач, сез тагын да көчле, сәламәт, акыллы булып үсәрсез, авырмассыз.

## Тема: КӨЗГЕ ЯФРАКЛАР. КҮГӘРЧЕН

**Бурычлар:**

1) балаларны көзнең характерлы билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; көзге яфраклар турындагы белемнәрне тирәнәйтү, күгәрченнең тышкы кыяфәте турындагы белемнәрне, хәрәкәтләрен ныгыту, [ш], [г] авазлар әйтелешен активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлеген үстерү;

3) балаларда пөхтә эшләү теләге һәм кошлар турында кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** көзге пейзаж сурәтләнгән картина, күгәрчен рәсеме, мольберт, ватман, һәр балага җитәрлек санда сары, кызыл, коңгырт төстәге яфраклар, пумалалар, җилем, салфеткалар, “Яфрак бәйрәме” (Р. Еникеева көе, Л. Лерон сүзләре) җырының аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, мине игътибар белән тыңлагыз. Мин сезгә бер табышмак әйтәм.

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана.
Бу кайчак була? *(Көз.)*

Бу табышмакның җавабын кем белде? (Балаларны активлаштыру.) Балалар, җәй үтте, көз җитте. Көзен урамда җылымы әллә салкынмы? *(Салкын.)* (Балаларны активлаштыру.) Урамда салкын булгач, кешеләр дә җылы киемнәрен кияләр.

Көзен кешеләр нәрсә кияләр? *(Свитер, чалбар, ботинкалар, резин итекләр, куртка, башлык, бияләй.)* (Балаларны активлаштыру.) Җылы киемнәр кешеләрне салкыннан саклый. (Тәрбияче көз сурәтләнгән картина элә.) Балалар, бу картинага карагыз әле. Һава торышы турында сез нәрсә әйтер идегез? (Балаларны активлаштыру.) Дөрес әйтәсез, күк йөзендә кара болытлар йөзә. Тиздән бу болытлардан яңгыр явар. Балалар, ни өчен агачлар бер якка авышкан? (Балаларны активлаштыру.) Әйе, җил исә, ул агачларны, куакларны селкетә, шуңа күрә алар бер якка авышалар. Искә төшерегез, җил искәндә нинди тавыш барлыкка килә? *(Ш-ш-ш.)* Дөрес, балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: ш-ш-ш. Җил исә, ул агачтагы яфракларны җиргә коя. Карагыз әле, агач төбендә нихәтле яфрак! Балалар, яфраклар нинди төскә кергән? *(Сары, кызыл, коңгырт.)* (Балаларны активлаштыру.) Көз көне яфракларга җылы кояш нурлары җитми, салкын җил яфракларны ботакларыннан өзеп ала. Яфраклар бөтерелә-бөтерелә җиргә коелалар, агачлар, куаклар ял итәргә җыеналар.

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

(Тәрбияче идәнгә яфраклар коя.) Балалар, хәзер һәрберегез берәр яфрак алыгыз! Яфракларыгызны күрсәтегез әле. Алар нинди төстә? *(Сары, кызыл, коңгырт.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Хәзер үз яфракларыгызны очыртыгыз һәм тотып алыгыз! Яфраклар авырмы, әллә җиңелме? *(Җиңел.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) (Тәрбияче “Яфрак бәйрәме” җырының аудиоязмасын куя.) Без сезнең белән яфраклар булып карыйк әле! Яфраклар агачта яшәгәннәр. (Балалар яфракларын өскә күтәрәләр.) Көз килгән. Көз яфракларны сары, кызыл төскә буяган. Яфраклар тагын да матурайганнар.

Сап-сары яфраклар
Җил искәч очалар.

Бөтерелә-бөтерелә
Җиргә үк төшәләр.

Балалар шигырь текстына туры китереп йөгерәләр, әйләнәләр, чүгәлиләр.

Балалар, сез чын яфраклар шикелле, матур итеп биедегез. Булдырдыгыз, балалар! Тәрбияче мольбертка ватман куя. Балалар, хәзер һәрберегез сары, кызыл, коңгырт яфракларыгызны менә бу ватманга ябыштырыгыз. (Балалар ватманга яфраклар ябыштыралар.) Булдырдыгыз, балалар! Менә нинди матур көзге табигать! Балалар, көз җиткәч, күп кенә кошлар үзләренә җим таба алмыйлар, шуңа күрә алар җылы якка китәләр. Кайбер кошлар салкын кышны безнең якларда үткәрәләр. Шундый кош белән мин сезне таныштырырга телим.

Бер кошка кызыгамын:
Тәпие кызыл аның.
Атлаган саен баш ия –
Гадәте кызык аның.
Гөлдер-гү, гөлдер-гү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?

Бу шигырьдә нинди кош турында сүз бара? *(Күгәрчен.)* (Мольбертка күгәрчен төшкән кечкенә картина куя.) Күгәрченне карыйк әле. Күгәрченнең нәрсәләре бар? *(Башы, гәүдәсе, канатлары, тәпиләре.)* Күгәрченнең башында нәрсәләр бар? (*Күзләре.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Күгәрчен күзләре белән сезгә карап тора. Күгәрченнең башында тагын нәрсә бар? (Томшыгына күрсәтә.) *(Томшык.)* (Балаларны активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, күгәрчен томшыгы белән җим чүпли. Күгәрчен нишли? *(Җим чүпли.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, күгәрчен нәрсә ярата? *(Көнбагыш, ярма, ипи.)* (Балаларны активлаштыру.) Күгәрчен гөрләгәндә нинди тавыш чыгара? *(Гөр-гөр.)* Әйдәгез, балалар, гөр-гөр итеп күгәрченнәрнең ничек итеп көнбагыш

чүпләгәнен күрсәтик. (Балалар “гөр-гөр” тавышы чыгарып, җим чүпләү хәрәкәте ясыйлар.) Балалар, күгәрченнең гәүдәсе бар. Марат, кил әле, күгәрченнең гәүдәсен күрсәт әле. Күгәрченнең гәүдәсендә канатлары бар. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: канатлар. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, күгәрчен ничек оча? Әйдәгез, бергәләп күрсәтик әле. Балалар, күгәрченнең койрыгы бар. Койрыгы аңа очарга ярдәм итә. Балалар, күгәрчен сикерәме әллә йөриме? *(Йөри.)* Аңа йөрергә нәрсәләре ярдәм итә? *(Тәпиләре.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Тәпиләре нинди төстә? *(Кызыл тәпиләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Көзен, кышын күгәрченнәргә җим табу кыенлаша. Шуңа күрә аларны ашатып торырга кирәк. Күгәрченнәр безнең участокка киләләр. Балалар, бүген саф һавага чыккач, без аларны көнбагыш белән сыйларбыз.

## *Өченче бүлек.*
## МИН ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ

### Тема: ӘТИ, ӘНИ ҺӘМ МИН

**Бурычлар:**

1) балаларның гаиләләре турындагы күзаллауларын киңәйтү;

2) балаларның фикерләвен, хәтерен, хәрәкәт активлыгын үстерү;

3) балаларда туганлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар**: балаларның гаилә әгъзалары белән төшкән фоторәсемнәре, А5 форматында парлы хайваннар һәм аларның балалары аерым сурәтләнгән рәсемнәр, ябыштырылган карточкалар, һәр балага көзге, әти, әни һәм бала итеп киендерелгән курчаклар яки рәсемнәр.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, менә бу фоторәсемгә карагыз әле (Тәрбияче гаилә фотолары күрсәтә.) Сез бу фоторәсемнәрдә сурәтләнгән кешеләрне таныйсызмы? (Балалар аларда әти-әниләре, туганнары сурәтләнгәнен әйтәләр.) Бик дөрес, балалар, болар сезнең гаилә белән төшкән фоторәсемнәрегез. Сезнең һәрберегезнең үз гаиләсе бар. Сезнең гаиләгездә кемнәр яши? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, җәнлекләрнең дә гаиләләре бар. Анда да әти-әниләре үз балалары турында кайгырталар: аларны ашаталар, алар белән уйныйлар. Җәнлекләрнең балалары яшәү шартларына җайлашсын өчен, аларны төрле гадәтләргә өйрәтәләр. (Балаларны активлаштыру.) Ә сезнең әти-әниләрегез сезнең турыда ничек кайгырталар? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, һәрбер гаиләдә яшәүчеләр бер-берсен яраталар, хөрмәт итәләр, бер-берсе белән ягымлы сөйләшәләр. Һәр әти-әни үз баласын сәламәт, акыллы, тәрбияле итеп үстерергә тырыша.

Балалар янына Йомшаккай йөгереп керә, үзе елый.

Йомшаккай *(елап)*. Булышыгыз! Коткарыгыз, коткарыгыз!

Тәрбияче. Исәнме, Йомшаккай! Тынычлан. Аңлат әле, нәрсә булды?

Йомшаккай. Җәнлекләрнең балалары әти-әниләрен югалтканнар, алар елыйлар, әти-әниләрен күрәселәре килә. Ә мин буталып беттем, аларга булыша алмыйм.

Тәрбияче. Кайгырма, Йомшаккай. Без сиңа балалар белән ярдәм итәрбез. Балалар, Йомшаккайга булышабызмы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Йомшаккай, җәнлекләрнең балалары үзләре кайда соң?

Йомшаккай. Мин аларны үзем белән алып килә алмадым. Бары тик фотосурәтләрен генә алып килә алдым. Менә! (Йомшаккай җәнлекләрнең әти-әниләре һәм балалары аерым төшерелгән фотосурәтләр яки рәсемнәр ябыштырылган карточкалар күрсәтә.)

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез уйнап алыйк әле.

Тәрбияче балалар белән “Җәнлекләрнең балаларына гаиләләрен табарга ярдәм ит” хәрәкәтле уенын тәкъдим итә. Балаларга карточкалар таратыла, балалар бүлмә буенча таралып йөгерәләр, “Җәнлек балалары!” сигналы буенча үз гаиләләрен табалар.

Йомшаккай. Рәхмәт сезгә, балалар! Мин хәзер җәнлекләрнең балаларына ярдәм итә алам.

Тәрбияче. Йомшаккай, син әти-әни һәм бала арасында нинди аерма барлыгын әйтә аласыңмы?

Йомшаккай. Юк, белмим. Белсәм, җәнлек балаларына үзем генә ярдәм иткән булыр идем.

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, тагын уйнап алыйк.

“Охшашлыгын һәм аермасын тап” дигән уенны оештыра. Әни, әти, бала төшерелгән сурәтләр яки әти, әни, бала итеп киендерелгән курчаклар күрсәтә. Балалар карыйлар һәм аларның нәрсә белән бер-берсенә охшаган булуы, нәрсәләре белән аерылып торуы турында сөйлиләр.

Йомшаккай. Балалар, мин бик күп әйберләр белдем, рәхмәт! Мин бик ашыгам. Ярдәм итүегез өчен мин сезгә кечкенә көзгеләр таратам (тарата.) Очрашканга кадәр, дусларым, сау булыгыз!

Тәрбияче. Нинди матур көзгеләр! Хәзер һәрберегез көзгегә карагыз. Сез нәрсәләр күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Башларыгызны күрсәтегез әле. (Балаларны активлаштыру.) Башыгызда нәрсәләр бар? *(Чәч, маңгай, күзләр, борын, авыз, колаклар.)* (Балаларны активлаштыру.) (Шул рәвешле балалар гәүдә өлешләрен әйтеп чыгалар.) Балалар, сез гәүдәгезнең нинди өлешләрдән торуын күрдегез. Бу өлешләр һәрберегездә дә бар,

ләкин сез, бер-берегездән бик нык аерылып торасыз. Балалар, сез биремнәрне бик тырышып үтәдегез, Йомшаккайга булыштыгыз. Ә иң мөһиме, гәүдәгезнең нинди өлешләрдән торуын белдегез һәм гаилә турында тагын да күбрәк белемнәр алдыгыз.

## Тема: МИН ҺӘМ КЕШЕЛӘР

**Бурычлар:**

1) балаларга кешенең үсеше турында күзаллаулар бирү, төрле яшьтәге һәм җенестәге кешеләрне аерырга өйрәтү; кешеләрнең бер-берсеннән аерылып торуын (яше, җенесе белән генә түгел, ә характер үзенчәлекләре, киеме, шөгыле белән дә аерылуын) аңлату;

2) сөйләмнәрен, логик фикерләүләрен үстерү;

3) әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** магнит такта, А4 форматында төрле яшьтәге кешеләр, балалар сурәтләнгән карточкалар, кешеләрнең кайсы җенескә каравын (малай, кыз), тышкы кыяфәтен (күзләр, борын, иреннәр, чәчләренең төсе һәм озынлыгы, өс киеме, аяк киеме) күрсәтә торган модельләр, “тормыш чылбырын” аңлату өчен А4 форматында яңа туган бала, мәктәпкәчә яшьтәге, укучы бала, олы кеше (ир-ат яки хатын-кыз), өлкән кеше (әби, бабай) рәсеме, “тылсымлы сандык” предметлары (шалтыравык, уенчык, укучы сумкасы, чүкеч, күзлек, төрле төстәге парлы лենталар.

### Эшчәнлек барышы

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, ишек шакыйлар, кем килгән икән?

Тәрбияче ишекне барып ача. Бүлмәгә Белмәмеш (курчак) килеп керә, ул кулына конверт тоткан.

Белмәмеш. Исәнмесез, балалар! *(Исәнме, Белмәмеш.)*

Тәрбияче. Балалар, Белмәмеш ниндидер йомыш белән килгән. Белмәмеш мәктәпкә йөри. Ул – укучы. (Балаларны активлаштыру.) Укытучы апалары өй эше биргән. Белмәмешкә кешеләр турында бар нәрсәне өйрәнеп, шул турыда мәктәптә сөйләргә кирәк. Ә ул бернәрсә дә белми икән. Белмәмешкә өй эшләрен эшләргә булышабызмы? (Балаларның җаваплары.) Белмәмеш, син урындыкка утыр да, балаларны күзәтеп тор. Балалар, Белмәмешнең конвертында нәрсә бар икән? Карыйк әле.

Тәрбияче конвертны ача, аннан кешеләрнең төрле сурәтләрен ала: төрле яшьтәге, төрле милләт балалары, төрле олы кешеләр сурәтләнгән рәсемнәр.

Тәрбияче. Балалар, бу рәсемнәрдә сез кемнәрне күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Бер сүз белән аларны ничек атарга була? *(Кешеләр.)* Әйе, балалар, кешеләр. Ни өчен безнең барыбызны да бертөрле итеп, бер сүз белән “кешеләр” дип атыйлар? Кешеләр бер-берсенә нәрсә белән охшаганнар? *(Кешеләрнең гәүдәсе, башы, ике кулы, йөрер өчен ике аягы бар; алар сөйләшәләр, уйныйлар, эшлиләр, мәктәптә укыйлар, балалар бакчасына йөриләр, ашыйлар, киемнәр кияләр, укый, яза беләләр, җырлыйлар, бииләр һ. б.)*. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, барлык кешеләр дә бертөрлеме? *(Юк, кешеләр бер-берсеннән аерылып тора.)* (Балаларны активлаштыру.) Бик кызык әле бу. Кешеләр нәрсәләре белән бер-берсеннән аерылып торалар икән?

Бер-бер артлы җенесләре (кыз-малай, хатын-кыз-ир-ат, әби-бабай), тышкы кыяфәтләре белән аерылып торган кеше гәүдәсе өлешләренең моделен күрсәтә. Балалар, модельләргә карап төрле сыйфатларны атыйлар. Тәрбияче балаларга уен-күнегү тәкъдим итә, мәсәлән, малайлар (кызлар) кул чабыгыз, сары чәчле балалар аяк белән тыпырдагыз, кемнең киемендә кызыл төс бар, барыгыз да басыгыз һ. б.

Т ә р б и я ч е. Хәзер, әйдәгез, кайсыгыз игътибарлырак икән, карыйк әле. Һәрберегез модельләрне алыгыз да үзегез турында сөйләгез.

Бала “чәч” карточка-моделен ала һәм сөйли: “Минем чәчем кара”, “алар озын” һ. б.

Т ә р б и я ч е. Балалар, бар кеше дә бертөрле булса, нәрсә булыр иде икән? *(Балалар үз әти-әниләрен, әби-бабайларын, ә әти-әниләр балаларын танымаслар, тапмаслар иде.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, шулай да бертөрле кешеләр була, аларны “игезәкләр” дип атыйлар. Безнең төркемдә дә Булат белән Азат – игезәкләр. (Әгәр төркемдә игезәкләр булмаса, башка төркемнән балаларны чакырырга һәм чагыштырырга мөмкин.) Алар нәрсәләре белән охшаганнар? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, әйдәгез бер уен уйнап алыйк әле.

“Үзең турында сөйлә” уенын уйныйлар. Барлык балалар да түгәрәккә басалар, музыка уйнаганда, тупны чиратлап бер-берсенә тапшыралар. Музыка туктаганда, туп кемдә калса, шул үзе турында сөйли. Мәсәлән, “Мин рәсем ясарга яратам”, “Мин биим”, “Минем күзләрем зәңгәр” һ. б. Уен берничә тапкыр кабатлана

Т ә р б и я ч е. Балалар, Белмәмешнең конвертында тагын ниндидер картинкалар бар. (Тәрбияче конверттан кешенең “тормыш чылбырын” сурәтләүче портретлар ала.) Балалар, әйдәгез, бу рәсемнәрдән кешенең “тормыш чылбырын” төзик. Карагыз әле, кеше яше белән ничек үзгәрә. (Тәрбияче картинкаларны күрсәтә.) Кеше тормышының башлангычын кайсы рәсемнән белеп була, кайсы рәсемдә яңа туган бала сурәтләнгән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, дөрес, бу – яңа туган бала. Бала азрак үскән – кайсы рәсемне куябыз? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, бу – мәктәпкәчә яшьтәге бала, менә сезнең кебек. Сез дә балалар бакчасына йөрисез, сезне дә мәктәпкәчә яшьтәге бала дип әйтергә була. Ә

аннан соң кайсы рәсемне куяр идегез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, укучы бала рәсеме куябыз. Менә укучы бала үсеп җитә, ул зур кеше була. Укучы баладан соң нинди рәсем куярсыз? *(Олы кеше рәсеме.)* (Балаларны активлаштыру.) Олы кеше, яши-яши, бабайга яки әбигә әйләнә. Әйдәгез, бабай рәсемен куйыйк. Балалар, менә күрәсезме, кешенең тормыш юлы үзе бер "тормыш чылбырын" хәтерләтә. Менә шушы "тормыш чылбырында" үзегезне күрсәтегез әле. (Тәрбияче берничә баланы чакыра, алар күрсәтәләр.) Булдырдыгыз! Бик яхшы! Безнең төркемдә ничә бала бар? Балалар күпме? *(Күп.)* Әйе, балалар күп. Ә балалар кемнәр алар? *(Алар – кечкенә кешеләр.)* Дөрес, сез барыгыз да – малайлар да, кызлар да – кешеләр, ләкин сез әле кечкенә. Сез дә зур булып үсәрсез, мәктәпкә баргач, укучы булырсыз. Мәктәпне тәмамлагач, зур кешеләр булып, үзегезнең гаиләгезне корырсыз. Яши-яши, әбиләр, бабайлар да булырсыз. Балалар, "Кемгә нәрсә кирәк?" уенын уйнап алыйк. Минем "тылсымлы сандыгым" бар, аның эчендә төрле предметлар. Предметларны игътибар белән карап, яңа туган балага, малайга, ир кешегә, бабайга нәрсә кирәк булуын әйтегез.

Тәрбияче шалтыравык, уенчык (курчак яки машина), укучы сумкасы, чүкеч, күзлек рәсемнәрен күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, әйтегез әле, балалар олы кешеләрдән нәрсә белән аерылалар? *(Балалар уйныйлар, укыйлар, балалар бакчасына, мәктәпкә йөриләр, ә зур кешеләр эшкә йөриләр, акча эшлиләр, балаларын тәрбиялиләр, карыйлар, әниләр ашарга пешерәләр, әтиләр өйдә ремонт эшләре белән шөгыльләнәләр һ. б.).* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар уйнарга яраталар, без дә уйныйк әле.

Тәрбияче "Парыңны тап" уенын оештыра. Балаларга төрле төстәге тасмалар таратыла, күңелле музыка уйнатыла, балалар бүлмә буйлап йөриләр. Музыка туктагач, тасмаларының төсләре туры килгән малай һәм кыз парлашып басалар.

Тәрбияче. Бик күңелле итеп уйнадыгыз. Булдырдыгыз! Белмәмеш тә сезгә рәхмәт әйтә. Белмәмеш малайлар һәм кызлар, зурлар һәм балалар, ир-атлар һәм хатын-кызлар, әбиләр һәм бабайлар, яңа туган балалар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар, укучылар барлыгын аңлады. Аларның барысын да “кешеләр” дип атыйлар. Мин сезнең яхшы кешеләр булып үсүегезне, башка кешеләрне хөрмәт итүегезне, яратуыгызны телим!

## Тема: МИН – ҮЗЕМ ӨЧЕН ИҢ КАДЕРЛЕ КЕШЕ

**Бурычлар:**

1) балаларда үзләренең уникаль (бердәнбер) һәм кабатланмас шәхес булулары турында күзаллаулар формалаштыру;

2) балаларның үзаңнарын үстерү;

3) тышкы кыяфәтләренә игътибарлылык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Белмәмеш (курчак), балалар санынча көзгеләр һәм балалар гәүдәсенең контурлы сурәте (трафаретлар), төсле карандашлар.

### Эшчәнлек барышы

Балалар янына чәчләре тузгыган, җыйнаксыз Белмәмеш килеп керә.

Белмәмеш. Исәнмесез, балалар. Минем сезгә кунакка киләсем килде! Мин бик ашыктым!

Тәрбияче. Белмәмеш, нигә син шулай киенеп килдең?

Белмәмеш. Мин бик тырыштым, матур итеп киендем. Киемнәремне үтүкләдем, галстук та тактым.

Тәрбияче. Белмәмеш, син чыгып киткәндә үзеңне көзгедән карадыңмы?

Белмәмеш. Карадым, карадым.

Тәрбияче. Белмәмеш, әгәр дә син үзеңне көзгедән караган булсаң, тузган чәчләр белән, болай җыйнаксыз киенеп

килмәс идең. Балалар, көзге нәрсә өчен кирәк? (Балаларның җаваплары.) Белмәмеш, көзгегә карап үзеңне тәртипкә китер әле! (Белмәмеш көзгегә карый, киемнәрен төзәтә.) Балалар, сезнең дә үзегезне көзгедән карыйсыгыз киләме? (Балалар үзләрен көзгедән карыйлар.) Алсу, син көзгедән нәрсә күрәсең? *(Үземне күрәм.)* Дөрес, Алсу, син бу җир йөзендә үзеңә иң кадерле кеше. Марат, ә син көзгедән нәрсә күрәсең? *(Үземне күрәм.)* Марат, син дә бу җир йөзендә үзеңә иң кадерле кеше. (Тәрбияче чиратлап һәр балага мөрәҗәгать итә.) Бик яхшы! Балалар, мин дә үзем өчен бик кадерле. Сез дә минем өчен бик кадерле. Мин сезне бик яратам. Балалар, һәрберегез үзегезне тагын бер кат көзгедән карагыз. Авызыгызга, борыныгызга, күзләрегезгә игътибар итегез. Гүзәл, син нинди? Син үзеңнең авызыңны, борыныңны, күзләреңне нинди итеп күрәсең? (Тәрбияче башка балаларга да шушы ук сорауны бирә.) Алсу, син башкаларга охшагансыңмы? Синең йөзең башкаларның йөзеннән нәрсә белән аерыла? *(Чәчнең, күзләрнең төсе, борынның, иреннәрнең формасы.)* Дөрес, балалар, һәрберегезнең чәчләренең, күзләренең төсе, борын һәм иреннәр формасы башкаларныкыннан аерылып тора. Сезнең кайсыгыз турында ул почык (кечкенә) борынлы дип әйтеп була? (Балаларның җаваплары.) Кемнең чәче сары төстә? (Балаларның җаваплары.) Кемнең чәчләре кара төстә? Кемнең күзләре зәңгәр? (Балаларның җаваплары.) Ә кем коңгырт-кара күзле? (Балалар түгәрәккә, ә Белмәмеш түгәрәк уртасына баса.) Балалар, Белмәмеш белән уйныйк әле.

Белмәмеш. Кемнең күзләре коңгырт-кара, шулар түгәрәк эченә керәләр. Кемнең чәче үрелгән, шул балалар түгәрәк эченә керәләр. Хәзер сары чәчле балалар түгәрәк эченә басалар. Чәче кыска булган балалар түгәрәк эченә керәләр.

Тәрбияче. Балалар, мин сезне бик яратам, сез минем өчен бик якын. Малайлар кыюлар, көчлеләр, ә кызлар нәфисләр, ягымлылар. Карагыз әле, безнең Алсу ничек матур итеп елмая. Маратның нинди ярдәмчел икәнлеген искә төшерегез. Әмир чын дус була белә (һ. б). Балалар, мин сезгә трафаретлар бирәм. Трафаретларга рәсем ясарсыз. Рәсем “Үзеңне бизә” дип

атала. Сез үзегезне нинди итеп күрергә телисез, шулай итеп рәсемгә төшерегез. (Балалар трафаретларга рәсем ясыйлар. Бизәлгән трафаретларны балалар бергәләп карыйлар. Рәсемне кем ясаганын әйтергә тырышалар.) Балалар, рәсемнәрегезне өегездә стенага караватөстенә элеп куя аласыз. Иртән йокыдан уянгач, шушы рәсемгә карап, үзегезне сәламләгез, үзегезгә сәламәтлек, шатлык, яхшылык теләгез. Булдырдыгыз! Үзегезне һәрвакыт яратыгыз! Үзегезне беркайчан да онытмагыз!

## *Дүртенче бүлек.*
## МИНЕМ ШӘҺӘРЕМ, МИНЕМ ВАТАНЫМ

### Тема: МИНЕМ ДАНЛЫКЛЫ ШӘҺӘРЕМ

**Бурычлар:**

1) балаларны туган шәһәр белән таныштыруны дәвам итү; шәһәрнең тарихы, Татарстан Республикасы турында белем бирү;

2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалоглы сөйләмен үстерү;

3) балаларда туган шәһәр белән горурлану хисләре, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** шәһәр турында матур көй, мольберт, шәһәр күренеше сурәтләнгән рәсем, “Lego” төзү материаллары.

### Эшчәнлек барышы

Балалар алдында шәһәр сурәтләнгән рәсем.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле бу рәсемгә. Рәсемдә сез нәрсә күрәсез? *(Йортлар, урам, автобус, кешеләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу рәсемдә безнең шәһәр сурәтләнгән. Безнең шәһәрнең исеме ничек? (*Яр Чаллы*.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, без Яр Чаллы шәһәрендә яшибез. Яр Чаллы – матур шәһәр, шәһәрдә биек

йортлар, киң урамнар, парк-скверлар күп. Безнең шәһәребез Татарстан Республикасында урнашкан. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Татарстан Республикасында шәһәрләр күп: Казан, Яр Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Бөгелмә, Әлмәт, Минзәлә һ. б. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) (Ишек шакыган тавыш ишетелә.) Балалар, кем икән ул?

Тәрбияче ишекне ача, хат ташучы керә.

Хат ташучы. Исәнмесез, минем нәни дусларым! *(Исәнмесез!)* Мин сезгә безнең шәһәрне төзегән төзүчеләрдән хат алып килдем. Сез аны бергәләп тыңларсыз. Сау булыгыз.

Тәрбияче. Рәхмәт, Хат ташучы, сау бул! Балалар, бу хат гади хат түгел, әйдәгез, игътибар белән бергәләп тыңлыйк әле.

Аудиоязма яңгырый. Исәнмесез, балалар! Без сезнең бүген шәһәребез турында сөйләшкәнегезне белдек һәм аның ничек төзелгәне турында сөйләргә булдык. Безнең шәһәребезнең тарихы бик кызыклы. Бик күптәннән бу җирләргә бер кеше килеп урнашкан. Ул юл салып, терлек асрап, иген игеп яши башлаган. Аны күреп, тагын бүтән кешеләр килеп урнашканнар, һәм кечкенә авыллар барлыкка килгән. “Чаллы” сүзе елга исеменнән алынган. Елга буена урнашканга күрә дә инде, шәһәребез Яр Чаллы дип атала. Балалар, менә шушы кечкенә авылдан ничек зур шәһәр барлыкка килде икән соң? Кешеләр Кама автомобиль заводын төзергә килгәннәр. Завод төзегәндә, кешеләр палаткаларда, вагоннарда яшәгәннәр. Тиз арада Чаллы авылыннан зур Чаллы шәһәре барлыкка килә. Шәһәребез үсте, зурайды. Безнең шәһәрне сезнең әбиләрегез, бабаларыгыз төзеде. Хәзер сезнең әтиләрегез, әниләрегез зур биналар, матур йортлар төзиләр. Балалар, шәһәребезнең киләчәге сезнең кулларда. Безнең шәһәребез данлыклы! Шәһәребез һәрвакыт матур, күкләребез аяз булсын! Төзүчеләр.

Тәрбияче. Рәхмәт төзүчеләргә. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, менә без шәһәребезнең тарихы белән

таныштык. Ни өчен безнең шәһәр “Яр Чаллы” дип атала? (Активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, безнең шәһәрне кемнәр төзегән? (Балаларның җаваплары.) Дөрес, балалар, безнең шәһәрне төзүчеләр – сезнең әбиләрегез, бабаларыгыз төзегән. Ә хәзер зур биналарны, матур йортларны кемнәр төзи? (Балаларны активлаштыру.) (Балаларның җаваплары.) Балалар, безнең шәһәребез нинди? (Балаларның җаваплары.) Әйе, безнең шәһәр матур, зур, данлыклы. Бергәләп кабатлыйк: данлыклы. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, шәһәребез матур булсын өчен, безгә нәрсә эшләргә кирәк икән? (Балаларны активлаштыру.) (Балаларның җаваплары.) Әйе, шәһәребез матур булсын өчен агачлар, чәчәкләр утыртырга, урамнарны чиста тотарга, чүп ташламаска, әйберләрне ватмаска кирәк. Булдырдыгыз! Балалар, әйдәгез, без сезнең белән менә бу төзү материалларыннан үзебезнең урамны төзик.

Тәрбияче балаларга төзү материаллары бирә. Балалар барысы бергә шәһәр күренеше төзиләр.

Тәрбияче. Урамыгыз бигрәк матур. Мин бу урамда яшәр идем! Балалар, ә сез бу урамга нинди исеме бирәсез? (Балаларны активлаштыру.) (Балаларның җаваплары.) Булдырдыгыз! Бик кызыклы исемнәр. Безнең урамның исеме “Яшь төзүчеләр” булыр. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Менә безнең шәһәребездә тагын бер яңа урам барлыкка килде. Булдырдыгыз!

## Тема: МИНЕМ ТУГАН ИЛЕМ – РӘСӘЙ

**Бурычлар:**

1) балаларда туган ил, аның тарихы, флаг (әләм) турында күзаллаулар формалаштыру;

2) балаларның кабул итүләрен, сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтү осталыгын, игътибарын үстерү;

3) балаларда туган илгә мәхәббәт, төгәллек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** интерактив такта, компьютер, проектор, Рәсәй тарихы турында слайдлар, Рәсәй флагы рәсеме, балалар санынча А5 форматындагы ак кәгазь битләре, ак, зәңгәр, кызыл төстәге кәгазь тасмалар.

## Эшчәнлек барышы

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, анда кем бар икән?

Ишекне барып карый, Йомшаккай керә.

Тәрбияче. Безгә кем килгән? *(Йомшаккай.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.)

Йомшаккай. Исәнмесез, балалар! (Балаларны активлаштыру.)

Тәрбияче. Ни булды сиңа, Йомшаккай?

Йомшаккай. Мин бит мәктәптә укыйм. Миңа өй эше бирделәр, ә мин аны эшли алмыйм. Сез бит бик акыллы балалар, миңа ярдәм итә алмассызмы икән?

Тәрбияче. Әйдә биремеңне әйтеп кара, безнең балалар сиңа ярдәм итәрләр.

Йомшаккай. Миңа үзебезнең Туган илебез турында, Рәсәй, аның тарихы турында сөйләргә куштылар, ә мин бер нәрсә дә белмим.

Тәрбияче. Йомшаккайга ярдәм итәбезме? *(Әйе.)* Мин сезгә Рәсәй турында сөйлим, сез игътибар белән тыңлагыз. (Сөйләгәндә информацион технологияләр кулланырга мөмкин.) Безнең илебез бик борынгы. Безнең илебез ничек атала? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, безнең Туган илебез – Рәсәй. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бик күптән, кешеләр төркемнәр белән яшәгәннәр. Һәр төркемнең үз башлыгы булган. Безнең илнең дә үз башлыгы бар. Аны президент дип атыйлар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Безнең илебез – Рәсәйнең дә туган көне бар. 12 нче июнь – Рәсәй Федерациясенең туган көне. Бу бик зур

бәйрәм. Балалар, бергә кабатлыйк әле: 12 июнь – Рәсәйнең туган көне. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, нинди илдә яшибез? *(Рәсәй Федерациясендә, Рәсәйдә.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, без Рәсәйдә яшибез. Булдырдыгыз! Балалар, уң кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең уң кулыгыз! Уң кулыгызга сокланып карагыз! Сул кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең сул кулыгыз! Уң кул бармаклары чиратлап сул кул бармаклары белән исәнләшәләр:

Саумы, кояш!
Саумы, һава!
Саумы, иртә!
Саумы, йомшак җил!
Саумы, Туган ил!

Тәрбияче. Йомшаккай, балалар, мин сезгә бер рәсем күрсәтәм.

Тәрбияче балаларга Рәсәй флагы (әләме) рәсемен күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле бу рәсемгә. Рәсемдә сез нәрсә күрәсез? *(Флаг.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, әйе, бу рәсемдә безнең илнең флагы (әләме) сурәтләнгән. Һәрбер илнең, дәүләтнең үз әләме (флагы) бар. Безнең илнең дә флагы (әләме) бар. Балалар, флаг (әләм) нинди төсләрдән тора? *(Ак, зәңгәр, кызыл.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, бу төсләр һәрберсе нәрсә дә булса аңлата. Ак төс – бурычны, чисталыкны, зәңгәр – тугрылыкны, яратуны, кызыл – батырлыкны, көчне аңлата. Әйдәгез, балалар, сезнең белән әләмнәр (флаглар) ясыйбыз. Сезнең алда ак, зәңгәр, кызыл кәгазь тасмалар, шуларны дөрес итеп, үрнәктәге кебек бер-бер артлы ябыштырабыз. (Балалар аппликация ясыйлар.) Йомшаккай, менә балалар нинди матур флаглар (әләмнәр) ясадылар. Бу безнең илебезнең – Рәсәй флагы (әләме.)

Йомшаккай. Рәхмәт сезгә, балалар! Мин бик күп нәрсәләр белдем, сез бик акыллы балалар. Сау булыгыз!

## *Бишенче бүлек.*
# ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

### Тема: КАР КЫЗЫ, КАР БӨРТЕГЕ БЕЗДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) Яңа ел уңаеннан балаларның тирә-юнь турындагы күзаллауларын киңәйтү, курчак киемнәренең билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; төзү детальләрен аеру һәм атауны (куб, пластина, кирпеч, борыс) ныгыту, аларны төзүдә кулланырга өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, диалоглы сөйләмен, төзү материаллары белән эшләү осталыгын үстерү;

3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру, курчакларга карата кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ике курчак (берсе Кар кызы, икенчесе Кар бөртеге булып киенгән), һәр балага җитәрлек төзү материалы.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, тиздән нинди бәйрәм якынлаша? *(Яңа ел бәйрәме. Чыршы бәйрәме.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, Яңа ел бәйрәмен һәр кеше көтеп ала. Һәр җирдә Яңа ел чыршылары бизәлә. Һәр кеше: олымы ул, кечкенәме – Яңа елны каршыларга әзерләнә. Курчаклар да бу бәйрәмне көтеп алалар, бу бәйрәмне яраталар, балаларга кунакка киләләр, бергәләп уйныйлар, күңел ачалар.

Ишек шакыйлар. Курчак керә.

Тәрбияче. Бүген безгә кунакка курчак килде. Исәнләшик курчак белән. *(Исәнмесез!)* Балалар, карагыз, бу гади курчак түгел, бу курчак – Кар кызы, Кыш бабайның оныгы. (Балаларны активлаштыру.) Кар кызының киемен карыйк әле. Бу нәрсә? (Тәрбияче курчакның күлмәгенә күрсәтә.) *(Күлмәк.)*

(Балаларны активлаштыру.) Күлмәк нинди төстә? (Балаларның җаваплары.) Күлмәк нәрсә белән бизәлгән? *(Якасы, җиңнәрне, итәге мамык белән бизәлгән, курчак күлмәк өстеннән мәрҗәннәр элгән. Мәрҗәннәр бик матур, алар җем-җем итәләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Курчакның күлмәге сезгә ошыймы? (Балаларны активлаштыру.) Әйе, Кар кызының күлмәге бик матур, үзенә килешеп тора. Кар кызы башына нәрсә кигән? *(Башлык.)* Башлык нинди төстә? (Балаларның җаваплары.) Әйе, башлык һәм күлмәк бер төстә. Башлык та Кар кызына бик килешә. Балалар, Кар кызы аягына нәрсәләр кигән? *(Итекләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Кар кызының итекләре нинди? *(Матур, җиңел, мишуралар белән бизәлгән.)* (Балаларны активлаштыру.) Мин сезгә сораулар бирәм, сез җавап бирегез. Бу кем? *(Кар кызы, Кыш бабайның оныгы.)* Кар кызы өстенә ... (*күлмәк*) кигән. Кар кызының күлмәге ... *(матур, бизәлгән, зәңгәрсу төстә.)* Бу Кар кызының ... (*башлыгы.*) Ул ... *(матур, бизәлгән, килешә, зәңгәрсу төстә.)* Кар кызы аягына ... (*итекләр*) кигән. Алар ... *(матур, җиңел, мишуралар белән бизәлгән.)* Балалар, Кар кызы үзе белән Кар бөртеген дә алып килгән. Менә ул. (Икенче курчакны күрсәтә.) Исәнләшик Кар бөртеге белән. *(Исәнмесез!)* Кар бөртегенең дә киемен карыйк әле. Кар кызы һәм Кар бөртеге бертөрле киенгәннәрме, әллә башкачамы? (Балаларның җаваплары.) Бу нәрсә? (Тәрбияче Кар бөртеге курчакның күлмәгенә күрсәтә.) *(Күлмәк.)* (Активлаштыру.) Күлмәк нинди төстә? (Балаларның җаваплары.) Күлмәк нәрсә белән бизәлгән? *(Мишуралар белән бизәлгән.)* (Балаларны активлаштыру.) Кар бөртегенең күлмәге сезгә ошыймы? (Балаларны активлаштыру.) Әйе, Кар бөртегенең күлмәге бик матур, үзенә килешеп тора. Кар бөртеге башына нәрсә кигән? *(Бер нәрсә дә кимәгән. Ул башын мишура белән бизәгән.)* (Балаларның җаваплары.) Балалар, Кар бөртеге аягына нәрсәләр кигән? *(Ак носкилар, ак туфлиләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Кар бөртегенең туфлиләре нинди? *(Матур, җиңел.)* (Балаларны активлаштыру.) Хәзер без барыбыз да Кар бөртекләре булырбыз. (Тәрбияче аудиоязманы куя.) Кар бөртекләре һавада әйләнәләр-әйләнәләр дә җиргә

төшәләр. (Берничә тапкыр кабатлана.) Балалар, әйдәгез, Кар кызы белән Кар бөртегенә өй төзибез. Урыннарыгызга утырыгыз.

Өстәлләрдә төзү материаллары: кубиклар, пластиналар, кирпечләр, борыслар. Балалар курчаклар өчен йорт төзиләр. Төзү материалының атамасын, төсен, формасын, зурлыгын, билгеләнешен атыйлар.

## Тема: ЯҢА ЕЛ УЕНЧЫКЛАРЫ

**Бурычлар:**

1) балаларны Яңа ел бәйрәмен каршыларга әзерләү, чыршы уенчыклары белән таныштыру, пыяладан ясалган уенчыкларның, предметларның билгеләрен ачыклау (үтә күренмәле, төсле, шома, салкын, ватылучан);

2) балаларның сенсор сәләтләрен һәм кызыксынуын, күзәтүчәнлеген үстерү;

3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** тартма, төрле төстәге, зурлыктагы һәм формадагы чыршы уенчыклары, пыяладан ясалган кечкенә предметлар (ислемай шешәләре, ут лампасы, савыт-саба, ваза, бокал һ. б.), пыяланың тавышын белү өчен таякчык, стакан. В. Вәлиева сүзләре һәм көенә язылган “Чыршыкай-матуркай” җыры аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче кулына мишуралар белән бизәлгән тартма ала.

Тәрбияче *(серле тавыш белән)*. Балалар, бу нәрсә? Әйе, бу тартма. Гади тартма түгел, ул тылсымлы тартма. (Тәрбияче тартманы акрын гына селкетә.) Анда нәрсәдер бар! Тартма эчендә нәрсә бар икәнен белү өчен, аны ачып карарга кирәк. Алсу, кил әле, тартманы ач һәм андагы предметларны балаларга күрсәт. (Бала тартманы ача.) Алсу, син нәрсә алдың?

*(Чыршы уенчыгы.)* Балалар, тылсымлы тартмада чыршы уенчыклары салынган. (Тәрбияче тартмадан уенчыкларны ала һәм күрсәтә.) Бу чыршы уенчыклары түгәрәк формада, төрле зурлыкта, төрле төстә: кызыл, зәңгәр, сары, яшел. Ничек уйлыйсыз, бу уенчыкларны нинди материалдан ясаганнар икән? (Балаларны активлаштыру.) Бу уенчыклар пыяладан ясалган. Пыяла уенчыклар. (Тәрбияче өстәлгә төсле һәм үтә күренмәле пыяладан ясалган предметлар тезә.) Балалар, үтә күренмәле пыяладан ясалган нинди предметлар беләсез? *(Тәрәзә, ут лампасы, шешәләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Төсле пыяладан ясалган нинди предметлар күрәсез? *(Савыт-саба.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, өстәлдә яткан пыяла предметларны тотып карагыз әле. Алар нинди? *(Шома, салкын.)* (Балаларны активлаштыру.) Пыяла су үткәрми. Карагыз әле, хәзер мин тәҗрибә үткәреп карыйм. (Тәрбияче стаканга су сала.) Су стаканнан агып чыктымы? *(Юк.)* Стакан турында нәрсә әйтергә була? *(Пыяла су үткәрми.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, суны пыяладан ясалган нинди савытларга салырга була? *(Шешә, банка, чынаяк, ваза һ. б.).* Пыяла төрле калынлыкта булырга мөмкин. Тәрәзәләрне, витриналарны калын пыяладан ясыйлар. Вазаларны, бокалларны нечкә пыяладан ясыйлар. (Балаларны активлаштыру.) Ләкин пыяла, нинди калынлыкта булуына карамастан, тиз ватыла, шартлый. Шуңа күрә пыяладан ясалган предметларга карата бик сак булырга кирәк. Балалар, карагыз әле, мин махсус таякчык белән сак кына пыяла предметларга сугып чыгам. Тыңлагыз, пыяла нинди тавыш чыгара? *(Яңгыравыклы, чылтырый.)* (Балаларны активлаштыру.) (Тәрбияче балаларның игътибарын тартмадагы чыршы уенчыкларга юнәлтә.) Балалар, тартмадагы чыршы уенчыклары нинди материалдан ясалган? *(Пыяла.)* (Балаларны активлаштыру.) Тиздән Яңа ел бәйрәме җитәчәк, без чыршыны шундый матур уенчыклар белән бизәрбез. Чыршыбыз матур, купшы булыр, ялтырап торыр. Хәзер аларны, ватылмасын өчен, тартмага салып куйыйк. (Балалар, берәм-берәм килеп,

уенчыкларны тартмага салалар.) Булдырдыгыз! Әйдәгез, чыршы турында җыр тыңлыйбыз һәм биибез.

Тәрбияче В. Вәлиева сүзләре һәм көенә язылган “Чыршыкай-матуркай” җыры аудиоязмасын куя.

## Тема: ЯҢА ЕЛ КИЛӘ

**Бурычлар:**

1) балаларда Яңа ел бәйрәме турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү; сенсор билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерү осталыгын ныгыту;

2) балаларның чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләү, диалоглы сөйләмен, сорауларга җөмлә белән җавап бирү осталыгын, хисси тәҗрибәсен, кабул итүләрен үстерү;

3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре уяту.

**Җиһазлар:** мольберт, А3 форматында “Яңа ел” сериясеннән картиналар (1. балалар бакчасында балалар Яңа елга әзерләнә, шарлар, сөңгеләр, фонариклар, кар бөртекләре белән ёлка бизиләр; 2. бүлмә бизиләр; 3. балалар маскалар, әкият персонажлары костюмнары кигәннәр; 4. Бәйрәм башланган, Кыш бабай килгән), шкатулка, төрле төстәге, зурлыктагы, формадагы чыршы уенчыклары, В. Вәлиева сүзләре һәм көенә язылган “Чыршыкай-матуркай” җыры аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Мольбертка “Яңа ел” сериясеннән картина куелган, ул капланган. Тәрбияче балаларның игътибарын шуңа җәлеп итә.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, бу нәрсә икән? Әйдәгез ачып карыйк. Балалар, монда матур рәсемнәр. Бу бит балалар

бакчасы. Рәсемдә сез тагын нәрсә күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, балалар бәйрәмгә әзерләнә. Ә алар нинди бәйрәмгә әзерләнә икән соң, сез ничек уйлыйсыз? *(Яңа ел бәйрәменә.)* (Балаларны активлаштыру.) Сез аны каян белдегез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйдәгез, балалар, Яңа елга ничек әзерләнәләр икән, шуны карыйк. Балалар, башта алар нишләгәннәр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, балалар бүлмәгә чыршы куйганнар. Бергәләп кабатлыйк: бүлмәгә чыршы куйганнар. (Балаларны активлаштыру.) Ә аннан соң нишлиләр? *(Аны бизиләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Чыршыны нәрсә белән бизиләр? (*Уенчыклар белән.*) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, ләкин бу гади уенчыклар түгел, ә ёлка уенчыклары. Балалар, бу рәсемгә карагыз әле, нинди матур зал. Аны нәрсә белән бизәгәннәр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, монда гирляндалар да бар, фонариклар да, мишуралар да, кәгазьдән ясалган кар бөртекләре дә бар. Булдырдыгыз! Балалар, менә бу картинада балалар нишлиләр? *(Маскалар, костюмнар кияләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу гади костюмнар гына түгел, ә Яңа ел костюмнары, маскарад костюмнары. Бергәләп кабатлыйк: маскарад костюмнары. (Балаларны активлаштыру.) Нинди әкият геройларының костюмнарын кигәннәр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Кайсыгыз балаларның Яңа ел бәйрәменә әзерләнүләрен сөйли? (Балаларны активлаштыру.)

Тәрбияче берничә баланы чакыра, алар картиналар буенча Яңа елга әзерләнүне сөйлиләр.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле бу рәсемгә. Сез нәрсә күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бәйрәм башланган. Балаларның кәефләре нинди? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балаларның кәефләре яхшы, күтәренке,

күңелле, чөнки бүген Яңа ел бәйрәме. Балалар, Яңа ел бәйрәме ни өчен күңелле? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Сез Яңа елда кем килүен көтәсез? *(Кыш бабайны.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен сез Кыш бабайны көтәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ә Кыш бабай сезгә нәрсәләр бүләк итә? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ә сез Кыш бабайны ничек сөендерәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, бергәләп өйрәнгән җырны җырлыйбыз.

Тәрбияче белән балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар һәм Яңа ел турында берәр җыр башкаралар. Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, ишек шакыйлар, кем икән ул?

Тәрбияче ишеккә бара һәм матур итеп бизәлгән шкатулка алып керә.

Тәрбияче *(серле тавыш белән)*. Балалар, хат ташучы безгә Кыш бабайдан бүләк китергән. Бу нәрсә икән? *(Шкатулка.)* Әйе, бу шкатулка. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бу гади шкатулка түгел, ул тылсымлы шкатулка. (Тәрбияче шкатулканы акрын гына селкетә.) Анда нәрсәдер бар! Алия, кил әле, ач шкатулканы. Алия, син нәрсә алдың? *(Уенчык.)* Балалар, бу сез уйный торган уенчык түгел, бу нинди уенчык? *(Чыршы уенчыгы.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Алия, син алган чыршы уенчыгы ничек атала? *(Шар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Алсу, шарны кара әле, ул формасы буенча нинди? *(Түгәрәк.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, шарны тотып карагыз әле, ул нинди: кытыршымы әллә шомамы? (Тәрбияче балалар янына килә, балалар шарны тотып карыйлар.) *(Шома.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Шар нинди төстә? *(Кызыл шар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) (Тәрбияче җебеннән тотып шарны әйләндерә.) Балалар, карагыз әле, шар ялтырый.

(Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Шар чыршыны бизәү өчен генә кулланыла. Төшеп китсә, ул ватыла. Шуңа күрә, аны чыршыга элгәндә, бик сак булырга кирәк.

Тәрбияче балалар белән тагын ике шар карыйлар, алар төрле төстә, зурлыкта, шома һәм кытыршы.

Тәрбияче. Балалар, без караган шарлар нинди уенчыклар? *(Чыршы уенчыклары.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Алар нинди формада? (*Түгәрәк.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Зурлыгы буенча нинди? *(Төрле зурлыкта.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Төсе буенча нинди? *(Төрле төстә: кызыл, зәңгәр, сары, яшел.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Шарлар барысы да кытыршымы, әллә шомамы. *(Шома.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Шарлар белән нәрсәне бизиләр? *(Чыршыны бизиләр.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Тиздән Яңа ел бәйрәме җитәчәк, без чыршыны шундый шарлар белән бизәрбез. Чыршыбыз матур, купшы булыр, ялтырап торыр. Хәзер аларны ватылмасын өчен шкатулкага салып куйыйк. (Балалар берәм-берәм килеп, уенчыкларны шкатулкага салалар.) Булдырдыгыз! Әйдәгез, чыршы турында җыр тыңлыйбыз һәм биибез.

Тәрбияче В. Вәлиева сүзләре һәм көенә язылган “Чыршыкай-матуркай” җырының аудиоязмасын куя.

## Тема: КИЕМНЕҢ ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

**Бурычлар:**

1) балаларны киемнең билгеләнеше һәм функцияләре белән таныштыру; кием материалы һәм аны куллану ысулы арасындагы бәйләнешне урнаштырырга өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, диалоглы сөйләмен, кызыксынуын, иҗади сәләтләрен үстерү;

3) балаларда зәвык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ике рәсем: яфраклардан тегелгән юбка кигән кеше һәм җәнлек тиресеннән тегелгән киемле кеше; җитен үләне ясалган рәсем, мамык үсү күренеше төшерелгән рәсем, сарык йоны, ике кисәк тукыма, төрле тукыма үрнәкләре, кәгазьдән ясалган Яңа ел күлмәге силуэтлары, төсле карандашлар.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, тиздән нинди бәйрәм якынлаша? *(Яңа ел бәйрәме. Чыршы бәйрәме.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, Яңа ел бәйрәмен һәр кеше көтеп ала. Бүлмәдә чыршы бизиләр, матур күлмәкләр алалар, тегәләр. (Тәрбияче карнавал рәсемен күрсәтә: Кар кызы, Кар бөртеге, төлке, аю, бүре һ. б. булып киенгән балалар.) Карагыз әле, Яңа елга нинди карнавал костюмнар әзерлиләр: балалар төлке, бүре, аю, елан булып киенергә яраталар. Сез киемнәрнең ничек барлыкка килгәнен беләсезме? Кешеләр ничек итеп кием тегә башладылар икән? Теләсәгез, сезгә дә сөйлим. Уңайлы итеп утырыгыз һәм тыңлагыз. Борын-борын заманда кешеләр урманда, тау куышларында яшәгәннәр. Җил, яңгырдан капланырга бернинди әйберләре дә булмаган. Урманда зур һәм кечкенә яфраклы агачлар үскән, үләннәр бик биек булып үскәннәр. Салкын булган вакытта кешеләр үзләрен шул яфраклар белән каплый торган булганнар. (Тәрбияче яфраклардан ясалган юбка күрсәтә, аны курчакка кидертә.) Менә шулай итеп киенгән элекке кешеләр. Яфраклар салкыннан бик саклый алмаганнар, алар тиз тузганнар. Кешеләр башка материал эзли башлаганнар. Урманнарда, тау куышлыкларында кешеләр белән төрле җәнлекләр дә яшәгән. Алар яңгырдан да, җилдән дә, салкыннан да курыкмаганнар. Кешеләр җәнлек тиресеннән кием тегә башлаганнар. (Тәрбияче җәнлек тиресе кигән кешеләрне күрсәтә.) Балалар, сез ничек уйлыйсыз, яфрактан тегелгән кием уңайлымы, әллә җәнлек тиресеннән тегелгән киемме? (Балаларның җаваплары.) Дөрес әйтәсез, җәнлек тиресеннән тегелгән кием авыр булган,

кешеләр өчен уңайлы булмаган. Кешеләр уңайлы кием турында уйлана башлаганнар. Алар бик күзәтүчән булганнар: кырда җитен үскән. (Тәрбияче җитен үләне күрсәтә.) Җитен турында мондый табышмак бар, тыңлагыз: “Озын буйлы, зәңгәр күзле”. Җитен озын буйлы, аның чәчәкләре зәңгәр. Шуңа күрә дә шундый табышмак уйлап тапканнар. Җитеннең сабакларын тарткаласаң, йомарласаң, изсәң, җеп эрләргә, җептән тукыма ясарга була. Шундый тукыма ясап, кешеләр үзләрен чорнап куйганнар. Без дә шулай эшләп карыйк әле. (Тәрбияче ике баланы чакыра, аларны тукыма белән чорный, йөреп карарга куша.) Сезгә шулай йөрү уңайлымы? Болай чорналгач, эш эшләве дә бик уңайсыз. Остазлар энә, җеп уйлап тапканнар, алар белән күлмәкләр тегә башлаганнар. Башта кешеләр тукыманы җитеннән ясаганнар, соңрак мамыктан ясый башлаганнар. Тагын да соңрак сарык йонынннан тукымалар ясаганнар. (Тәрбияче тукыма үрнәкләрен күрсәтә.) Күлмәк тегүче осталар киемнәрне матур һәм уңайлы итеп тегәргә тырышканнар. Балалар, кешеләр ничек итеп кием тегәргә өйрәнгәннәрен аңладыгызмы? Хәзер олылар да, балалар да бик матур итеп киенәләр. Аларның киемнәре уйнар өчен, эшләр өчен, ял итәр өчен бик уңайлы. Ял итеп алыйк. Урамга җыенабыз, ди. Носкиларны, чалбарларны, кофтаны, бүрекне, куртканы киябез. (Балалар киенү гамәлләрен күрсәтәләр.) Бер-берегезгә шарфларны бәйләргә булышыгыз. Бияләйләрне киябез. Сез нәрсәләр кидегез? (Балаларның җаваплары.) Чыктык. Кар белән уйныйбыз. (Балалар бер-берсенә “кар” аталар.) Кар ява башлады. Кар бөртекләрен тотыгыз. Хәзер аларга өрегез, озак итеп өрегез. Булдырдыгыз. (Ике тапкыр кабатлана.) Хәзер кешеләр киемнәрне кибеттән сатып алалар. Анда нинди генә киемнәр юк! Эш киемнәре дә, бәйрәм киемнәре дә, Яңа ел костюмнары да бар. (Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә.) Яңа ел алдыннан сезгә әниләрегез матур күлмәкләр, матур киемнәр сатып алалар. Сез, аларны киеп, чыршы янында әйлән-бәйлән уйнарсыз, шигырь сөйләрсез. Кыш бабай белән биерсез. Хәзер, балалар, урыннарыгызга утырыгыз. Өстәлләрдә күлмәк силуэтлары һәм төсле

карандашлар ята. Бу күлмәкләргә Яңа ел бизәкләре ясагыз. (Балалар күлмәкләргә бизәк төшерәләр.)

## Тема: ХУШ КИЛӘСЕҢ, КАРЛЫ КЫШ!

**Бурычлар:**

1) балаларның кыш, Яңа ел турындагы белемнәрен тирәнәйтү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;

2) кабул итүне, игътибарны, сүзлек байлыгын, бәйләнешле сөйләмне үстерү;

3) биремнәрне үтәүгә кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар**: конверт (аның эчендә хат, чыршы һәм чыршы уенчыкларының (бер йолдыз, ике кызыл шар, ике сары шар) контурлы сурәтләре; өч картинка (беренчесендә –кар бөртеге, кыш бабай, кар кызы, үлән; икенчесендә – панама, тун, бияләйләр, киез итекләр; өченчесендә – чана, велосипед, чаңгы, тимераяк ясалган), "Чыршы җыры"ның (К. Кинзәбулатова сүзләре, С. Низаметдинов көе) аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Балалар кулга кул тотынып түгәрәккә басалар. Чиратлап бер берсенең кулын кысалар һәм: "Исәнме, ... (исемен әйтә)! Мин сине күрүемә бик шат!" – диләр. Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, кемдер ишек шакый. Кем бар икән, чыгып карыйм әле. (Тәрбияче хат алып керә.) Балалар безгә хат килгән. Карагыз әле, конверты нинди матур! Конвертка нәрсәләр ясалган? *(Кыш бабай, Кар кызы һәм Яңа ел чыршысы.)* Конвертны ачып, хатны укыйк. Нәрсәләр язалар икән? Балалар, игътибар белән тыңлагыз, мин укыйм: "Исәнмесез, кадерле балалар. Мин сезне якынлашып килүче Яңа ел бәйрәме белән котлыйм, "Хуш киләсең, Карлы Кыш!" уеннарында катнашырга чакырам. Һәр баланы бүләк көтә. Бүләк чыршы бәйрәмендә булачак. Сезне яратып, Кыш

бабагыз.” Балалар, хат кемнән килгән? *(Кыш бабайдан.)* Балалар, “Хуш киләсең, Карлы кыш!” уеннарында катнашабызмы? *(Әйе.)* Балалар, конверт эчендә хат кына түгел, тагын нәрсәдер бар. (Тәрбияче конверттан картоннан ясалган чыршы һәм чыршы уенчыкларының контурлы сурәтләрен ала.) Бу нәрсә? *(Чыршы.)* Ә монда нәрсәләр? *(Уенчыклар.)* Әйе, Яңа ел уенчыклары. (Балаларны активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Уенчыклар гади түгел. Аларның һәрберсендә дә Кыш бабай җибәргән биремнәр бар. Биремне үтәгәч, уенчыкны чыршыга элеп куярга кирәк. Әгәр дә барлык уенчыклардагы биремнәрне үтәп, аларны чыршыга элеп куйсак, без уеннарда җиңүче булачакбыз. Тырышып карыйбызмы? *(Әйе.)* (Тәрбияче бер чыршы уенчыгын ала һәм биремне укый.) Бер уенчыкны алам. Уенчыкта нинди бирем бар икән? Бу *уенчыкта* табышмак бар. Тыңлагыз әле:

Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән,
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчан? *(Кыш.)*

Дөрес, балалар, табышмакта кыш турында әйтелә. Уенчыкны чыршыга элеп куябызмы? *(Әйе.)* (Тәрбияче уенчыкны үзе элә яки берәр баланы чакыра.) Гүзәл , кил әле, икенче уенчыкны ал! Нинди бирем җибәргән икән Кыш бабай? Балалар, менә монда картинкалар бар.

Тәрбияче алдан ук балаларның урындыкларына картинкалар куеп чыга. Урындыгына кыш сурәтләнгән картинка куелган бала, аны күрсәтә һәм анда нәрсәләр күрүен әйтә. Шуннан соң тәрбияче картинканы җыелма кесәгә куярга куша. Түбәндәге картинкалар куела: 1) кар ява, бөтен җир кар белән капланган; 2) кешеләр җылы киемнәр киеп йөриләр; 3) балалар чанада, чаңгыда, тимераякта шуалар; 4) балалар Кар бабай ясыйлар; 5) елга боз белән капланган; 6) юлларны көрәк һәм кар чистарта торган машиналар белән чистарталар; 7) балалар җимлекләр эләләр, җимлеккә җим сибәләр. Бала биремне мөстәкыйль үти алмаса, башка балалар да ярдәм итә ала.

Т ә р б и я ч е. Балалар, ничек уйлыйсыз, бирем үтәлдеме? *(Әйе.)* Димәк, икенче уенчыкны чыршыга элеп куярга кирәк. Алсу, кил әле, уенчыкны чыршыга элеп куй. (Элә.) Булдырасыз, балалар. Барлык биремнәрне дә үтәрсез дип ышанам.

Балалар, өченче биремне үтәр алдыннан
әйдәгез ял итеп алыйк.
Йомшак карны алабыз
*(кар әвәләү хәрәкәтләре ясыйлар).*
Аннан туплар ясыйбыз.
Кар атышып уйныйбыз.
Бик күңелле яшибез
*("кар атышалар").*
Суыктан без курыкмыйбыз
*(кулларын як-якка җәеп йөриләр),*
Рәхәтләнеп уйныйбыз.
Кар бөртекләре куып
Уйнаудан һич туймыйбыз
*(йөгерәләр).*

Рәхәтләнеп ял иттек, хәрәкәтләндек. Хәрәкәттә – бәрәкәт! Хәзер инде калган уенчыклар белән чыршыны бизәп бетерергә кирәк. Марат, ничәнче уенчыкны алабыз? *(Өченче.)* Кил, алып бир әле өченче чыршы уенчыгын. Карыйк, нинди бирем алып килгән икән өченче уенчык? Өченче уенчыкта "Нәрсә артык?" уены тәкъдим итела. (Тәрбияче җыелма кесәгә 3 картинка куя.) (Беренче картинага күрсәтә.) Балалар, игътибар белән карагыз әле, бу картинкада нәрсә ясалган? *(Кар бөртеге, кыш бабай, кар кызы, үлән.)* Нәрсә артык? *(Үлән.)* Ни өчен? (Балаларның җаваплары.) Икенче картинканы карагыз! Нәрсәләр ясалган? *(Панама, тун, бияләйләр, киез итекләр.)* Нәрсә артык? *(Панама.)* Ни өчен? (Балаларның җаваплары.) Өченче картинкага игътибар итегез, нәрсәләр күрәсез? *(Чана, велосипед, чаңгы, тимераяк.)* Нәрсә артык, ни өчен?

(Балаларның җаваплары.) Булдырдыгыз, балалар. Биремне бик җиңел башкардыгыз. Кайсыгыз уенчыкны чыршыга элеп куя? (Бер бала уенчыкны элә.) Ничәнче уенчыкны алабыз? *(Дүртенче.)* Яхшы, Энҗе, дүртенче уенчыкны син ал әле. Нинди бирем үтәргә кирәк икән? (Энҗе уенчыкны алып тәрбиячегә бирә.) Балалар, урманда булган бер вакыйга турында сөйләнә. Тыңлагыз әле:

Куян, урман аланлыгында сикергәләп йөргәндә, бик акрын гына чаңгыда шуып йөрүче Кар бабайны күреп алган һәм: “Кар бабай, нигә син шундый күңелсез?” – дип сораган. “Менә, кәефем кырылды, ни өчендер чаңгым әйбәт шумый”, – дигән Кар бабай. Балалар, Кар бабайга күңелсез. Әйдәгез Кар бабайның кәефе күтәрелсен өчен, күңелсез сүзенә каршы мәгънәле сүзләр уйлап карагыз әле *(Күңелле, шаян, шатлыклы, кәефле, җанлы.)* Менә бу вакыйганы да ачыкладык. Кыш көне һәркемгә дә күңелле булсын, шатлык өстәлсен дип, уенчыкны чыршыга элеп куябыз. (Тәрбияче уенчыкны элә.) Чыршы бизәлеп бетте дисәк тә була. Ниһаять, соңгы уенчыкны алабыз. Ул ничәнче? *(Бишенче.)* Менә ул! (Тәрбияче чыршының очына куела торган йолдыз күрсәтә.) Нәрсә бу? *(Йолдыз.)* Кечерәйтеп, матур итеп әйткәндә, ничек була? *(Йолдызчык.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Йолдыз белән нинди бирем җибәргән икән Кыш бабай? Йолдызга сорау язылган: Чыршыда ничә уенчык бар? *(Биш.)* Нинди төстәге уенчыклар бар? *(Кызыл, сары.)* Нинди төстәге уенчыклар күбрәк? *(Кызыл.)* Алар ничә? *(Өч.)* Нинди төстәге уенчыклар азрак? *(Сары.)* Алар ничә? *(Ике.)* Йолдызны чыршыга элеп куям. Балкып янып торсын! Чыршыга барлык уенчыклар да эленде. Биремнәр башкарылды. Үзегез бик зирәк, акыллы икәнсез. Биремнәрне җиренә җиткереп эшләдегез. Әйдәгез, үзегезне мактап кул чабып алыгыз да, кыш турында күңелле җыр тыңлагыз һәм кушылып җырлагыз. (Тәрбияче “Чыршы” (К. Кинзәбулатова сүзләре, С. Низаметдинов көе) җырының аудиоязмасын куя.) Балалар, сез уеннарда катнашып, биремнәр үтәдегез. Бу уеннарның исеме ничек атала иде әле? *(Хуш киләсең, Карлы кыш!)* Уеннар сезгә ошадымы? Нәрсә ошады? Нәрсә белдегез?

(Балаларның җаваплары.) Балалар, Кыш бабай җибәргән биремнәрне үтәдегез, уенчыклар белән чыршыны бизәдегез. Сез бизәгән Яңа ел чыршысы безнең бүлмәне бизәп торыр. Ә без сезнең белән Яңа ел бәйрәмен, Кыш бабайны, аның бүләкләрен көтеп калабыз.

## Тема: МИЛӘШ ҺӘМ БАЛАН ҖИЛӘКЛӘРЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның Яңа ел турындагы күзаллауларын киңәйтү; үсемлекләрнең җимешләре, аларның табигатьтәге һәм кеше тормышындагы роле белән таныштыру;

2) танып белүгә кызыксыну үстерү, сүзлекне баету һәм активлаштыру;

3) кошларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** тартмага салынган миләш җиләкләре, һәр бала өчен тәлинкәгә салынган миләш җиләкләре, миләш агачына кунган карабүрекләр ясалган картинка.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, кулга-кул тотынышып басыгыз да, башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып "Хәерле иртә!" теләгез. Балалар, миндә бер тартма бар. Тартманы селкетеп карыйм. (Селкетә.) Нәрсә бар икән соң тартма эчендә. Мин табышмак әйтәм, ә сез җавабын эзләгез:

Җимешем кып-кызыл була,
Бу шатлык минем өчен!
Чөнки кышкы салкында да,
Һич тә үзгәрми төсем. *(Миләш.)*

Бик дөрес, балалар! Тартма эчендә миләш җиләкләре бар. Тартма эчендә нәрсә бар? *(Миләш җиләкләре бар.)* (Балаларны

активлаштыру.) (Тәрбияче тартма эченнән миләш тәлгәше ала.) Бу нәрсә? *(Миләш тәлгәше.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бер ботакта ничә җиләк бар дип уйлыйсыз? *(Ботакта җиләкләр күп.)* Бер ботакта җиләкләр күп булганда, ул нәрсә дип атала? *(Тәлгәш.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, миндә тагын бер төрле җиләк бар. (Тәрбияче балан тәлгәше күрсәтә.) Бу җиләк нәрсә дип атала? *(Балан.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балан җиләкләре миләш җиләкләренә охшаганмы? *(Әйе.)* Нәрсә белән охшаган? *(Алар түгәрәк, шулай ук тәлгәше бар.)* Балан җиләкләре миләш җиләкләреннән нәрсә белән аерыла? *(Алар ялтырап торалар, сусыл, тотып карауга йомшак, ачык кызыл төстә.)* (Балаларны активлаштыру.) Балан җиләкләрен миләш җиләкләренең апасы дип тә атыйлар. Миләш һәм балан турында бертөрле табышмак та бар:

Яшел күлмәкләрен салганнар,
Кызыл төймәләре калганнар.

Балалар, табышмакта нинди яшел күлмәк турында сүз бара? Ни өчен агачлар яшел күлмәкләрен салганнар? (Балаларның җаваплары.) Балалар, яфраклары булмаса да, миләш һәм балан җиләкләре кыш көне дә агачта кып-кызыл булып утыралар. Сез миләш яфракларының нинди икәнен беләсезме? Аларны башка яфраклар арасыннан аера аласызмы? *(Әйе.)* Менә бу яфраклар арасыннан миләш яфрагын күрсәтегез

2–3 бала кипкән яфраклар арасыннан яки картинкадан миләш яфрагын аерып күрсәтәләр.

Тәрбияче. Балалар, табышмакта миләшнең һәм баланның кызыл төймәләре булуы әйтелә. Кызыл төймәләр дип нәрсә турында әйтелә? *(Җиләк турында.)* Әйдәгез, миләш җиләкләрен карыйк. (Балалар өстәл артына утыралар. Тәрбияче һәр бала каршына тәлинкәгә салынган миләш җиләкләре куя.) Балалар, игътибар белән карагыз әле, чынлап та, миләш җиләге төймәгә охшаганмы? Алар тагын нәрсәгә

охшаган? *(Сәдәфкә, кечкенә шарга, кечкенә тупка, алмага.)* Сезнең тәлинкәдә ничә җиләк бар? (Тәрбияче аерым балалардан сорый, алар санап әйтәләр.) Балалар, бер җиләкне кулыгызга алыгыз. Тотып карагыз, ул нинди: йомшакмы әллә катымы? Кытыршымы әллә шомамы? *(Җиләк каты һәм шома)* (Балаларны активлаштыру.) Җиләкне учларыгызда, өстәлдә тәгәрәтеп карагыз. Тәгәриме? *(Тәгәри.)* Ул формасы буенча нәрсәгә охшаган? *(Кечкенә шарга.)* Төсе нинди? Миләш җиләкләре менә бу кызыл флагка (күрсәтә) охшаганмы, әллә менә бу кызыл сары кишергәме (күрсәтә)? (Балаларның җаваплары.) Балалар, игътибар итегез әле, миләшнең караңгырак төстәге бер урыны бар. Ул йолдызчыкны хәтерләтә. Әйдәгез лупа аша шул йолдызчыкны карыйк. Санагыз әле, йолдызчыкның ничә нуры бар? (Балалар биремне үтиләр, сорауларга җавап бирәләр.) Балалар, җиләкнең эчендә нәрсә бар, сытып карагыз әле! (Салфетка белән җиләкне сыталар.) Сыткач, нәрсә күрдегез? *(Эчендә сок, төшләре-орлыклары, җимеш йомшагы бар.)* (Балаларны активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, миләш җиләкләрен иснәп карагыз әле. Сезгә аның исе ошыймы? *(Әйе.)* Бер җиләкне ашап карагыз. Аның тәме нинди? *(Әче, әчкелтем.)* Балалар, миләш җиләгендә витаминнар күп. Алардан дару ясыйлар. Әче булуы куркыныч түгел. Әле хәзер дә, тышта кыш булып, Яңа ел якынлашса да, миләш агачында миләш җиләкләре янып торалар һәм салкыннан аларның җиләкләре тагын да тәмлерәк була. Миләшнең хуш исле җиләкләрен кайнатып, шифалы витаминлы чәй ясыйлар. Бу чәй сәламәтлекне ныгыта, көч бирә. Әйдәгез, шушы витаминлы чәйне эчеп карагыз әле. (Балалар эчеп карыйлар.) Бигрәк тәмле! Миләшләрнең хуш исе килеп тора. Балалар, урманда яшәүче җан ияләренең, бигрәк тә кошларның кайсысы миләш җиләкләре ярата? *(Карабүрек исемле кошлар.)* Әйе, балалар, карабүрекләр. Икенче төрле аларны “балан чыпчыгы” дип тә йөртәләр. (Тәрбияче миләш агачына утырган карабүрекләр сурәтләнгән картинка күрсәтә) Балалар, миләш ботагында нинди кошлар утыра? *(Карабүрекләр.)* Сез аларны

ничек таныдыгыз? *(Башларында кара бүрекләре бар әти кошларның түшләре кызыл була.)* Алар ни өчен миләшкә кунганнар? (Балаларның җаваплары.) Балалар, кайчакта кыш көне салкын көчле җилләр исеп, миләш җиләкләрен коеп бетерә. Карабүрекләр бу вакытта нәрсә ашарлар? Аларга кем ярдәм итәр? *(Балаларның җаваплары.)* Балалар, әйдәгез, Яңа елга карабүрекләргә күчтәнәч әзерлик. Энә белән җеп алып тәмле матур җимлек ясарга була. (Күрсәтә. Миләш җиләкләрен төймә итеп тезәләр.) Менә нинди матур төймә килеп чыкты. Яңа ел алдыннан миләш агачына элеп куярбыз. Балалар, карабүрекләр бу күчтәнәчнең сездән икәнен белсеннәр өчен, хат язып җибәрик. Һәрберегезнең хатын диктофонга (магнитофонга) яздырабыз. "Исәнмесез, карабүрекләр! Тышта салкын кыш. Тиздән Яңа ел бәйрәме җитә. Балалар сезне бәйрәм белән котлыйлар. Алар сезгә Яңа ел күчтәнәче әзерләделәр – миләш җиләкләреннән бик тәмле төймәләр ясадылар. Безгә Яңа ел бәйрәменә очып килегез! Без сезне безнең мәйданчыкта көтеп калабыз".

## *Алтынчы бүлек.*
## КЫШ

### Тема: КЫШ БИЛГЕЛӘРЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның кыш турындагы белемнәрен ныгыту;

2) балаларның күрсәтмә образлы фикерләвен үстерү;

3) туган табигатькә мәхәббәт һәм эстетик хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** "Ап-ак чәчәкләр" җырының аудиоязмасы (А. Нибаев сүзләре, Ш. Колбарисов көе.) Белмәмеш (курчак), кыш билгеләре сурәтләнгән картина, кыш сурәтләнгән 3 рәсем, җәй сурәтләнгән 1 рәсем, хаталар белән ясалган рәсем (каен агачында сары яфраклар бар; чыршы төбендә гөмбә үскән,

куак соры төстә; тузганак чәчәк аткан), балалар санынча рәсем ясау өчен зәңгәр фондагы кәгазь битләре, төсле буяулар, пумалалар.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, безгә бүген кунакка Белмәмеш килгән.

Белмәмеш. Исәнмесез, балалар! *(Исәнме, Белмәмеш!)*

Тәрбияче. Балалар, Белмәмеш ел вакытлары турында бернәрсә дә белми икән. Бик беләсе килә. Балалар, ә сез кайсы ел вакытларын беләсез? *(Кыш, яз, җәй, көз.)* Бик дөрес, балалар! Балалар, сезгә кайсы ел вакыты ныграк ошый? (Балаларның җаваплары.) Ни өчен? (Балаларның җаваплары.) Балалар, Белмәмеш бик матур, күңелле бер ел вакыты турында ишетергә, шуның турында күбрәк белергә тели икән. Кайсы ел вакыты дип уйлыйсыз? Белмәмеш шушы ел вакыты турында бер табышмак ишеткән, хәзер аны сезгә дә әйтеп карый. Табышмакны игътибар белән тыңлагыз:

Белмәмеш.
Салкын да, карлы да,
Битемне чеметтерә.
Бияләйләрне кимәсәм,
Кулларны өшеттерә.

Тәрбияче. Балалар, Белмәмеш әйткән табышмак кайсы ел вакыты турында? *(Кыш турында.)* Дөрес, балалар, салкын карлы кыш турында. Белмәмешкә кышкы күренешләр турында сөйләп күрсәтәбезме? *(Әйе.)*

Белмәмеш. Рәхмәт сезгә, балалар! Сез һәрвакыт миңа булышырга тырышасыз!

Тәрбияче. Белмәмеш, син утырып тор, игътибар белән тыңла! Без балалар белән дөрес итеп кыш турында сөйләрбез. Балалар, кыш кайсы ел вакытыннан соң килә? *(Кыш көздән соң килә.)* (Балаларны активлаштыру.) Бик дөрес, салкын кыш

алтын көздән соң килә. Әйдәгез, кыш турында сөйләшик әле. (Тәрбияче кыш билгеләре сурәтләнгән картинкалар күрсәтә.) Балалар, кыш билгеләре сурәтләнгән картинкаларга карап, кыш билгеләрен искә төшерергә тырышыгыз. Кыш көне табигатьтә нинди үзгәрешләр барлыкка килә? *(Бөтен җир ак кар белән капланган, салкын, кешеләр җылы киемнәр киеп йөриләр, аю өендә кышкы йокыга талган.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Салкында кар өстеннән барганда, нинди тавыш ишетелә? *(Шыгыр-шыгыр.)* (Күмәк кабатлаулар.) Дөрес, балалар, кар шыгыр-шыгыр килә. Кар шыгырдый. (Күмәк кабатлаулар.) Балалар, кышкы буран улаганда, нинди тавыш барлыкка килә? *(У-у-у.)* (Күмәк кабатлаулар.)

Тәрбияче. Балалар, хәзер без сезнең белән уйнап алырбыз. Уен “Кайсы рәсем артык?” дип атала.

Тәрбияче җыелма кесәгә яки фланелеграфка 4 рәсем куя. Аларның өчесендә кыш, берсендә җәй билгеләре сурәтләнгән. Балалар кайсы рәсемнең артык һәм ни өчен артык булуын билгелиләр.
Тәрбияче “Ап-ак чәчәкләр” җырының аудиоязмасын куя.

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез “Ап-ак чәчәкләр” исемле җыр тыңлап, ял итеп алыйк.

Ап-ак чәчәкләр шикелле
Кар сибелә кырларга.
Их, шул мамык кар өстендә
Ауный-ауный уйнарга.

Балалар җыр җырлыйлар һәм хәрәкәтләр ясап бииләр.

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә “Рәссамның хатасын төзәт!” уенын тәкъдим итәм. Сезгә хаталары булган кыш рәсеме күрсәтәм. (Тәрбияче кыш сурәтләнгән рәсемгә көз, яз, җәй ел вакытларының берәр билгесен кертә.) Балалар, кыш рәсемендә рәссам нинди хаталар җибәргән? *(Каен агачының яфраклары сары, чыршы төбендә гөмбә үскән, тузганак чәчәк аткан.)* Булдырдыгыз, балалар! Биремне бик дөрес итеп

үтәдегез. Балалар, кышкы табигать бик матур. Бөтен җир ап-ак кар белән капланган. Кар кояш нурларында җем-җем итеп тора. Һава саф. Сулаган саен сулыйсы килә. Әйдәгез, шушы матур карлы кышның рәсемен ясап карагыз. Хәзер мин сезгә зәңгәр төстәге кәгазьләр бирәм. Сез шул кәгазь битендә кыш рәсеме ясагыз. (Балалар музыка астында кыш рәсеме ясыйлар.)

Белмәмеш. Балалар, миңа бүген сезнең белән бик рәхәт булды! Сез кыш турында бик күп беләсез һәм кышны бик яратасыз икән! Кыш турында ясаган рәсемнәрегез матур һәм кызык. Сез миңа бүген бик тә ошадыгыз. Мин әле тагын килермен! Сау булып торыгыз! Хушыгыз!

## Тема: КАР БАБАЙ

**Бурычлар:**

1) балаларның кышкы күренешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү; геометрик фигураларның – түгәрәкнең, өчпочмакның атамасын ныгыту; детальләрне зурлыгы буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, фикерләвен үстерү;

3) балаларда уңай эмоциональ халәт булдыру, эстетик хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “тылсымлы тартма”, аның эчендә: хат, җиләк, чана, кар бабай, гөмбәләр, чәчәкләр, панама, кышкы башлык, бияләйләр рәсемнәре (аерым), П. Чайковскийның «Детский альбом» сериясеннән «Январь» әсәренең аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, хәерле көн! Кәефләрегез ничек? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, урамда суыкмы, әллә җылымы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе, суык, ни өчен икән? Хәзер елның кайсы вакыты? *(Кыш.)*

(Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Урамда кыш икәнен каян белергә мөмкин? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе, урамда ап-ак кар, көннәр суык. Сез кыш көне урамда йөрергә яратасызмы? (Балаларны активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Ни өчен? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Кыш көне сез урамда нинди уеннар уйныйсыз, нишлисез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, ә кардан сез нәрсәләр ясыйсыз? *(Кар бабай.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, бүген без сезнең белән Кар бабайның рәсемен ясарбыз. Балалар, ул нинди өлешләрдән, фигуралардан тора? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе, балалар, ул түгәрәкләрдән тора. Зурлыклары буенча ул түгәрәкләр бертөрлеме? *(Юк.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе, башта кечкенәрәк түгәрәкне ясыйбыз, аннан соң зуррагын, аннан соң иң зурысын ясыйбыз. Балалар, Кар бабайның күзләрен нинди төс белән, ничек итеп ясыйбыз? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе, аның күзләре ике кечкенә түгәрәктән тора. Ә борынын ничек ясыйбыз? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, балалар, Кар бабайның борыны кызыл төстәге кечкенә өчпочмактан тора. Ә хәзер матур музыка астында Кар бабайны үзегез ясап карагыз.

Балалар үрнәк буенча Кар бабай рәсеме ясыйлар. Шул вакыт П. Чайковскийның «Детский альбом» сериясеннән «Январь» әсәренең аудиоязмасы яңгырый.

Тәрбияче. Балалар, рәсемнәрегез бигрәк матур булган, кич белән эти-әниләрегезгә күрсәтербез. Балалар, сез рәсем ясаганда, Йомшаккай бер “тылсымлы тартма” калдырды. Әйдәгез, тартманы ачып карыйк әле. Балалар, монда бик күп рәсемнәр, янында хаты да бар. (Тәрбияче хатны укый.) Әйдәгез хатны укыйк әле: “Исәнмесез, балалар! Минем сезгә зур үтенечем бар иде. Мин сезгә рәсемнәр җибәрәм. Ул рәсемнәрдә төрле предметлар ясалган, ләкин мин аларның кайсысының кыш темасына туры килүен белмим. Ярдәм итсәгез иде. Зур рәхмәт әйтеп, Йомшаккай”. Балалар, Йомшаккай бигрәк

тәрбияле, ул ягымлы сүзләр белән хат язып җибәргән, аңа булышабызмы? (Балаларның җаваплары.)

Тәрбияче балаларга җиләк, чана, Кар бабай, гөмбәләр, чәчәкләр, панама, кышкы башлык, бияләйләр рәсемнәре күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, бу рәсемнәрнең кайсысы кыш фасылына туры килә? *(Чана, Кар бабай, кышкы башлык, бияләйләр.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Булдырдыгыз, балалар! Йомшаккай бик сөенер, сезгә рәхмәт әйтер. Балалар, без сезнең белән нәрсәләр турында сөйләштек? Сезгә ошадымы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Булдырдыгыз, балалар! Әйдәгез, башлыкларны, бияләйләрне, итекләрне киеп, чаналарны алып, урамга чыгабыз.

## Тема: ҖӘНЛЕКЛӘР КЫШКА ӘЗЕРЛӘНӘ

**Бурычлар:**

1) балаларны җәнлекләрнең кышкы табигатьтә яшәү рәвеше белән таныштыруны дәвам итү;

2) балаларның грамматик яктан дөрес сөйләмен үстерү;

3) балаларда тере табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Куян уенчыгы.

### Эшчәнлек барышы

Җәй көне урман аланында җәнлекләр җыелган. Ала карга агач башында утырган, куян, тиен, аю сурәтләнгән сюжетлы картина.

Тәрбияче. Балалар, сез бүген балалар бакчасына нинди киемнәр киеп килдегез? *(Җылы киемнәр кидек.)* (Балаларны активлаштыру.)

Тәрбияче балаларга бер-берсенең өске киемнәрен карарга тәкъдим итә. Кемнеңдер тун, кемнеңдер пуховик киеп килүе ачыклана.

Тәрбияче. Балалар, кышын урманда яши торган җәнлекләрнең киемнәре бармы икән? *(Юк.)* (Балаларны активлаштыру.) Киемнәре дә булмагач, җәнлекләрне нәрсә җылыта? *(Аларны тиреләре җылыта.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар җәнлекләрнең тиреләре бик җылы. Әйдәгез, "тире" сүзен бергәләп кабатлагыз. *(Тире.)* (Балаларны активлаштыру.) Бик яхшы! Тиредән туннар тегәләр. Аларны кешеләр кыш көне киеп йөриләр. Тиредән тегелгән туннар җылы була. Җәнлекләр үзләренең туннарын кайчан да булса салалармы икән? *(Юк.)* (Балаларны активлаштыру.) Хәзер мин сезгә кызу җәй көнендә урманда булган бер вакыйга сөйлим. Җәнлекләр җәй көнендә урман аланына җыелганнар да, көн кызуыннан зарлана башлаганнар. Моны агач ботагында утырган Ала карга ишетеп алган да, көләргә тотынган: "Җәнлекләр, кызу булмасын өчен, сезгә туннарыгызны салырга кирәк", – дигән. Җәнлекләр аптыраушта калганнар. Бәлки чыннан да җылы туннарны салыргадыр? Беренчеләрдән булып Тиен сүз башлаган. Ул: "Мин тунымны салмыйм, туным мине энәләре кадый торган чыршы ботакларыннан саклый", – ди. "Ә минем туным кура җиләклектә чебен-черкиләрдән саклый", – дип ышанычлы итеп әйтеп куйган Аю. Куян да сүзсез калмаган: "Минем соры туным җир өстеннән күренми, шуңа күрә аучы да мине күрми кала", – ди. Шулай итеп бер генә җәнлек тә тунын салырга теләмәгән. Чөнки җәнлекләрнең туннары аларны дошманнардан саклый һәм яшерә.

Менә җәй үтеп киткән, җәй артыннан көз дә үтеп киткән һәм салкын кыш килгән. Чебен-черкиләр дә очмый башлаган, җир өсте ак кар белән капланган. Шулай булса да, җәнлекләр туннарын салырга теләмиләр. Балалар, ни өчен җәнлекләр туннарын кыш көне дә салырга теләмиләр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Җәнлекләр кышын да, җәен дә бер төрле тун "киеп" йөриләрме? Әллә аларның туннары үзгәрәме? (Балаларның җаваплары.) Кыш көне Аю йокыга тала. Аңа тун ни өчен кирәк икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны

активлаштыру.) Көн буе чабып йөри торган бүрегә тун нәрсәгә кирәк икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) “Җәен соры, кышын ак”, – дип кайсы җәнлек турында әйтәләр? *(Куян.)* (Балаларны активлаштыру.) Куян ни өчен кышын соры тунын “салып”, ак тунын “кия” икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, тикшереп карыйк әле, барлык җәнлекләр дә туннарын кигәннәрме икән?

“Кайсы җәнлекнең туны нинди?” уены үткәрелә.

Тәрбияче. Җәнлекләргә туннары бик кирәк. Җәй көне алар матур иде, ә кыш көне алар тагын да ... *(матуррак, җылырак.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, монда бер җәнлек килгән. Ул сезнең янга керергә тели. (Тәрбияче уенчык куян алып керә.) Бу нәрсә? *(Куян.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, бу Куян. (Балалар Куян белән исәнләшәләр.) Балалар, куян кайда яши? *(Урманда.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, Куян кыргый җәнлек. Ул урманда яши. Сезнең янга килү, аның өчен бик кызык. Ул сезнең белән уйнарга тели.

Ап-ак куян утыра *(балалар чүгәләп утыралар),*
Колакларын селкетә *(Куян колакларын ясап, кулларын башка куялар һәм селкетәләр).*
Менә шулай, менә шулай,
Колакларын селкетә,
Аңа тик тору кыен,
Җылыта ул тәпиен *(кулларын сыйпыйлар, уалар).*
Һап, һап, һап *(кулларын чәбәклиләр).*
Җылыта ул тәпиен,
Куян тик торса туңа.
Сикергәли ул шуңа *(сикерәләр).*
Һап, һап, һап *(кулларын чәбәклиләр).*

Булдырдыгыз, балалар! Сез бүген бик актив булдыгыз.

## Тема: ҖӘНЛЕКЛӘР КЫШКЫ УРМАНДА

**Бурычлар:**

1) балаларның кыргый хайваннар турындагы күзаллауларын формалаштыру, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту;

2) бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;

3) хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** урман макеты (макетта тиен агач куышында, аю өнендә, төлке куак астында, куян кар өеме артында, керпе оясында ясалган), кар өеме артыннан төлке, тиен, бүре койрыгы, куян колаклары, поши мөгезләре күренеп торган картинка, "Ак куян" җырының аудиоязмасы (М. Бикбова сүзләре һәм көе.)

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, нинди матур тартма! Аның эчендә нәрсәдер бар. Нәрсә икән? Табышмакка дөрес итеп җавап бирсәгез, нәрсә икәнен белерсез:

Ак мамык кебек
Ялтырый алмаз кебек. *(Кар бөртеге)*

Бик дөрес, балалар, кар бөртеге. (Тәрбияче тартма эченнән кар бөртеге алып күрсәтә.) Балалар, күрәсезме, нинди матур кар бөртеге! Хәзер игътибарлы булыгыз. Кар бөртеге кемнең җилкәсенә куна, шул кыш турында нинди дә булса сүз әйтә. *(Суык, кар, боз, буран, шугалак, чаңгы, чана, тимераяк, тау һ. б.).* Булдырдыгыз, балалар, кыш турында бик матур сүзләр беләсез икән. Хәзер без сезнең белән кышкы урманга сәяхәткә барабыз. Күзләрегезне йомыгыз! (Музыка яңгырый, тәрбияче кышкы урман макеты күрсәтә.) Балалар, без кая килеп чыктык? *(Урманга.)* Дөрес, балалар, без сезнең белән кышкы урманда. (Балаларны активлаштыру.) Нинди матур кышкы урман! Бөтен

җир йомшак ак кар белән капланган. Урманда тып-тыныч. Әйдәгез, урман тынычлыгын тыңлап карыйк әле. Тып-тыныч кына тыңлагыз. Берәр нинди тавыш килмиме? (Балаларның җаваплары.) Тирән итеп урманның саф һавасын сулагыз. Салкын урман һавасын тоярга тырышыгыз. Урман һавасы бик файдалы, ул борыннарны ярып керә. Бик яхшы! Балалар, урманда нинди хайваннар яши? *(Куян, бүре, аю, төлке, тиен, керпе, поши.)* Бер сүз белән бу хайваннарны ничек дип атыйлар? *(Кыргый хайваннар.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә икенче төрле хайваннарны тагын нәрсә дип атыйлар? *(Җәнлекләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, кыргый хайваннарны кыргый җәнлекләр дияргә дә була. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, сез санап киткән кыргый хайваннарның барысын да кышын урманда күреп буламы? *(Юк.)* Ни өчен шулай уйлыйсыз? *(Аю белән керпе кыш көне йоклыйлар.)* Балалар, карагыз әле монда, бу нинди маҗара?

Тәрбияче картинка күрсәтә. Картинкада кар өеме артыннан төлке, тиен, бүре койрыгы, куян колаклары, поши мөгезләре күренә.

Тәрбияче. Барлык кыргый җәнлекләр дә нәрсәдәндер курыкканнар һәм качканнар: кайсысының колагы, кайсысының койрыгы гына чыгып калган. Әйдәгез, яшеренгән җәнлекләрне койрыклары, колаклары буенча танып карагыз. Балалар, бу нәрсә койрыгы? *(Төлкенеке.)* Ә бу нәрсә колаклары? *(Куянныкы.)* Бусы нәрсә койрыгы? *(Тиеннеке.)* Ә менә бу нәрсә? (Мөгезләр күрсәтә.) *(Мөгезләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Нәрсә мөгезләре икән ул? *(Пошиныкы.)* Дөрес, поши мөгезләре. (Балаларны активлаштыру.) Ә бу койрык нәрсәнеке? (*Бүренеке*.) Балалар, сез ничек уйлыйсыз, урман җәнлекләр өчен нәрсә икән ул? Урман – җәнлекләрнең өйләре дип әйтергә буламы? *(Була.)* Әйе, урман җәнлеккә өй кебек. Урман җәнлекләрне яшәтә, ашата, саклый. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, урман җәнлекләрнең өе булса да, һәрбер җәнлек урманда үзенең өен ясый. Кайсы җәнлек кайда яши икән, карыйк әле.

Урман макетына якын киләләр. Макетта тиен агач куышында, аю өнендә, төлке куак астында, куян кар өеме артында, керпе оясында (өнендә) ясалган. Балалар кайсы җәнлекнең кайда булуын әйтеп чыгалар.

Тәрбияче. Балалар, һәрбер җәнлек үзенчә хәрәкәтләнә. Төлке ничек хәрәкәтләнә? *(Йөгерә.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйдәгез, куян булып сикереп күрсәтегез. Хәзер аю кебек алпан-тилпән йөреп алыгыз. Балалар, нәрсәдер кыштырдый. (Кыштырдаган тавыш ишетелә.) Ишетеләме? Нәрсә икән ул? Нәрсә бу? *(Тиенгә күрсәтә.) (Тиен.)* Әйе, тиен икән. Балалар, тиеннең туны нинди төстә? *(Соры.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә җәй көне ул нинди төстә иде? *(Җирән, кызыл, сары.)* (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен соң тиеннең йоны төсен үзгәрткән? (Балаларның җаваплары.) Дөрес, балалар, тиен көз көне җирән төстәге йонын коя, аның урынына яңа – соры төстәге куе йон чыга. Йонының төсе үзгәргәч, агачлар арасыннан аны бик күреп булмый. Ул шулай итеп дошманнарыннан саклана. Куе һәм җылы йон аны кышкы салкыннарда туңдырмый. Тиен үзенең агачтагы куышына керә дә, йонлач койрыгы белән ябына һәм аңа бернинди салкыннар да куркыныч түгел. Агач куышында тиен көз көне җыеп куйган гөмбәләр, чикләвекләр бар. Ул шулар белән туклана. Балалар, тагын бер җәнлек бар монда. Табышмак әйтәм, тыңлагыз:

Өстенә ул энәле күлмәк кия,
Шулай да аны әнисе “йомшаккаем” дип сөя.

Нәрсә ул, балалар? *(Керпе.)* Керпене йокысыннан уяттык бугай, фыр-фыр килә. Керпе көз ахырында йомгак булып йомарлана да үләннәр, яфраклар белән түшәлгән җылы оясында йокыга тала. Ул кыш буе йоклый. Көз көне, йокыга талганчы, ул туйганчы ашый. Тиресе астында май катламы барлыкка килә. Шуңа күрә ул ач түгел. Яз көне, көннәр җылынгач, керпе йокыдан уяна. Әйдәгез, бармакларны хәрәкәтләндереп уйнап алыйк, урманны сәламлик!

Урман.
Саумы, тылсымлы урман!
Сиңа сокланып торам!

Ике кулны күтәреп, учларны үзләренә каратып бармакларны турайталар.

Тәрбияче. Балалар, кыш көне тагын кайсы җәнлек йокыга тала? *(Аю.)* Дөрес, балалар. Аю кайда йоклый? *(Өнендә.)* Әйе, аю өнендә бик каты йокыга тала, аны уятырга ярамый. Аю кыш көненә үзенә азык әзерлиме? *(Юк.)* Аю ашамыйча ничек яши икән соң? (Балаларның җаваплары.) Әйе, аю көздән күп итеп ашый һәм эчә, шулай итеп тиресе астына май катламы җыя. Аюның төп эше – каты йокыга талу һәм яз килгәнен көтү. Балалар, куак астында нечкә билле, көлтә койрыклы бер җәнлек утыра. Ул нәрсә? *(Төлке.)* Төлкенең йоны җирән төстә. Аның төсе кышын да, җәен дә үзгәрми. Төлкегә башка җәнлекләрдән качарга, сакланырга кирәкми, чөнки ул – ерткыч. (Балаларны активлаштыру.) Кыш көне төлкегә дә яңа калын йон үсә. Шул йон аны салкыннан саклый. Төлке кайда яши? *(Оясында, өнендә.)* Әйе, төлке җирне казып оя ясый. Шунда ял итә, йоклый. Аннары ауга чыга. Төлке кайсы җәнлекне аулый? *(Куянны.)* Дөрес, балалар. Менә кар өеме артында куян тора. Куян кышка ничек әзерләнә соң? *(Соры тунын сала, ак тун кия.)* Ни өчен ул соры тунын ак тунга алмаштыра? *(Төлке, башка ерткыч хайваннар күрмәсен өчен.)* Дөрес, куян шулай итеп ерткычлардан саклана. Ул кар өеме артына кача, күзләрен йомып, колакларын кысып, тыныч кына утыра. Шулай утырганда ул ак кар йомарламына охшап кала. Нәрсәгә охшый? *(Ак кар йомарламына охшый.)* Балалар, сез ничек уйлыйсыз, куяннар кышын азык әзерлиме? (*Юк*.) Дөрес, балалар. Куяннар кышын агач ботакларын, агач кайрыларын кимерәләр, кар астыннан тамырчыклар эзлиләр. Әйдәгез, “Ак куян” җырын тыңлыйк һәм бергәләп биеп алыйк. (М. Бикбова сүзләре һәм көе.)

Балалар җыр сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Сез бүген нәрсә белдегез? (Балаларның җаваплары.) Мин сезнең барыгызга да матур көн телим!

## *Җиденче бүлек.*
## ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

### Тема: *БЕЗ – СОЛДАТЛАР*

**Бурычлар:**

1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру; очкычның (самолёт), вертолётның өлешләрен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; солдат, очучы, диңгезче, очкыч, вертолёт, кораб сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын үстерү;

3) балаларда очучы, диңгезче, хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләре, малайларда көчле, кыю булу теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Г. Нигъмәтҗанов көенә һәм Ш. Маннапов сүзләренә язылган "Солдатта булган диләр" җырының аудиоязмасы, кызлар тарафыннан малайлар өчен алдан әзерләгән бүләкләр, мольберт, А4 форматында аерым самолёт, вертолёт һәм кораб рәсемнәре, җилем, балалар санынча А5 форматындагы кәгазь битләре, кораб ясау өчен төсле кәгазьләр.

### Эшчәнлек барышы

Г. Нигъмәтҗанов көенә һәм Ш. Маннапов сүзләренә язылган "Солдатта булган диләр" җырының аудиоязмасының бер өлеше яңгырый.

Тәрбияче. Кадерле балалар, барыгызга да матур көн телим! Балалар, бу нинди матур җыр яңгырый? Ни өчен безнең

бүлмәбез шундый матур итеп бизәлгән икән? Ничек уйлыйсыз? *(Бүген әтиләр бәйрәме.)* Дөрес, бүген әтиләр бәйрәме. (Балаларны активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, 23 февраль көнне безнең илебез Ватанны саклаучылар бәйрәмен билгеләп үтә. Бу көнне солдатларны, командирларны, безнең әтиләрне, бабаларыбызны – барлык Ватанны саклаучыларны, армиядә хезмәт итүчеләрне котлыйлар. Ә тагын безнең төркемдәге малайларны – булачак ил сакчыларын да котлыйбыз. (Кыз балаларны активлаштыру.) Малайлар, барыгыз да басыгыз әле. Сезне чын күңелдән Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз. Сәламәт, кыю, батыр, көчле булып үсегез! Бездән кечкенә генә бүләкләр кабул итеп алыгыз.

Кызлар алдан әзерләгән бүләкләр тапшыралар.

Тәрбияче. Балалар, Ватанны саклаучылар нинди булырга тиеш? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, балалар, алар көчле, кыю, гадел, үз сүзендә тора белүче булырга тиеш. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: көчле, кыю, гадел, үз сүзендә тора белүче. (Балаларны активлаштыру.) Малайлар, ә сезнең көчле, кыю, гадел, үз сүзендә тора белүче буласыгыз киләме? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, әйдәгез сезнең белән өйрәнгән “Солдатта булган диләр” җырын җырлыйк.

Билен кысып буган, диләр,  
Бигрәк тә уңган, диләр;  
Әллә каян күренеп тора –  
Солдатта булган, диләр.

Кечеләрне кече итәр,  
Олыны зурлар, диләр.  
Әллә каян күренеп тора –  
Солдатта булган, диләр.

Комбинезон алган, диләр,
Шинелен салган, диләр.
Шинелен салса да, солдат
Гадәте калган, диләр.

Тәрбияче. Балалар, булдырдыгыз! Менә солдатлар нинди була икән! Ә хәзер бер табышмакка җавап табыгыз әле.

Канаты бар – җилпеми,
Эче җылы – җил тими.
Корыч йөрәкле кош ул,
Безнең яраткан дус ул. (*Самолёт.*)

Дөрес, балалар.

Тәрбияче мольбертка самолёт һәм вертолёт рәсемнәрен куя.

Тәрбияче. Балалар, бу рәсемнәрдә сез нәрсә күрәсез? *(Очкычлар* (*самолёт), вертолёт.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, әйдәгез бу рәсемнәрне карыйк әле. Бу очкычның (самолётның) нәрсәсе? *(Кабинасы.)* (Балаларны активлаштыру.) Очкыч (самолёт) кабинасында кем утыра (*Очучы утыра.*) (Балаларны активлаштыру.) Очкычның (самолётның) кошларныкы кебек нәрсәсе бар? *(Канатлары бар.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә монысы очкычның (самолётның) нәрсәсе? *(Койрыгы.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Ә хәзер бу рәсемне карыйк. Бу нәрсә? (*Вертолёт.*) (Балаларны активлаштыру.) Бу нәрсә? *(Кабина.)* (Балаларны активлаштыру.) Вертолёт кабинасында кем утыра? *(Очучы утыра.)* (Балаларны активлаштыру.) Вертолётның кошларныкы кебек нәрсәләре бар? *(Канатлары бар.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә монысы вертолётның нинди өлеше? *(Койрыгы.)* Балалар, вертолёт белән очкыч (самолёт) охшаганнармы? (Балаларның җаваплары.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, алар охшаганнар, ләкин аларның аермасы да бар. Нинди аерма икән? (Балаларның җаваплары.)

(Балаларны активлаштыру.) Әйе балалар, очкычтан (самолёттан) аермалы буларак, вертолётның пропеллере бар. Әйдәгез, бергә кабатлыйк: пропеллер. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, безнең илебезнең һава чикләрен очкычлар (самолётлар) һәм вертолётлар белән саклыйлар. Очкыч (самолёт) һәм вертолёт йөртүчеләрне ничек атыйлар? (*Очучылар.)* (Балаларны активлаштыру.) Очучылар сәламәт, кыю, акыллы булырга тиешләр. Әйдәгез, сез дә очучылар булырсыз, уйнап алабыз. Очучылар! Очкычларга (самолётларга), вертолётларга “утырыгыз”! (Балалар, кулларын як-якка сузып, “очкыч” булып “очалар”.) Булдырдыгыз! Балалар, мин сезгә бер шигырь укыйм.

Тасмалы фуражкасы
Бик килешә үзенә,
Ә якасы охшаган
Матур зәңгәр күзенә.
Кызыл флотчы абый
Бүген бездә ял итә.
Иртәгә хезмәтенә –
Ерак диңгезгә китә.

Кем турында икән бу шигырь? (Балаларның җаваплары.) Әйе, балалар, монда сүз диңгезче турында бара. Балалар, диңгезчеләр диңгез чикләрен саклыйлар. Бергәләп кабатлыйк: диңгезчеләр диңгез чикләрен саклыйлар. (Балаларны активлаштыру.) Диңгезләрдә, океаннарда су өстендә һәм су астында хәрби корабларда диңгезчеләр илебезне саклыйлар. Балалар, әйдәгез без дә сезнең белән кораблар ясыйк. (Тәрбияче кораб рәсеме күрсәтә.) Балалар, бу рәсемдә сез нәрсә күрәсез? *(Кораб.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар башта корабның көймә өлешен ябыштырабыз, менә ул. Ә монысы җилкәне. Ә иң очына флаг ябыштырырбыз. (Төсле кәгазьләрдән ябыштырып кораблар ясыйлар.) Булдырдыгыз, балалар! Эшләрегез бигрәк матур булды, без аларны әтиләргә, бабайларга, абыйларга бүләк итәрбез. Балалар, барыгыз да

кулга кул тотынышып түгәрәккә басыгыз, кулларыгызның җылысын бер-берегезгә бүләк итегез. Бер-берегезгә карап елмаегыз, сәламәтлек теләгез! Булдырдыгыз, балалар! Без бүген солдатлар, очучылар, диңгезчеләр турында күп нәрсә белдек. Мин сездән бик канәгать! Рәхмәт сезгә!

## Тема: БЕЗНЕҢ АРМИЯ

**Бурычлар:**

1) балаларда илне саклаучы сугышчылар турында күзаллау формалаштыру; “Ватанны саклаучылар” төшенчәсен ачыклау; кайбер хәрби һөнәрләр (диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчысы) белән таныштыру;

2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын үстерү;

3) хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчылары төшкән рәсемнәр (алар үзләренә хас булган эш гамәлләрен башкаралар), һәр гаскәрнең баш киемнәре (пилотка, шлем, бескозырка, зәңгәр һәм яшел фуражкалар), Россия армиясенең макеты.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безнең бүлмә бәйрәмчә бизәлгән: флажоклар, плакатлар эленгән, әтиләргә багышлап газета чыгарылган. Ни өчен шундый бәйрәмчә һәм тантаналы атмосфера бүген төркемдә? *(Иртәгә бабайлар, әтиләр бәйрәме, Ватанны саклаучылар бәйрәме.)* Булдырдыгыз. Әйе, иртәгә бәйрәм. Безнең халкыбыз Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтәчәк. Бу безнең илебезне дошманнардан саклаган кешеләр һәм бүгенге көндә Россия армиясендә хезмәт итүче солдатлар бәйрәме. Һәр илнең армиясе бар. Армия үз Ватанын сакларга тиеш. Безнең илнең дә үз армиясе бар. Безнең армия зур һәм көчле.

Тәрбияче балаларга иллюстрацияләр күрсәтә. Бу рәсемнәрдә төрле төр гаскәрләрнең хәрби хезмәте сурәтләнгән: диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчылары.

Тәрбияче. Бу рәсемдә сез кемне күрәсез? Алар нәрсә эшлиләр? Ни өчен солдатларга шөгыльләнергә, тренировкаларда булырга кирәк? (Балаларның җаваплары.) Илне саклау һәм яклау өчен солдатлар нәрсә эшлиләр? (Балаларның җаваплары.) Солдатлар нинди булырга тиеш? *(Көчле, тәвәккәл, сәламәт.)* Әйе, көчле булу өчен аларга тренировкаларга йөрергә, хәрби хезмәткә өйрәнергә кирәк, алар оста итеп ата белергә, каршылыкларны җиңәргә өйрәнәләр. Солдатлар кыю, көчле булырга өйрәнәләр. Солдат булу өчен бүгеннән үк әзерләнергә кирәк. Хәзер без "Сигнальщиклар" дигән күнегү ясарбыз.

Без җирдә басып торабыз *(аяклар азрак аерылган, куллар артта.)*

Корабларда йөзәбез *(куллар алга куела һәм тиз генә артка җибәрелә.)*

Һәрвакыт сигнал бирәбез, шундый приказ безгә бирелгән *(ике кулны да аркага куялар.)*

Уңга борыл *(баш уңга борыла, уң кул аркага куела.)*

Сулга борыл *(Баш сулга борыла, сул кул аркага куела.)*

Йоклама, сигнал бирергә онытма! *(катып калырга: смирно.)*

Балалар, һәр гаскәр төренең хәрби киеме бар. Өстәлдә хәрбиләрнең баш киемнәре ята. Әйдәгез, аларның кемнеке икәнен билгелик. Шлем кемгә ... *(танкистка.)* Бескозырка кемгә ... *(диңгезчегә.)* Пилотка кемгә ... *(солдатка.)* Яшел фуражка кемгә ... *(чик сакчысына.)* Зәңгәр фуражка кемгә ... *(очучыга.)* Булдырдыгыз.

Тәрбияче балаларга өстәлдә яткан баш киемнәрен кидерә. Дүрт бала Ш. Галиевнең "Бусы – хәрби сер" исемле шигырен сөйлиләр.

Еракта-еракта тора, минем абый сакта тора,
Әни эштә чакта тора, әти юлда чакта тора,

Мин уйнаган чакта тора, син йоклаган чакта тора!
Телевизор да карамый, читкә карарга ярамый,
Чиккә генә карап тора, дошман килеп кермәсен, ди,
Безнең серне белмәсен, ди.
Әниләр эштә булганда, берүзең генә калганда,
Түгел өйне саклап тору, бу бит – илне саклап тору!
Еракта-еракта тора, минем абый сакта тора.
Сакта һәр-һәр чакта тора, әйтмим, кайсы якта тора,
Син үзең дә сорап торма, бусы – хәрби сер!

Тәрбияче. Балалар, безнең солдатларга ярдәмгә техника килә. Кем әйтә, гаскәрләр нинди техника белән эшлиләр? *(Самолётлар, корабльләр, танклар, пушкалар, ракеталар.)* (Тәрбияче балалар атаган техниканың рәсемнәрен күрсәтә.) Бер сүз белән боларны хәрби техника дип атыйлар. (Балаларны активлаштыру.)

Тәрбияче балалар белән “Россия армиясе” дигән макет төзи. Балалар башта хәрби техниканы билгеләнеше буенча куялар. Макетта зәңгәр төс белән диңгез билгеләнә, яшел төс белән – коры җир, күк (голубой) төс белән – һава. Балалар биремне үтиләр. Аннан соң тәрбияче хәрбиләрнең фигурасын тиешле булган хәрби техника янына куярга куша.

Тәрбияче. Очкыч янына ... *(очучы)* килде. Танк янына ... *(танкист)* басты. Һавадан парашютта ... *(парашютчы)* төште. Кораб янында... *(диңгезчеләр)* тора. Машинага ... *(солдатлар)* утырган. Дәүләт чиген ... *(чик сакчылары)* саклый. Балалар, карагыз әле, нинди матур макет барлыкка килде. Төрле гаскәре булган армия – көчле армия. Ул үз илен диңгездә дә, коры җирдә дә, һавада да саклый ала.

## Тема: БАКЧАБЫЗНЫҢ БАЛТА ОСТАСЫ

**Бурычлар:**

1) балаларны олылар хезмәте белән таныштыруны дәвам итү (балта остасы хезмәте); хезмәт кораллары турындагы белемнәрен ныгыту;

2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү, хезмәт коралларын классификацияләү осталыгын, игътибарын, олылар хезмәтенә карата кызыксынуын үстерү;

3) өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** балта остасының эш кораллары, төрле һөнәр вәкилләре сурәтләнгән карточкалар (6 балта остасы, табиб, кибетче, шофёр, төзүче, укытучы), аларның эш кораллары сурәтләнгән 24 кечкенә карточка.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, ишетәсезме, кем шаулый анда? Айрат, Әмир, Алсу, сез шауламыйсызмы анда? Кем икән ул? (Тәрбияче уен почмагына бара, тыңлап карый.) Балалар, уенчыклар шаулый икән – курчаклар Таһир белән Гүзәл, клоуннар Гали белән Вәли. Алар нәрсәдер бүлә алмыйлар. Уенчыклар, сез нигә шаулыйсыз? (Тәрбияче бер уенчыкны колагына китерә, балаларга мөрәҗәгать итә.) Уен почмагында аларга утырырга җиһаз җитми. Ни эшләргә? Безнең уенчыкларга ничек итеп ярдәм итәргә? Балалар бакчасында эшләүче хезмәткәрләр булыша аламы? (Балаларның җаваплары.) Хәзер мин сезгә бер шигырь укыйм. Тыңлагыз.

Үстең инде, улым, дип,
Эш өйрәнсен кулың, дип,
Әти чүкеч тоттырды,
Бер кадакка суктырды.
Суктым ике, суктым өч,
Дүртенчегә бетте көч.
Көч беткәнен сизептер,

Бармакка төште чүкеч.
Әти сукса, нык суга,
Кадактан да ут чыга,
Каян килә мондый көч? –
Тылсымлыдыр бу чүкеч.

Балалар, сез кемнең кулында чүкеч, кадак күргәнегез бар? (Балаларның җаваплары.) Сез дөрес әйтәсез, аларны безнең балта остасы (плотник) Камил абыйның кулында күрергә була. Балалар, ул эшләгәндә, аңа нинди предметлар ярдәмгә килә? *(Чүкеч, кадак, каргаборын (плоскогупцы), пычкы.)* (Тәрбияче балаларга эш коралларын күрсәтә.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар бакчасында Камил абый нинди эшләр башкара? *(Ул җиһазны ремонтлый, өстәлләрне, урындыкларны ныгыта, тумбочкага ишек тоткасын беркетә, стенага картиналар элә, шкафларның ишеген ныгыта.)* (Балаларны активлаштыру.) Менә нинди безнең Камил абыебыз! Ул бөтен эшне эшли белә. Саныйк әле, Камил абый нинди? *(Тырыш, эш сөючән, оста эшләүче, пөхтә, игътибарлы, үзенең эшен ярата, җиһаз ватылса, шунда ук ярдәмгә килә.)* Дөрес, балалар, Камил абыйның бик матур сыйфатлары бар: ул ягымлы, игътибарлы, авыр чакта ярдәмгә килә, балалар бакчасында эшләүчеләргә булыша. Ул яхшы иптәш, хезмәткәр. Балалар, “Гаилә” уенында безгә кирәкле булган диванны да Камил абый рәтләп бирде. Ул аны пөхтә итеп эшләде. Безнең Камил абый үз эшенең остасы, тырыш кеше. Балалар, бүлмә буйлап йөрик әле, җиһазларга карагыз, группада нәрсәне ремонтларга кирәк икән? (Балаларның җаваплары.) Группадагы җиһазны кем ремонтлый? (Балаларның җаваплары.) Әйе, безгә Камил абыйны чакырырга кирәк. (Тәрбияче ярдәмчесе балта остасын чакырырга китә.) Без сезнең белән балта остасы булып алырбыз. (Тәрбияче белән бергә балта остасының гамәлләрен күрсәтәләр.) Балта остасы такта кисә. (Тәрбияче балалар белән такта кисү гамәлен күрсәтә.) Балта остасы кадакларны тактадан тартып ала. (Балалар тәрбияче артыннан

кабатлыйлар.) Балта остасы шөрепләрне стенага беркетә. Балта остасы утын яра һ. б.

Группага балта остасы керә. Балалар аңа төркемдә эшлисе эшләрне күрсәтәләр. Балта остасы балаларга эш кораллары яткан ящикны күрсәтә. Эш кораллары белән кирәкле эшне башкара. Балалар аның эшләгәнен карап торалар.

Тәрбияче. Менә, балалар, Камил абый эшен бетерде. Без аңа рәхмәт әйтик, әтиләр бәйрәме белән котлыйк.

Дүрт бала чыгып, Б. Рәхимованың "Әти бәйрәме көне" дигән шигырен сөйлиләр. Балта остасын озаталар.

Тәрбияче. Хәзер без уйнап алырбыз. Уен "Кемгә нәрсә кирәк?" дип атала. Мольбертка төрле һөнәр кешеләренең сурәтләре куелган. Кемнәр алар? *(Балта остасы, табиб, кибетче, укытучы, төзүче, шофёр.)* Сезнең өстәлдә бу һөнәр кешеләренең хезмәт кораллары ята. Аларны игътибар белән карагыз, кемгә нинди хезмәт коралы кирәк булуын күрсәтегез.

Балалар хезмәт коралларын классификацияләләр, тәрбияче эш кораллары янына төрле һөнәр кешеләренең сурәтләрен куя. Мәсәлән, балта остасын балта, чүкеч, шөреп, кадак, каргаборын янына, табибны мамык, градусник, дару, шприц, бинт янына һ. б.

## *Сигезенче бүлек.*
## 8 МАРТ

### Тема: МУЗЫКА ҖИТӘКЧЕСЕНДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) балаларның әниләр бәйрәме, әниләре турындагы белемнәрен киңәйтү, музыка җитәкчесенең links бербөтен образын тудыру; музыка коралларының төп билгеләрен ачыклау;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, диалоглы сөйләм формасын, шигырьләрне сәнгатьле сөйләү осталыгын үстерү;

3) балаларда әниләргә, музыка җитәкчесенә карата ихтирам, хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Йомшаккай – уенчык песи, картинкаларда музыка кораллары сурәтләнгән (гармун, пианино, скрипка, гитара, барабан), Р. Миңнуллинның “Әни кирәк” җыры.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Кадерле балалар, бүген безгә кунакка Йомшаккай килде. Исәнләшик әле аның белән. Балалар, Йомшаккай сездән болай дип сорый: Сез музыка, җырлар яратасызмы? Нинди музыканы тыңларга яратасыз? Җырларны, музыканы сез кайда тыңлыйсыз? Музыка коралларында кем уйный? Кем сезнең белән бергә уйный һәм җырлый? (Балаларның җаваплары.) Карагыз әле. Йомшаккай безгә картинкалар алып килгән. Нәрсәләр сурәтләнгән анда?

Тәрбияче балаларга музыка кораллары (барабан, гармун, гитара, пианино, скрипка) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә. Музыка кораллары турында әңгәмә үткәрә.

Тәрбияче. Бу музыка уен коралы ничек атала. *(Барабан.)* (Балаларны активлаштыру.) Барабан нинди өлешләрдән тора? *(Барабанның өсте, асты бар, тавыш чыгару өчен таякчыклары бар.)* (Балаларны активлаштыру.) Барабанны нинди материалдан ясаганнар? *(Пластмассадан.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, барабан уйнаганда, кешеләр нишли? *(Маршка басып йөриләр.)* (Балаларны активлаштыру.) (Башка музыка уен кораллары белән дә шундый әңгәмә үткәрелә.) Булдырдыгыз, балалар. Сез дөрес итеп җавап бирдегез. Музыка уен кораллары музыка залында күп. Әйдәгез, залга музыка җитәкчесе янына кунакка барабыз. Йомшаккай да безнең белән барсын.

Балалар һәм тәрбияче музыка залына керәләр, аларны музыка җитәкчесе каршы ала. Залны күрсәтә, кечкенә экскурсия үткәрә. Балалар музыка уен коралларын, дидактик материалларны, пианиноны, урындыкларны һ. б. карыйлар.

Тәрбияче. Балалар, безнең музыка җитәкчесе Зәйтүнә апа өйдә дә музыка коралында уйный. Аның өйдә гаиләсе бар. (Музыка җитәкчесе гаиләсе, улы турында сөйли. Улына ул өйдә җырлар җырлый, аның белән уйный.) Зәйтүнә апа өйдә тагын ниләр эшли икән, уйлап карагыз әле. (Балаларның җаваплары.) Менә нинди безнең Зәйтүнә апабыз! Ул музыка җитәкчесе генә түгел, ул улының әнисе дә, иренең хатыны да. Ул тәмле итеп ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә, кер юа, үтүкли, көн саен яраткан эшенә килә, балаларга яңа җырлар, биюләр өйрәтә. Сорыйк әле Зәйтүнә ападан, теләгән һәр кеше музыкант була аламы? Әйе, музыкант булу өчен кешенең музыкаль сәләте булырга тиеш: яхшы тавышы һәм музыканы ишетү сәләте. Балалар, Зәйтүнә апага ягымлы сүзләр әйтегез әле. *(Матур, ягымлы, акыллы, тырыш, кайгыртучан.)* Балалар, бәйрәм уңаеннан без әниләр һәм әбиләр турында шигырьләр өйрәндек. Әйдәгез, аларны Зәйтүнә апага сөйлик.

1 нче бала. Йолдызларга тиң үзләре, гүзәлләрнең гүзәле,
Миңа һәрчак сөеп карый әниемнең күзләре.
Энҗе-мәрҗәннәр диярсең – янып тора үзләре,
Миңа һәрчак бәхет тели әниемнең күзләре.

2 нче бала. Ак яулыклы, көләч йөзле,
Шат күңелле, әйбәт тә.
Кем ул, диеп сорыйсызмы?
Дәү әнием, әлбәттә.
Ярдәме гел тиеп тора
Барына да дәү әни ул,
Тәмле бәлеш пешерүче
Дәү әни безнең өйдә.
Аңардан ашарга сорый

Шаян песиебез дә.
Якын кешеләргә дә.
Барлык кешеләргә дә.

3 нче бала. Иртән торсам, кояш чыгып,
Нурларын сипкән иде.
Әбиемнең чәе кайнап,
Коймагы пешкән иде.

4 нче бала. Минем әби бик әйбәт,
Гел көлеп кенә тора.
Балакаем, дип әйтеп,
Сөеп, иркәләп тора.
Әбием һәркөн безгә
Тәмле ашлар пешерә,
Сөйкемле сүзләре белән
Безнең күңелне күрә.
Без әбине яратабыз,
Ул да безне ярата.
Безнең әбидән дә әйбәт
Кем бар икән дөньяда?

5 нче бала. Әни сүзе – иң бөек сүз,
Юк аңа һичбер алмаш.
Иң-иң әйбәт кешеләр дә
Әни кебек була алмас!

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар. Менә нихәтле матур шигырьләр беләсез сез. Йомшаккайга да сез бик ошадыгыз. Хәзер Зәйтүнә апа пианинода музыка уйнар, без “Әни кирәк” җырын җырларбыз.

Җырлап бетергәч педагог музыка җитәкчесен кунакка чакырганы, кызыклы хикәясе, күңелле музыкасы өчен рәхмәт әйтә. Балалар, саубуллашып, төркемгә кайталар.

## Тема: ӘНИЕМ ТУРЫНДА СӨЙЛИМ

**Бурычлар:**

1) бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү; әниләр турында тасвирлама төзү осталыгын формалаштыру;

2) кабул итүне, хәтерне, игътибарны, сүзлек байлыгын үстерү, сәнгатьлелек чараларын куллануда күнектерү;

3) әниләргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар**: әниләр һәм әбиләр рәсеме ясалган картинкалар, әниләрнең фотографияләре, чәчәк ясау өчен һәр балага җитәрлек таҗ яфракчыклары, чәчәкнең үзәге, “Әниләр бәйрәме” (Г. Гомәр сүзләре, М. Бикбова көе) җырының аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Балалар, кулга-кул тотынышып түгәрәккә басалар. Чиратлап бер-берсенең кулын кысалар һәм: “Исәнме, ... (исемен әйтә)! Мин сине күрүемә бик шат!” – диләр.

Тәрбияче. Балалар, күрәсезме, безгә бер зур конверт калдырып киткәннәр. (Балалар карыйлар.) Конверт эчендә нәрсә бар икән? (Конвертны ачалар.) *(Картинкалар.)* (Тәрбияче картинкаларны җыелма кесәгә куя.) Картинкаларда кемнәр сурәтләнгән? *(Әниләр һәм әбиләр.)* Сез үзегезнең әниегезне яратасызмы? (Балаларның җаваплары.) Ә әбиегезне яратасызмы? *(Яратабыз.)* Сез әниегезгә ягымлы итеп ничек эндәшәсез? *(Әнием, әнкәй.)* Ә әбиегезгә ягымлы итеп ничек эндәшәсез? *(Әбием, әбкәй.)* Балалар, ни өчен без бүген әниләр, әбиләр турында сөйләшәбез икән? *(Тиздән 8 март – әниләр бәйрәме җитә.)* (Балаларны активлаштыру.) 8 март бәйрәме турында сез нәрсә беләсез? (*8 март – хатын-кызлар бәйрәме. 8 март – әниләр, әбиләр, апалар, сеңелләр бәйрәме.*) (Балаларны активлаштыру.) 8 март бәйрәме елның кайсы вакытында үткәрелә? *(Яз көне.)* Әйе, 8 март – язның беренче бәйрәме. Сез бәйрәмгә ничек әзерләнәсез? *(Бүләкләр әзерлибез, шигырьләр,*

*җырлар, биюләр өйрәнәбез.)* (Балаларны активлаштыру.) Гадәттә, 8 мартка чәчәкләр бүләк итәләр. Бүген без дә сезнең белән әниләргә чәчәк бүләк итәрбез. Хәзер һәрберегез бер таҗ яфракчыгы алсын. (Алалар.) Әниегез турында җылы матур сүзләр әйтегез, мин ул сүзләрне таҗ яфрагына язып куям. Аннары таҗ яфракчыкларын тоташтырырбыз да тылсымлы сүзләрдән тылсымлы чәчәк килеп чыгар. (Тәрбияче чәчәккә сүзләр яза, чәчәкне җыялар.) Менә нинди чәчәк килеп чыкты. Без аны элеп куябыз. Әниләрегез килгәч карарлар. Тылсымлы чәчәктәге тылсымлы сүзләрне укып шатланырлар. Сез ничек уйлыйсыз, әни өчен иң якын кеше кем икән? Әниләрнең һәрвакытта да кәефе яхшы булсын, алар гел елмаеп торсыннар, бер дә борчылмасыннар өчен, нәрсә эшләргә кирәк? Әни кеше үзен начар хис иткәндә яки арыганда, аңа кем булыша ала? (Балаларның җаваплары.) Бик дөрес, балалар! Сез үзегез матурлык тудырасыз. Шуның белән әниләрегезгә тагын да яшьрәк, бәхетлерәк булырга ярдәм итә аласыз. Моның өчен әниләргә игътибарлырак булырга, аларны тыңларга, булдыра алганча ярдәм итәргә һәм ешрак назлы, иркәләү сүзләре әйтергә кирәк. Балалар, сездә әниләрегезнең фотографияләре бар. Сез, үз әниегезнең фотографиясен табып, аның турында сөйләп күрсәтерсез. Сезнең әниегезнең кем булуы, кайда эшләве, нинди тәмле әйберләр ягатуы безгә барыбызга да бик кызык. Әниегез турында сөйләгәч, аның фотографиясен стендка куярбыз. Һәрбер кеше сезнең әниләрегезгә карап соклансын әле! (Тәрбияче балаларны әниләре турында бергәләп сөйләргә җәлеп итә.) Алсу, әйдә, синең әниең турында сөйлик: “Минем әниемнең исеме ... (*Гөлназ)* Аның күзләре ... (*зәңгәр*), чәчләре ... *(кыска)* һ. б.”.

Балаларга сөйләү өчен план да тәкъдим итәргә була. Ул сөйләшү барышында бирелә: “Әниегезнең күзләре нинди төстә? Аның чәчләре нинди? Ул кайда эшли? Нәрсә пешерергә ярата? Буш вакытында нәрсә белән шөгыльләнә?”

Тәрбияче. Хәзер бергәләп әниләр турында җыр тыңларбыз. Сез дә кушылып җырлагыз. Биергә дә була.

(Тәрбияче “Әниләр бәйрәме” җырының (Т. Бикбова сүзләре һәм көе) аудиоязмасын куя.) Балалар, сез бүген нәрсәгә өйрәндегез? Нәрсә белдегез? Кем турында хикәя төзедегез? Нәрсә исегездә калды? (Балаларның җаваплары.) Булдырдыгыз! Мин сезнең өчен бик шат. Хәерле көн телим!

## *Тугызынчы бүлек.*
## ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

### Тема: САВЫТ-САБА

**Бурычлар:**

1) татар авылы көнкүреше белән таныштыру, хәзерге һәм элекке заманда кулланылган савыт-саба турындагы белемнәрне ныгыту;

2) кабул итүләрен, фикерләүләрен, хәтерләрен, сүзлек байлыгын үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;

3) татар халкының көнкүреш предметларына кызыксыну тәрбияләү

**Җиһазлар:** самавыр, чуен чүлмәк, чәйнек, тимер калаклар, агач кашыклар, варенье (кайнатма).

### Эшчәнлек барышы

Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәккә басалар һәм чиратлашып бер-берсенең кулын кысып: “Исәнме ... (исемен әйтә)! Мин сине күрүемә бик шат”, – диләр.

Тәрбияче. Балалар, мин бүген авылда яшәүче әби булам (яулык бәйли) һәм сезне авыл өенә кунакка чакырам. Әйдәгез, балалар, рәхим итегез, түрдән узыгыз!

Балалар алдан әзерләп куелган эскәмияләргә утыралар. Өстәлгә савыт-саба: кәстрүл, чуен, чүлмәк, самавыр, чәйнек, тимер калак, агач кашык куелган.

Тәрбияче. Карагыз, әле, минем өстәлдә нәрсә бар? *(Самавыр, чуен чүлмәк, чәйнек, калаклар,кашык, кәстрүл.)* (Балаларны активлаштыру.) Бик дөрес, балалар. Бу әйберләрнең барысын да бер сүз белән ничек әйтергә була? *(Савыт-саба.)* Савыт-саба нинди? *(Чиста, юылган, матур, ялтырый.)* Әйе, балалар, дөрес әйтәсез, савыт-сабаларымны бик яратам, шуңа күрә мин аларны чистартып, ялтыратып, юып торам. Хәзер мин сезгә табышмак әйтәм, табышмакның җавабын өстәлдән табарсыз: "Ничек кенә тырышсаң да, син аны агарта алмассың". *(Чуен чүлмәк.)* Ни өчен шулай әйтәләр? *(Ул кара төстә.)* Әйе, балалар, мин аны бик озак ышкысам да, чуен агармады. Ул пычрак түгел, үзе кара, шуңа күрә аны агартып булмый. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз! Агартып булмый. Балалар, чуен чүлмәк нинди материалдан ясалган дип уйлыйсыз? (*Чуеннан.*) Димәк, ул чуен чүлмәк. Бергәләп кабатлагыз әле. *(Чуен чүлмәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Чүлмәкнең чуен булуы әйбәт. Ни өчен икән? *(Аны мичкә куйгач, ул янмый.)* Дөрес, чуен чүлмәк нык, ватылмый. Балалар, чуеннан ясалган булгач, аның тискәре яклары да бар. Ни өчен? *(Чуен чүлмәк авыр, салкын.)* (Балаларны активлаштыру.) Салкынмы, тотып карагыз әле! (Балалар тотып карыйлар. Тәрбияче үзе чуен чүлмәкне күтәреп, аның авыр икәнен күрсәтә.) Чуен чүлмәкне мичтә тоткач, ул кыза, кулны пешерергә мөмкин. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, чүлмәк пыяладан эшләнсә, ул нинди булыр иде? *(Пыяла чүлмәк булыр иде.)* (Балаларны активлаштыру.) Чүлмәк пыяла булса, бик яхшы булыр иде. Ни өчен? *(Ул җиңел, ул матур.)* (Балаларны активлаштыру.) Пыяла чүлмәктән бөтен әйбер күренеп торыр иде. Бөтен әйбер күренеп торгач, ул нинди була инде? *(Үтә күренмәле.)* (Балаларны активлаштыру.) Бергәләп кабатлагыз әле. *(Үтә күренмәле.)* (Балаларны активлаштыру.) Чүлмәк пыяладан булса, аның тискәре ягы да бар. Ни өчен? *(Ул ватылырга мөмкин. Пыяла ватылса, кулны кисәргә мөмкин.)* Балалар, чүлмәк агачтан эшләнгән булса, ул нинди булыр иде? (*Агач чүлмәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Агач чүлмәк яхшы була. Ни өчен? (*Җылы. Агач чүлмәккә әйбер салганда*

*пешмисең.)* (Балаларны активлаштыру.) Агач чүлмәкнең тискәре ягы да булырга мөмкин. Ни өчен? *(Ул мичтә янарга мөмкин. Агач чүлмәк чыдам түгел.)* (Активлаштыру.) Шулай да чүлмәкнең чуеннан булуы яхшы. Чуен чүлмәк авыр, кулны да пешерергә мөмкин, ләкин аны мичкә куйгач, анда әйберләр тәмле булып пешә. Балалар, чуен чүлмәкне кулны пешермичә мичтән алу өчен ухват кирәк. Нәрсә кирәк? (*Ухват.)* (Балаларны активлаштыру.) (Тәрбияче балаларга ухват күрсәтә.) Балалар, сезнең әниләрегез ашны пешерә торган савыт ничек атала? *(Кәстрүл.)* (Балаларны активлаштыру.) Бигрәк кызык сүз. Балалар, сезнең өйдә тагын нинди савыт-сабалар бар? (Балаларның җаваплары.) Балалар, ничек уйлыйсыз, савыт-сабаны кайда ясыйлар? (*Заводта, фабрикада.)* (Балаларны активлаштыру.) Савыт-саба нинди материалдан ясала? *(Агачтан, тимердән, чуеннан, пыяладан, балчыктан, фарфордан.)* Савыт-сабаны авыл осталары балчыктан, тимердән, агачтан ясыйлар. Табышмак тыңлагыз һәм җавабын табыгыз: “ Үзем ашамыйм, ләкин башкаларны ашатам”. Бу нәрсә? *(Кашык.)* Карагыз әле, минем өстәлемдә дә кашыклар бар. Алар нәрсәдән ясалган? *(Агачтан.)* Әйе, агач кашыклар. Алар нинди? (*Матур, бизәкле.)* Кашыкларны халык осталары матур итеп бизәгән. Шуңа күрә алар бизәкле. Нинди? *(Бизәкле.)* (Балаларны активлаштыру.) Без авылда кашыклар белән ашап кына калмыйбыз, ә уйныйбыз да. Әйдәгез, кашыклар белән уйнап алыйк әле.

Балалар алдан әзерләнгән берәр көй уйныйлар яки мәктәптә хәзерлек төркеменә йөрүче балаларны чакырталар.

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә тагын бер табышмак әйтәм:

Эчендә су да бар, ут та бар,
Ул үзе һәр йортта бар. *(Самавыр.)*

(Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Самавыр ни өчен кирәк? *(Самавырдан чәй эчәләр.)* Ә сез өйдә чәйне нәрсәдән эчәсез? *(Чәйнектән.)* Самавырның нәрсәләре бар? (Балаларның

җаваплары.) (Балалар самавырның капкачын, төбен, тоткасын, борынын, аякларын күрсәтәләр. Самавырның ничә тоткасы, капкачы, аяклары, борыны барлыгын әйтәләр.) Бик дөрес, балалар, самавырның бер капкачы, бер борыны, ике тоткасы, дүрт аягы бар. Самавыр нәрсәдән ясалган? *(Җиздән, тимердән.)* Самавыр матурмы? (*Матур.)* Әйе, самавыр бик матур. Самавыр көзге кебек ялтырап тора. Ни өчен көзге кебек ялтырап тора дип әйтергә мөмкин? (Балаларның җаваплары.) Самавыр суы кайнагач чыжлап утыра. Самавыр "җырлый" дип тә әйтәләр. Менә безнең самавыр да чыжлый – "җырлый" башлады. Мин сезнең барыгызны да чәй эчәргә чакырам. (Кайнатма белән чәй эчәләр.)

## *Унынчы бүлек.*
## ЯЗ

### *Тема:* КАР БАБАЙ ЯЗНЫ ЭЗЛИ

**Бурычлар:**

1) балаларның ел фасыллары, кыш, яз билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнеш турындагы күзаллауларын формалаштыру; кояш, кошлар, умырзая чәчәге, җир казый, орлык чәчә кебек сүзләр һәм сүзтезмәләр хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын, фикерләвен, хәрәкәт активлыгын үстерү;

3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** А4 форматында кояш рәсеме, Җир шарының рәсеме, А3 форматында яз көне кайта торган күчмә кошлар сурәтләнгән сюжетлы картина, А3 форматында умырзая чәчәге сурәтләнгән сюжетлы картина.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, без бүген сезнең белән ел фасыллары турында сөйләшербез. Сез нинди ел фасыллары беләсез? (Балаларның җаваплары.) Балалар, ә сез ел фасыллары турында нинди мәкальләр беләсез? Әйдәгез искә төшерик әле. Җәй эшләсәң, кыш ашарсың. Кышкы кар – көзге икмәк. Көзге бозның көзге калынлыгына да ышан, язгы бозның ястык калынлыгына да ышанма. Кыш көне – арбаңны, яз көне чанаңны әзерлә. Язгы көн ел туйдыра. Балалар, ә хәзер елның кайсы вакыты? *(Яз.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз!

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче. Балалар, кем икән ул?

Тәрбияче барып ишекне карый, Кар бабай керә.

Тәрбияче. Исәнме, Кар бабай, син нишләп йөрисең?

Кар бабай. Мин сезгә ерактан килдем. Мине сезгә минем хуҗам җибәрде. Ә сез минем хуҗамны беләсезме? Мин сезгә табышмак әйтәм, җавабын тапсагыз, хуҗамны белерсез.

Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән.
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.

Бу кайчак? *(Кыш.)* Булдырдыгыз! Дөрес, минем хуҗам – Кыш. Ләкин ул хәзер бик боек. Балалар, мин һич кенә дә аңламыйм, ни өчен Кышның кәефе юк икән? *(Урамда яз. Бөтен җирдә кар эри. Кояш җылыта. Түбәдән озын боз сөңгеләре күренә.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе шул, ничек кәефе төшмәсен инде Кышның! Ул күпме эш эшләгән: зур кар көртләре ясаган, чыршыларны кар каплаган, җәнлекләрне

саклаган. Ул мине сеңлесен эзләргә җибәрде. Мин сезгә табышмак әйтәм, җавабын тапсагыз, Кышның сеңлесен белерсез.

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт,
Йә, әйтеп кара? *(Яз.)*

Тәрбияче. Балалар, булдырдыгыз! Әйдәгез Язның кайда икәнен Кояштан сорыйк. (Тәрбияче кояш рәсемен күрсәтә.) Кояш, Кояш, син Язны күрмәдеңме? (Тәрбияче Кояш булып әйтә.) Мин Язны күрдем, карны, бозны эретергә ярдәм иттем. Рәхмәт, Кояш! Кар бабай, безнең балалар Кояш белән уйный беләләр. Син дә уйныйсыңмы?

Кояш чык, чык, чык!
Тәти кашык бирермен;
Майлы ботка бирермен!
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда *(балалар җитәкләшеп түгәрәк буйлап йөриләр)*.

Гөрләвекләр агалар *(балалар түгәрәк буйлап йөгерәләр)*.

Килгән инде каргалар *(балалар түгәрәк буйлап кулларын як-якка җәеп “очалар”)*.

Эри инде кар көртләре *(балалар акрын гына чүгәлиләр)*.

Үсеп килә чәчәкләре *(балалар аяк очларына басып, кулларын өскә күтәреп сузылалар)*.

Булдырдыгыз, балалар! (Тәрбияче кошлар рәсемен күрсәтә.) Балалар, бу рәсемдә нәрсә күрәсез? *(Кошлар.)* (Балаларны активлаштыру.) Бәлки кошлардан сорарбыз, алар Язны күрмәделәрме икән? Әйдәгез, бергәләп сорыйк: “Кошлар, кошлар, сез Язны күрмәдегезме?” (Балаларны активлаштыру.)

Кошлар. Күрдек, күрдек. Безне җылы яклардан Яз алып кайтты.

Тәрбияче. Рәхмәт сезгә, Кошлар! Балалар, ә Җир-ана безгә нәрсә әйтер икән? (Җир шарының рәсемен күрсәтә.)

Җир шары. Мине Яз уятты, яңа тормыш башланды.

Тәрбияче. Рәхмәт Җир-ана! Балалар, кешеләр Язны ничек каршылыйлар, Җирне ничек әзерлиләр? *(Җирне сөрәләр, казыйлар. Орлыклар утырталар.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, карагыз әле, нинди матур чәчәкләр. (Тәрбияче умырзая чәчәге сурәтләнгән сюжетлы картина күрсәтә.) Бу – умырзая чәчәге. Бергәләп кабатлыйк әле: умырзая чәчәге. (Балаларны активлаштыру.) Ул бик аз яши. Алар бик аз калганнар. Аларны сакларга кирәк.

Кар бабай. Кызык, ә умырзая Язны ничек каршы алды икән?

Тәрбияче. Ул язның килгәнен алдан сизенә һәм кар астыннан нечкә генә булып килеп чыга. Яз кайда икән дисезме? Тирә якка карагыз әле. Менә бит Яз!

Гөрләвек ага,
Кояш елмая,
Торналар үтте
Тезелеп бая.
Гөрләвекләрдә
Уйный үрдәк, каз.
Илне яшәртеп,
Шаулап килә яз.

Кар бабай. Балалар, рәхмәт сезгә! Хәзер мин хуҗам янына тыныч күңел белән кайта алам. Хәзер ул үзенең урынын Язга бирә ала. Сау булыгыз!

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Хәзер сез дә Яз турында күп нәрсәләр беләсез. Тагын бер тапкыр искә төшерик әле. (Кабатлыйлар.)

## Тема: ЯЗ БҮЛӘКЛӘРЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның яз, аның билгеләре турындагы белемнәрен, бер, күп төшенчәсен куллануларын ныгыту; бишкә кадәр санарга өйрәтү, киң, тар, яңгыравык, күңелле, тыныч тавыш, кычкырып сүзләр хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру; табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнешләрне аңлатуны һәм яз көне башкарыла торган эш турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү; куркынычсызлык кагыйдәләре турындагы белемнәрен киңәйтү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, ишетү сәләтен, кабул итүләрен үстерү;

3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык, үзара дуслык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** җылы яктан кайткан кошлар тавышы аудиоязмасы, тәрбияче өчен яз костюмы, фланелеграф, кара карганың, сыерчыкның, тургайның, торнаның, карлыгачның аерым контурлы рәсемнәре, А4 форматында кояш рәсеме, А3 форматында яз көне ике күлдәвектән барлыкка килгән, аннан соң ике тар һәм киң гөрләвек булып агуны сурәтләгән сюжетлы картина, “гөрләвек” ясау өчен ике тасма яки ике сикергеч (скакалка), балалар санынча кәгазьдән ясалган көймәләр, су салынган табаклар.

### Эшчәнлек барышы

Балалар уйныйлар, аудиоязмада җылы яктан кайткан кошлар тавышы яңгырый. Яз костюмы киеп, төркемгә тәрбияче керә.

Тәрбияче. Балалар, сез нинди тавыш ишетәсез? *(Кошлар җырлый.)* (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен кошлар шулай матур итеп җырлыйлар икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, балалар, яз килде, көннәр җылына, кояш ныграк җылыта, гөрләвекләр ага, кошлар Туган якларына кайталар, шуңа шатланып җырлыйлар, бөтен кеше шатлана.

Әйдәгез, яз билгеләрен бергәләп кабатлыйк әле: көннәр җылына, кояш ныграк җылыта, гөрләвекләр ага, кошлар Туган якларына кайталар. (Балаларны активлаштыру.)

Көннәр аяз, күктән алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы –
Сагынып көткән яз килә.
Кошлар кайта, каңгылдашып
Казлар кычкыра.
Ә кояш көне буена
Гел көлеп тора.

Балалар, мин сезгә бүләк алып килдем. Язның беренче бүләге – кошлар. (Кошлар тавышы аудиоязмасын акрын гына уйнаталар.) Балалар, кошлар ничек җырлый: кычкырыпмы, әллә тынычмы? *(Тыныч.)* (Балаларны активлаштыру.) (Кошлар тавышы аудиоязмасын кычкыртып уйнаталар.) Ә хәзер кошлар ничек җырлый? *(Кычкырып.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә кошларның тавышлары тагын нинди? *(Матур, яңгыравык, күңелле.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, әйдәгез кошларны чакырыйк.

Күктә оча каргалар,
Кычкыралар: “кар” да “кар”.

(Фланелеграфка кара карганың контурлы рәсеме куела.) Балалар, бу нәрсә? *(Кара карга, кош.) (Балаларны активлаштыру.)* Әйе, монда ничә кош бар? *(Бер.)* (Балаларны активлаштыру.)

Чакырабыз кошларны,
Кошлар, әйдә килегез,
Язны алып килегез!

(Фланелеграфка сыерчыкның, тургайның, торнаның, карлыгачның контурлы рәсеме куела.) Балалар, бу нинди кошлар? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Әйе, безгә тагын сыерчык, тургай, торна, карлыгач очып килделәр. Балалар, безгә ничә кош очып килде? *(Күп.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйдәгез, кошларны саныйк: бер, ике, өч, дүрт, биш. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, кошларны карыйк әле, алар нинди өлешләрдән тора икән? Илгиз, кил әле, сыерчыкның нәрсәләре бар, күрсәт.

Илгиз. Кошның башы, томшыгы, күзләре, гәүдәсе, койрыгы, канатлары, аяклары бар. (Тәрбияче берничә баланы чакырып фланелеграфтагы һәр кошның өлешләрен әйттерә.)

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Кошларның нинди өлешләрдән торуы исегезгә төштеме? Балалар, кошлар бер-берсенә охшаганмы? (Балаларның җаваплары.) Әйе, аларның барысының да башы, томшыгы, күзләре, гәүдәсе, койрыгы, канатлары, аяклары бар. Ә нәрсәләре белән аерылып торалар? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, балалар, кара карганың томшыгы зур, ул кап-кара төстә; сыерчык төрле төстәге каурыйлар белән капланган; тургай кечкенә, соры төстә; торнаның томшыгы һәм аяклары озын; карлыгачның койрыгы озын һәм ике чатлы. Балалар, ә кошлар нәрсәләр эшли беләләр? *(Очалар, суда коеналар, җим чүплиләр, бала чыгаралар.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, әйдәгез, без дә кошлар кебек очып уйныйк.

“Очты-очты” уены уйнала.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Яз сезгә тагын бер бүләк алып килде. (Тәрбияче фланелеграфка кояш рәсеме куя.) Бу нәрсә? *(Кояш.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә кояш нинди? *(Түгәрәк, сары, күңелле, елмая.)* (Балаларны активлаштыру.) Ул ни өчен елмая икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Дөрес, чөнки урамда яз. Әйдәгез без дә бер-беребезгә карап елмаешыйк. (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Язның сезгә тагын бер бүләге бар. Бу –

гөрләвек. Бергәләп кабатлыйк. *(Гөрләвек.)* (Балаларны активлаштыру.) Башта күлдәвекләр барлыкка килгән, аннан соң ул гөрләвек булып ага. (Тәрбияче яз көне күлдәвекләр барлыкка килә, аннан соң ул гөрләвек булып агуны сурәтләгән сюжетлы картина күрсәтә.) Балалар, безнең дә бүлмәдә “гөрләвек” бар икән. (Ике тасма яки сикергеч (скакалка) куеп “гөрләвек” ясала.) Әйдәгез, бу “гөрләвек” аша сикереп чыгабыз, яхшылап сикерегез, аякларыгыз чыланмасын. Булдырдыгыз, беркемнең дә аягы чыланмады. Аяклар чыланса, нәрсә була? *(Авырыйбыз.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, ә чирләмәс, авырмас өчен, без массаж ясыйбыз. Тамагыбыз авыртмасын, яхшылап сыпырыйк әле. (Биш тапкыр муеннарын сыпыралар.) Төчкермәскә, йөткермәскә борыннарны уабыз. (Биш тапкыр имән бармаклар белән борыннарын сыпыралар.) Маңгайны да онытмыйк, яхшылап аны ышкыйк. (Биш тапкыр уч төбе белән маңгайларын ышкыйлар.) Колаклар да калмасын, аларны да сыпырыйк. (Биш тапкыр имән һәм урта бармаклар белән колак яфракларын ышкыйлар.) Без чирдән курыкмыйбыз, рәхәтләнеп уйныйбыз. Булдырдыгыз, балалар! Балалар, рәсемгә карыйк әле, монда ничә гөрләвек бар? *(Күп, ике.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Балалар, бу гөрләвек тармы, әллә киңме? *(Киң.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә монысы нинди? *(Тар.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, яз көне гөрләвектә көймәләр йөздереп уйныйлар, ләкин уйнаганда сак булырга кирәк, аякларны чылатмаска, батмаска, бер-берең белән төртешмәскә кирәк. Ул көймәләрне нәрсәдән ясыйлар? *(Кәгазьдән, агачтан.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, без дә хәзер көймәләр йөздерербез.

Тәрбияче алдан ук кәгазьдән ясалган көймәләр тарата. Су салынган табакта көймәләрне йөздерәләр.

Тәрбияче. Җилләр, җилләр,
Ераkларга, зур елгага корабларны җибәр!

Балалар, яз безгә нинди бүләкләр җибәрде? *(Кошлар, кояш, гөрләвекләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! (Балалар уйнауларын дәвам итәләр.)

## Тема: ЯЗ КИЛӘ, ЯЗ!

**Бурычлар:**

1) балаларның яз, аның айлары, билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту; эшчәнлектә кулланган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнеш турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын, фикерләвен, хәрәкәтен, кабул итүләрен үстерү;

3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Ел фасыллары” фильмы яки А3 форматында кыш, яз, җәй, көз, “Яз көне җәнлекләр” картиналары, А5 форматында 10 иртә яз, 10 яз уртасы, 10 яз ахыры сурәтләнгән карточкалар, умырзая, тузганак чәчәге, үги ана чәчәге, энҗе чәчәк рәсемнәре, балалар санынча буялмаган күбәләк рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез бер-беребезгә карап, елмаеп сәламләшик. (Балалар бер-берсенә карап елмаялар, башларын ияләр.)

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт
Йә, әйтеп кара? *(Яз.)*

Булдырдыгыз! Балалар, ә сез бу табышмакның яз турында икәнен каян белдегез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Анда язның нинди билгеләре турында әйтелә? *(Боз һәм кар эреде, сулар йөгерде, көннәр озая, төннәр кыскара.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Ә хәзер елның кайсы вакыты? *(Яз.)* Балалар, менә бу рәсемнәргә карагыз.

Тәрбияче балаларга “Ел фасыллары” фильмын яки картинасын карарга тәкъдим итә.

Тәрбияче. Балалар, картинада язның нинди билгеләрен күрәсез? *(Кар эри, тамчылар тама, гөрләвекләр ага.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Әйе, яз килде. Балалар, сез беләсезме, иртә яз, яз уртасы, яз ахыры була. Бергәләп кабатлыйк: иртә яз, яз уртасы, яз ахыры (Балаларны активлаштыру.) Балалар, без сезнең белән рәсемнәр карарбыз, ә сез сайлап алган рәсемегезнең язның кайсы чорына туры килгәнен әйтергә тырышырсыз.

Тәрбияче А5 форматында 10 иртә яз, 10 яз уртасы, 10 яз ахыры сурәтләнгән карточкалар тәкъдим итә. Балалар, өстәл янына килеп, шул карточкаларны алалар һәм үз фикерләрен аңлаталар.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Әйе, иртә язда әле карлар эри генә башлый, гөрләвекләр ага, җылы яктан кошлар кайта башлый. Яз уртасында кар эреп бетә, җылы яктан кошлар кайтып бетә, кешеләр урамнарны чистартырга чыгалар, агачлар утырталар. Бергәләп урамнарны җыештыру, агачлар утырту өмә дип атала. Бергәләп кабатлыйк: өмә. (Балаларны активлаштыру.) Яз ахырында агачлар яфрак яра башлый, җир өсте яшел чирәм белән каплана. Балалар, кошлар җылы яктан кайчан кайта? *(Яз башында.)* Балалар, ә җылы яктан нинди кошлар кайта? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, яз көне җылы яктан торналар, күкеләр, карлыгачлар, сыерчыклар, кара каргалар, тургайлар кайталар. Балалар, кошлар җылы яктан

кайткач, яз уртасына кадәр оялар коралар, ә яз ахырында балалар чыгаралар. Бергәләп кабатлыйк: оя коралар, бала чыгаралар. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә яз көне җәнлекләр нишли икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) (Тәрбияче “Яз көне җәнлекләр” картинасы күрсәтә.) Әйе, яз көне җәнлекләр тормышында да үзгәрешләр була. Нинди үзгәрешләр икән? *(Яз көне куяннар, ак туннарын салып, соры туннарын кияләр. Барлык җәнлекләр, кышкы йоннарын коеп, яңаларын кияләр. Җәнлекләрнең балалары туа. Аюлар, керпеләр кышкы йокыдан уяналар.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Балалар, яз көне матур чәчәкләр үсә. Нинди чәчәкләр икәнен сез үзегез белергә тиеш. Без хәзер “Бу нинди чәчәк?” дигән уен уйнарбыз.

Өстәлдә А5 форматында төрле язгы чәчәкләр ясалган карточкалар ята, алар капланган. Балалар бер-бер артлы өстәл янына киләләр, бер рәсемне алалар, чәчәкнең исемен атыйлар, 2–3 җөмлә белән чәчәк турында сөйлиләр.

Тәрбияче. Алия, кил, бер рәсемне ал әле. Анда нинди чәчәк ясалган?

Алия. Бу умырзая чәчәге. Ул иртә язда кар астыннан чыга. Умырзая урманда үсә.

Тәрбияче. Булдырдың, Алия! Самат, син дә бер рәсемне ал.

Самат. Бу тузганак чәчәге. Ул яз ахырында чәчәк ата. Тузганак чәчәге сары төстә.

Тәрбияче. Булдырдың, Самат! (Шул рәвешле тәрбияче балалардан сорый, кайбер чәчәкләрнең атамасын аңлатырга мөмкин.) Балалар, чәчәкләрне сакларга кирәк, аларны өзәргә ярамый, өзмичә генә сокланырга кирәк. Балалар, әйдәгез, без дә чәчәкләр булып уйныйк.

Бездә беренче чәчәкләр

Таҗларын чыгарганнар *(балалар кулларын алга таба җәяләр),*

Аз гына җил иссә дә *(балалар кулларын өскә күтәреп җил исү хәрәкәте ясыйлар),*

Башларын аска игәннәр *(балалар башларын аска иярәр),*

Бездә беренче чәчәкләр

Башларын чайкый-чайкый *(балалар як-якка башларын чайкыйлар),*

Йокыга да талганнар *(балалар кулларын бер якка куеп йокыны имитацияләр).*

Булдырдыгыз, балалар! Балалар, сез хәтерлисезме, безгә Яз килгән иде? (Балаларның җавабы.) Ул сезгә менә мондый матур күбәләк рәсемнәре калдырган иде. Әйдәгез, Язга рәхмәт әйтик. (Балаларны активлаштыру.) Ләкин бу күбәләкләр барысы да ак төстә. Матур булсын өчен, аларны төрле төсләргә буярга кирәк. (Балалар күбәләк рәсемнәрен буйыйлар.)
Булдырдыгыз, балалар! Күбәләкләрегез бик матур килеп чыккан. Без сезнең белән бүген ел фасыллары, яз айлары, яз билгеләре турында сөйләштек. Саф һавага чыккач, бу билгеләрне күзәтербез.

## *Унберенче бүлек.*
## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

### Тема: ТАТАРСТАН БАЙРАГЫ

**Бурычлар:**

1) Татарстан байрагының төсләр турындагы белемнәрне ныгыту, агач һәм тукыманың билгеләрен ачыклау, кәгазь белән эшләү алымнарын камилләштерү, Җиңү көне турында мәгълүмат бирү;

2) балаларның сүзлек байлыгын активлаштыру, игътибарын, хәтерен, кабул итүләрен, флагта төсләрне дөрес урнаштыру осталыгын үстерү;

3) Татарстан байрагына карата горурлык хисләре, Җиңү бәйрәменә кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Татарстан байрагы (кечерәйтелгән копиясе), һәр балага җитәрлек санда яшел, ак, кызыл кәгазь кисәкләре, таякчык, җилем, салфетка, пумала, клеёнка.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, без яши торган планета ничек атала? *(Җир.)* (Балаларны активлаштыру.) Җир шарында бик күп илләр, республикалар бар. Шулар арасында матур һәм бай ил – безнең илебез. Зәкия Туфайлова туган илебез турында менә нинди шигырь язып калдырган:

Туган ил ул – алтын арышлар,
Туган ил ул – зифа камышлар,
Туган ил ул – иркен болыннар,
Болыннарда нәни колыннар.
Туган ил ул – зәңгәр диңгезләр,
Туган туфрак, үскән нигезләр.
Туган илдә – барыбыз бертуган,
Бик кадерле безгә ул шуңа.
Туган ил ул була бер генә,
Туган илнең кадерен бел генә.

Балалар, безнең республикабыз ничек атала? *(Татарстан.)* (Балаларны активлаштыру.) Татарстанда төрле халыклар яши. Һәр халыкның үз теле, җырлары, биюләре, әкиятләре, уеннары бар. Без күп, без төрле, ләкин безнең туган җиребез бер, ул безне берләштерә. Татарстан безне берләштерә. Безнең республикада яшәгән балаларны Татарстан балалары дип атыйлар. Сез Татарстан балалары. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, нәрсә ул туган ил? *(Без туган җир, без яши торган җир.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, һәр илнең үз байрагы бар, Татарстанның да байрагы бар. (Тәрбияче өстәлгә Татарстан байрагын куя.) Байракта нинди төсләр бар? *(Яшел, кызыл, ак.)* (Балаларны активлаштыру.)

Өч төс балкый безнең байракта.
Ак төс – безнең намус төсебез.
Яшел төсе – безнең яшәү төсе.
Кызылында чагыла көчебез.

Ак төс нәрсәне аңлата? (Балаларның җаваплары.) Дөрес әйтәсез, ак төс ул чисталык, пакьлек. Табигатьтә ак төстә нәрсәләр бар? *(Ак каен, ак кар, ак ромашка, ак болытлар, алмагач чәчәкләре, шомыртлар.)* (Балалар җавап бирә алмасалар, рәсемнәр күрсәтергә була.) Байрактагы кызыл төс нәрсәне белдерә? *(Иң матур төс.)* Кызыл төс нәрсәне белдерә? *(Бу кояш төсе, ут төсе, көз төсе, ул шатлык, сөенеч төсе.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, яшел төс нәрсәне белдерә? *(Тынычлык төсе, яшәү төсе.)* Табигатьтә нинди яшел әйберләр бар? *(Яшел яфраклар, яшел үлән, яшел чыршы, яшел нарат.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, Татарстан байрагы үз эченә туган табигатьнең барлык төсләрен алган, бу төсләр безнең илнең матурлыгы, байлыгы турында сөйлиләр. Әйтегез әле, безгә, безнең илгә байрак ни өчен кирәк? *(Ул безне берләштерә, байракка карап, кешеләрнең кайда яшәгәнен белеп була.)* (Балаларны активлаштыру.) Безнең республиканың байрагы бик матур. Бәйрәмнәр, тантаналы вакыйгалар булганда урамнарны байраклар белән бизиләр. Балалар, тиздән безнең зур илебез Җиңү көнен бәйрәм итәчәк. Җиңү бәйрәменә барлык кеше әзерләнә. Олысы да, кечесе дә мәңгелек ут янына барып, чәчәкләр куялар, байраклар күтәреп, демонстрациягә чыгалар. Өлкән кешеләрне, сугыш ветераннарын бәйрәм белән котлыйлар. Сез дә эти-әниләрегез белән бәйрәмгә барырсыз. Бу бәйрәм өчен байраклар ясыйк. Ә аны ясаганчы ял итеп алыйк.

Бер бармак – ялгыз бармак,
Ике бармак пар булмак.
Өч бармакта байтак көч,
Дүрт бармакта күмәк көч,

Биш бармакта тулы көч,
Тулы көч ул – бердәм көч,
Бергә-бергә эшләрбез,
Дуслар булып иртә-кич.

Һәр юлны әйткәндә, бармаклар очыннан төбенә таба дүрт тапкыр сыпыралар яисә, бармакларны җәеп, учны аска каратып куялар, һәр юлны әйткәндә, чәнчә бармактан тотынып, бер бармак күтәрелә бара: башта бер бармак, аннан ике бармак күтәрелә, эш шулай дәвам итә. Күнегү ике кулның бармаклары белән дә башкарыла.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, һәр байракның таягы (тоткасы) һәм тукымасы бар. Байракның таягы агачтан ясала. (Балаларны активлаштыру.) Таяк – нык материал, тотып карагыз әле. (Тәрбияче балаларга байракның таягын тоттыра.) (Балаларны активлаштыру.) Тукыма агачка беркетелә. Булдырдыгыз. Тагын бер тапкыр байракның таягын күрсәтегез әле. Ул ничек атала? Байракның тукымасын күрсәтегез. Хәзер без сезнең белән кечкенә байраклар ясарбыз. Байрак ясау өчен яшел кәгазь кисәгенә башта ак кәгазьне, аннан соң кызыл төстәге кәгазьне ябыштырабыз. (Тәрбияче эш алымнарын күрсәтә.) Менә яшелле, аклы, кызыллы тукыма килеп чыкты. Аны урталай бөгәбез. (Күрсәтә.) Бер өлешен җилем белән ябыштырырга кирәк. Уртага таякчыкны куярга кирәк. Менә шулай. (Тәрбияче эш алымын күрсәтә.) Тукыманың ике өлешен дә кушарга, пөхтә итеп кул белән йөртеп чыгарга. Менә байрак әзер. (Балалар байрак ясыйлар, ярдәм кирәк булган балаларга тәрбияче индивидуаль якын килә.) Балалар, сез булдырдыгыз. Нинди матур байраклар ясадыгыз! Бу байраклар белән Җиңү көне бәйрәменә бара аласыз. Сез ясаган байраклар җилдә җилфер-җилфер килерләр. (Балаларны активлаштыру.)

# Тема: ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыру; кайбер хәрби һөнәрләр (диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчылары) белән таныштыруны дәвам итү;

2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын, сүзлеген үстерү;

3) хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотлык, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчылары төшкән рәсемнәр (алар үзләренә хас булган эш гамәлләрен башкаралар), очкычлар, корабльләр, танклар, пушкалар, ракеталар сурәтләнгән рәсемнәр. Д. Тухмановның “Җиңү көне” (“День Победы”) җырының аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безнең бүлмә бәйрәмчә бизәлгән: шарлар, төрле төстәге флажоклар, плакатлар эленгән. Ни өчен шундый бәйрәмчә һәм тантаналы бүген төркемдә? *(Иртәгә зур бәйрәм – Җиңү көне.)* Булдырдыгыз. (Тәрбияче “Җиңү көне” (День Победы) җырының аудиоязмасын куя, балалар аның бер куплетын тыңлыйлар.) Әйе, иртәгә безнең халкыбыз Җиңү көнен билгеләп үтәчәк. Бик озак еллар элек сугыш булган, ул безнең илгә зур кайгылар һәм җимерүләр алып килгән. Бу сугышта дошманга каршы солдатлар батырларча көрәшкәннәр. Алар арасында очучылар, танкистлар, диңгезчеләр булган. (Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә.) Сугышта катнашкан кешеләр хөрмәтенә һәйкәлләр куялар. Һәйкәлләр янында һәрвакыт тере чәчәкләр. Бу чәчәкләр белән безнең солдатларны искә алабыз, аларга батырлыклары өчен рәхмәт әйтәбез, алар белән горурланабыз. Хәзер сугышта катнашкан әби-бабайлар инде бик картайган. Җиңү көнендә алар орден-медальләрен тагалар, бәйрәмдә катнашалар.

Карагыз әле, бу орден-медальләр аларны ничек бизи! (Тәрбияче рәсемнәр күрсәтеп сөйли.) Бу әби-бабайлар – сугыш ветераннары. (Балаларны активлаштыру.) Әгәр дә сез яшәгән йорттагы подъездда, сезнең гаиләдә сугыш ветераннары булса, аларны бәйрәм белән котларга онытмагыз. “Сезне бәйрәм белән котлыйм”, – дип әйтегез. Җиңү көнендә без үлгәннәрне искә алабыз, исәннәргә саулык телибез, алар алдында, аларның батырлыгы алдында баш иябез. (Тәрбияче сөйләмен рәсемнәр белән алып бара.)

Безнең армия зур һәм көчле. Россия армиясе үз халкын дошманнардан һәрвакыт саклаган, хәзер дә саклый. Безнең армиядә төрле гаскәрләр хезмәт итә.

Тәрбияче балаларга иллюстрацияләр күрсәтә. Бу рәсемнәрдә төрле хәрби гаскәрләрнең хезмәте сурәтләнгән: диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчылары.

Тәрбияче. Балалар, бу рәсемнәргә карагыз әле. Солдатлар нәрсә эшлиләр? Ни өчен солдатларга шөгыльләнергә, тренировкаларда булырга кирәк? (Балаларның җаваплары.) Илне саклау һәм яклау өчен солдатлар нәрсә эшлиләр? (Балаларның җаваплары.) Безнең илнең солдатлары көчле булу өчен, аларга тренировкаларга йөрергә, хәрби хезмәткә өйрәнергә кирәк. Аларны оста итеп атарга, каршылыкларны җиңәргә, сикерергә, үрмәләргә, йөзәргә өйрәтәләр. Солдат булу өчен бүген үк әзерләнергә кирәк. Хәзер без “Сигнальщиклар” дигән күнегү ясарбыз.

Без җирдә басып торабыз *(аяклар азрак аерылган, куллар артта),*

Корабльдә йөзәбез *(куллар алга куела һәм тиз генә артка җибәрелә).*

Һәрвакыт сигнал бирәбез, шундый приказ безгә бирелгән *(ике кулны да аркага куялар):*

Уңга борыл *(баш уңга борыла, уң кул аркага куела),*

Сулга борыл *(баш сулга борыла, сул кул аркага куела),*

Йоклама, сигнал бирергә онытма! *(Катып калырга: смирно).*

Балалар, сугыш вакытында һәм хәзер дә безнең солдатларга хәрби техника ярдәмгә килә. Хәрби техникага нәрсәләр кирә? *(Очкычлар, корабльләр, танклар, пушкалар, ракеталар.)* (Тәрбияче балалар атаган техниканың рәсемнәрен күрсәтә.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, Җиңү бәйрәме уңаеннан әйдәгез, “Россия армиясе” дигән макет төзибез. Бу макетта зәңгәр төс белән нәрсәне билгелик? *(Диңгезне билгелик.)* (Балаларны активлаштыру.) Яшел төс белән нәрсәне билгелик? *(Коры җирне.)* Ни өчен коры җирне яшел төс белән билгеләдек? *(Җирдә яшел үлән, агачлар, куаклар үсә.)* (Балаларны активлаштыру.) Һаваны нинди төс белән билгеләргә була? *(Күк төс белән.)* Әйе, күк төс белән һаваны ясыйк. (Балалар тәрбияче белән бергә биремне үтиләр.) Балалар, хәзер хәрби техниканы, хәрбиләрне тиешле урынга куярга кирәк. Очкыч янына ... *(очучы)* килде. Очкычны кая куябыз? *(Һавага.)* (Балаларны активлаштыру.) Һавадан парашютта ... *(парашютист)* төште. Танк янына ... *(танкист)* басты. Танк белән танкистны кая куябыз? *(Җиргә.)* (Балаларны активлаштыру.) Корабль янында ... *(диңгезчеләр)* тора. Корабльне кая куябыз. *(Диңгезгә.)* (Балаларны активлаштыру.) Машинага ... *(солдатлар утыра.)* Дәүләт чиген ... *(чик сакчылары)* саклый. Балалар, карагыз әле, нинди матур макет барлыкка килде! Төрле гаскәре булган армия – көчле армия. Ул үз илен диңгездә дә, коры җирдә дә, һавада да саклый ала.

## Тема: 9 МАЙНЫ КАРШЫЛАП...

**Бурычлар:**

1) балаларның Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыруны, хәрби һөнәрләр, аларның баш киемнәре белән таныштыруны дәвам итү, сугышчыларның батырлыгы турында сөйләү, хәрби техника турында белемнәрен киңәйтү;

2) балаларның диалоглы сөйләмен, конкрет-образлы фикерләвен, игътибарын, кызыксынуын, конструктив осталыкларын үстерү;

3) хәрби һөнәрләргә, ветераннарга карата хөрмәт, патриотлык, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** марш аудиоязмасы, Ватан сугышы сурәтләнгән рәсемнәр, Җиңү бәйрәме сурәтләнгән рәсемнәр (мәңгелек ут, һәйкәлләр, сугыш ветераннарын котлау), диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчылары төшкән рәсемнәр, аларның баш киемнәре, таякчыклар; самолётлар, корабльләр, танклар, пушкалар, ракеталар рәсеме.

## Эшчәнлек барышы

Аудиоязмада марш яңгырый. Балалар урыннарына утыра.

Тәрбияче. Җиңү көне уңаеннан безнең илебезне саклаучылар турында сөйләшик. Бөек Ватан сугышы бик озак барган. Илгә, аның кешеләренә зур кайгылар, җимерүләр алып килгән. Бу сугыш турында нәрсә ишеткәнегез бар? (Балаларның җаваплары.) Бүген без тыныч илдә яшибез. Җиңү көнендә сугыш ветераннарын, олы яшьтәге әби-бабайларны бәйрәм белән котлыйбыз, аларга саулык– сәламәтлек телибез. Бөек Җиңүне фронттагы солдатлар, авыл-шәһәрдә эшләүче кешеләр яулаган. Бик күпләр сугыш кырында үлеп калганнар. Аларның батырлыгын искә алып, һәйкәлләр куялар. Һәйкәлләр янында һәрвакыт тере чәчәкләр. Бу чәчәкләр сугышта катнашкан, батырлык күрсәткән, гаиләләренә кайта алмаган солдатларга рәхмәт билгесе һәм истәлеге. Сугыш ветераннары елдан-ел азая бара. Алар сез яшәгән йортта, подъездда да яшәргә мөмкин. Аларны күрсәгез, бәйрәм белән котларга онытмагыз. “Бәйрәм белән! Җиңү өчен сезгә рәхмәт”, – дип әйтегез. Безнең солдатлар диңгездә, коры җирдә, һавада да дошманнар белән сугышканнар. Безнең илнең солдатлары нинди? *(Кыю, көчле, курку белмәс, илне яратучан.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, самолётта, вертолётта очучы сугышчыларны кем дип атыйлар? *(Очучы, очучылар.)* (Балаларны активлаштыру.) Парашют белән сикерүчеләрне кем дип атыйлар. *(Парашютчы.)* (Балаларны активлаштыру.)

Танкта хезмәт итүчеләрне кем дип атыйлар? *(Танкистлар.)* (Балаларны активлаштыру.) Корабльдә, су асты көймәләрендә хезмәт итүчеләрне кем диләр? *(Диңгезчеләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Дәүләт чиген саклаучыларны кем дип атыйлар? *(Чик сакчылары.)* (Балаларны активлаштыру.) (Тәрбияче әңгәмәне рәсемнәр күрсәтү белән бергә алып бара.) Балалар, һәр гаскәр төренең хәрби киеме бар. Өстәлдә хәрбиләрнең баш киемнәре ята. Әйдәгез аларның кемнеке икәнен билгелик. Шлем кемгә ... *(танкистка.)* Бескозырка кемгә ... *(диңгезчегә.)* Пилотка кемгә ... *(солдатка.)* Яшел фуражка кемгә ... *(чик сакчысына.)* Зәңгәр фуражка кемгә ... *(очучыга.)* Булдырдыгыз. (Тәрбияче дөрес җавап биргән балаларга өстәлдә яткан баш киемнәрен кидерә.)

Хәрбиләргә хәрби техника ярдәмгә килә. Солдатлар, офицерлар төрле хәрби техника белән эшлиләр. Әйдәгез, нинди хәрби техника бар икәнен карыйк әле. (Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә: танк, самолёт, вертолёт, ракета, корабль, су асты көймәсе. Балалар техниканы атыйлар һәм кабатлыйлар.) Балалар, сезнең өстәлләрдә таякчыклар ята. Шулардан үзегезгә ошаган хәрби техниканы ясагыз. (Балалар биремне үтиләр.)

Әйдәгез, “Очучылар һәм очкычлар” дигән уенны уйнап алыйк. (Балалар уйныйлар.)

## *Уникенче бүлек.* ҖӘЙ

### Тема: ЧӘЧӘКЛӘР

**Бурычлар:**

1) балаларны җәйге табигатьтәге үзгәрешләр, чәчәкләрнең характерлы билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сорауларга тулы җәенке җөмләләр белән җавап бирү осталыгын ныгыту;

2) балаларның логик, образлы фикерләүләрен, хәтерен, игътибарын, вак моториканы үстерү;

3) чәчәкләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** чәчәкләр (күкчәчәк, ромашка, мәк, ландыш, тузганак) сурәтләнгән предметлы картинкалар, 4 өлешкә киселгән ландыш чәчәге сурәтләнгән картинка; чәчәк өлешләре (тамыры, сабагы, яфраклары, чәчәкләре.)

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, хәзер елның кайсы вакыты? *(Җәй.)* Дөрес, җәй. Сез җәй турында нәрсәләр беләсез? *(Кояш нык кыздыра, кызынырга, су коенырга була, урманда җиләкләр, гөмбәләр өлгерә, чәчәкләр күп була һ. б.)* Балалар, бик яхшы! Сез табигатьнең җәй көне ничек үзгәрүен беләсез. Җәй билгеләрен дөрес атадыгыз. Сезнең өстәл өстендә конвертлар бар. Конвертны ачыгыз, эчендәге әйберләрне алыгыз. (Балалар конверт эченнән киселгән картинка өлешләрен алалар.) Балалар, бу картинка таралган. Әйдәгез, җыеп карагыз әле. (Балалар дүрт киселгән өлештән ландыш чәчәге сурәтләнгән картинка җыялар.) Балалар, картинкада нәрсә ясалган? *(Ландыш чәчәге.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ландыш чәчәген энҗе чәчәк дип тә атыйлар. (Балаларны активлаштыру.) Ландыш чәчәге кайда үсә? *(Урманда. Ландыш чәчәге урманда үсә.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, яхшы! Ландыш чәчәге урманда үскәч, ул нинди чәчәк була инде? *(Урман чәчәге. Урманда үсә торган чәчәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Ландыш чәчәгенә игътибар белән карагыз. Ландыш чәчәге нинди? *(Ландыш чәчәге кечкенә кыңгыраулар кебек, аның зур яшел сабагы нечкә, чәчәкләре кечкенә ак.)* (Балаларны активлаштыру.) Кем ландыш чәчәге турында матур итеп сөйләп бирә ала? (Тәрбияче бер баладан сорый.) Бик яхшы, ландыш чәчәге турында матур итеп сөйләдегез. Хәзер картинкаларыгызны өстәл кырына куегыз. Игътибар белән тактага карагыз! (Җыелма кесәгә чәчәкләр сурәтләнгән предметлы картинкалар куелган.) Балалар, картинкаларда нинди чәчәкләр сурәтләнгән, исемнәрен атагыз әле. *(Күкчәчәк, ромашка, мәк, ландыш, тузганак)*. Балалар, күкчәчәк,

ромашка, мәк, ландыш, тузганак бер сүз белән ничек аталалар? *(Чәчәкләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, исегезгә төшерегез әле, чәчәкләр нинди өлешләрдән торалар, аларның нәрсәләре бар? *(Тамыры.)* Дөрес, тамыры бар. (Тәрбияче җыелма кесәгә тамыр сурәтләнгән картинка куя.) Менә ул тамыр. Чәчәкнең тагын нәрсәсе бар? *(Сабагы.)* (Тәрбияче сабак сурәтләнгән картинканы куя.) Менә чәчәкнең сабагын да куйдык. Ә тагын нәрсәсе бар? *(Яфраклары.)* (Тәрбияче яфрак ясалган картинка куя.) Чәчәкнең яфраклары да булды. Чәчәкнең тагын нәрсәсе бар? *(Чәчәге.)* Бик дөрес, матур чәчәге бар. (Тәрбияче чәчәк ясалган картинка куя.) Хәзер, балалар, чәчәкне тасвирлап, аның турында сөйләп карагыз. Мин сезгә күкчәчәкне тасвирлап күрсәтәм. Игътибар белән тыңлагыз. “Күкчәчәк – кечкенә генә зәңгәр чәчәк, аның сабагы нечкә, яфраклары бик матур. Ул басуда (кырда) үсә”. (Алга таба тәрбияче балаларны чакыра, алар һәр чәчәкне тасвирлыйлар.) Балалар, ә хәзер уен уйнап алыйк. Сез чәчәкләр булырсыз. Күктә кояш елмая. Матур итеп басыгыз. Бармакларыгызны җәеп, кулларыгызны өскә – кояшка күтәрегез! (Балалар кулларын күтәрәләр.) Чәчәкләр кояшка карыйлар, аның җылысын тоялар. (Балалар аяк очларына басып, кояшка таба үреләләр.) Кояш йокларга ята, чәчәкләр дә йоклый. (Чүгәлиләр, кулларны аска төшерәләр.) (Уен 2–3 тапкыр кабатлана. Музыка куярга да була.) Балалар, мин сезгә “Бу чәчәк кайда үсә?” уенын тәкъдим итәм. Мин сезгә чәчәкләр сурәтләнгән картинкалар күрсәтәм, ә сез аларның кайда үсүен әйтерсез. (Тәрбияче мәк (ландыш, күкчәчәк) күрсәтә.) Бу нинди чәчәк? *(Мәк.)* Мәк кайда үсә? *(Бакчада.)* Бу нинди чәчәк? *(Ландыш.)* Ландыш кайда үсә? *(Урманда.)* Бу нинди чәчәк? *(Күкчәчәк.)* Ул кайда үсә? *(Басуда яки кырда.)* Бик дөрес, балалар. Бакчада үсә торган чәчәкләрне махсус утырталар, аларны карыйлар, тәрбиялиләр. Алар бакча чәчәкләре дип аталалар. (Балаларны активлаштыру.) Урманда үсә торган чәчәкләрне беркем дә утыртмый, алар үзләре үсәләр һәм урман чәчәкләре дип аталалар. (Балаларны активлаштыру.) Басуда (кырда) үсә торган чәчәкләрне дә беркем дә утыртмый,

алар үзләре үсәләр һәм басу (кыр) чәчәкләре дип аталалар. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, җирдә чәчәкләр күп булса, җиребез матур, һава саф була. Чәчәкләрне яратыгыз һәм саклагыз! Чәчәкләрне өзмәгез! Урманнар, болыннар һәм бакчалар чәчәкләргә күмелсен! Безне сокландырсын!

## Тема: ҮРДӘК БӘБКӘСЕ БАК-БАКНЫ ТАСВИРЛАУ

**Бурычлар:**

1) уенчыкны эзлекле тасвирлап, кечкенә хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү: педагог сораулары ярдәмендә фикерләрен төзи белү осталыгы формалаштыруны дәвам итү;

2) бәйләнешле сөйләмне, кабул итүне, игътибарны үстерү;

3) хикәя төзүгә кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык әнкә үрдәк, уенчык үрдәк бәбкәсе.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, кулга-кул тотышып басыгыз. Әйдәгез, башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып “Хәерле иртә!” телибез.

Тәрбияче алдан ук, эшчәнлек башланганчы, уенчык үрдәк бәбкәсен өстәлгә куя. Балалар аны карыйлар. Балалар өстәл артына утыргач, тәрбияче сиздермичә генә үрдәк бәбкәсен алып куя. Ишек шакыйлар, тәрбияче уенчык үрдәк алып керә.

Тәрбияче. Балалар, ямьле кояшлы җәй көнендә әни үрдәк үзенең бәбкәсен яшел чирәм ашарга алып чыккан. Үрдәк бәбкәсе югалган. Әни үрдәк бәбкәсен эзләп йөри. Балалар, сез сары йомшак үрдәк бәбкәсен күрмәдегезме? Аның исеме Бак-Бак. Әйдәгез, бергәләп чакырыйк әле: “Үрдәк бәбкәсе Бак-Бак, чык монда!” (Күмәк һәм индивидуаль җаваплар.) (Бак-Бак күренә дә тагын кача.) Сары, йомшак Бак-Бак, чык монда!

Балалар тәрбияче белән бергә кабатлыйлар. Үрдәк бәбкәсе күренә.

Тәрбияче. Әнкә үрдәк, менә Бак-Багың табылды. Кил монда, утырып тор! Балалар, ул үрдәк бәбкәсе нәрсәдер әйтергә тели. Ул сездән: “ Минем күзләрем нәрсәгә охшаган?” – дип сорый. Балалар, үрдәк бәбкәсенең күзләре нәрсәгә охшаган? *(Сәдәфләргә, җиләкләргә, кечкенә шарларга, кечкенә тупларга.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Тәрбияче үрдәк бәбкәсен өстәл өстендә йөртә.) “Мин бик матур, әйеме? – ди үрдәк бәбкәсе. Әйе, үрдәк бәбкәсе бик матур. Балалар, үрдәк бәбкәсе матурмы? (Балаларның җаваплары.) (Тәрбияче үрдәк бәбкәсен тасвирлый.) “Үзең зур һәм юан, ә канатларың кечкенә, менә шундый. (Күрсәтә.) Әйе-әйе, канатларың бик кечкенә. Балалар, үрдәк бәбкәсенең канатлары нинди? *(Бик кечкенә.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, хәзер мин сезгә Бак-Бак турында сөйләп күрсәтәм. Игътибар белән тыңлагыз: “Бу үрдәк бәбкәсе Бак-Бак. Ул сары, йомшак. Бак-Бакның күзләре зур кара төймәләр кебек. Үрдәк бәбкәсе көлкеле. Үзе зур һәм юан, ә канатлары кечкенә. Бак-Бак башына түбәтәй кигән һәм эреләнеп кенә бак-бак-бак диеп алпан-тилпән китте.” Балалар, әйдәгез, үрдәк бәбкәсе Бак-Бак кебек алпан-тилпән йөреп күрсәтегез әле. (Балалар үрдәк кебек йөриләр. Тәрбияче хикәяне тагын бер кат кабатлый) Балалар, сез хәзер үрдәк бәбкәсе Бак-Бак турында сөйләрсез. Кемнең хикәясе бик матур килеп чыга, шуны бүләк көтә. (4–6 баладан сөйләтә, хикәясе матур килеп чыккан балаларны бүләкли.) Балалар, сез бүген бик дөрес, матур һәм яхшы итеп үрдәк бәбкәсе Бак-Бак турында сөйләдегез. Без Әни үрдәк белән сезне рәхәтләнеп тыңладык. Үрдәк бәбкәсе Бак-Бак, син кабат әниеңә әйтмичә бер җиргә дә китмә! Әниләрне һәрвакыт тыңларга кирәк. Менә безнең балалар әниләреннән сорамыйча бер җиргә дә бармыйлар. Шулаймы, балалар? *(Балаларның җаваплары.)* Балалар, Әни үрдәк һәм бәбкәсе Бак-Бак сезнең белән уйнарга калалар.

# 2. СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ (КОММУНИКАЦИЯ) ӨЛКӘСЕ

| **Срок-лар** | **Бүлекләр** | **Тема** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| **20.08.–10.09.** | **Белем бәйрәме** | Безнең уенчыклар | 1) балаларда предметларны тасвирлау; вак моториканы камилләштерү; исем, сыйфат кулланып, гади җөмләләр төзергә өйрәтү, предметлар атамасы, аларның өлешләрен атау, нинди материалдан ясалуы турында сөйләү хисабына сөйләмнәрен активлаштыру; “ш” авазын ныгыту;<br>2) балаларның кызыксынучанлыгын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда уенчыкларга карата сакчыл караш, үзара дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **11.09.–30.09.** | **Көз** | “Песи балалары белән” дигән сюжетлы картина карау | 1) балаларның көзге үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту; сюжетлы картина персонажларын игътибар белән карау; эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү; иҗадилык элементларын күрсәтү осталыгын формалаштыру, песи һәм аның балалары исемнәрен сөйләмдә куллану, җәнлекләр гамәлен билгеләүче сүзләр хисабына сүзлек запасын баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сенсор сәләтләрен, уен кагыйдәләрен үтәү теләген үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) песиләргә карата сакчыл мөнәсәбәт, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **1.10.–20.10.** | **Мин – дөньяның бер кешесе** | Гаилә | 1) балаларда, гаилә әгъзасы буларак, үзләре турында күзаллаулар формалаштыру; кеше тормышында гаиләнең әһәмиятен күрсәтү;<br>2) үзләренең гаилә әгъзалары турында сөйләү осталыгын, кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен үстерү; сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, сүзлекне ныгыту;<br>3) гаилә әгъзаларына карата хөрмәт, ярату, горурлык хисләре, ихтирам тәрбияләү. |
| **21.10.–04.11.** | **Минем шәһәрем, минем Ватаным** | Синең куркынычсызлыгың – синең кулларда | 1) балаларны куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру; тротуар, юлны аркылы чыгу урыны, машина юлы, куркынычсызлык каешы, регулировщик кебек яңа сүзләр һәм сүзтезмәләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү; туган як, шәһәр турында, транспорт төрләре турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда дустанә мөнәсәбәт, ярдәмләшү хисе тәрбияләү. |
| **15.11.–31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Кыш бабай турында хикәя төзү | 1) тәрбиячөнең сүзле күрсәтмәләре (схема) буенча күмәк хикәя төзү күнекмәләре формалаштыру; балаларны тәрбияче һәм яшьтәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | дәвам итү;<br>2) игътибарны, фантазияне, сөйләмдә еш кулланыла торган исемнәрне, сыйфатларны, фигыльләрне куллану; күмәк эшләү осталыгы үстерү;<br>3) Яңа елга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Әкияти җәнлекләрнең кышкы мажара-лары | 1) тәрбиячենең сүзле күрсәтмәләре (схема) буенча күмәк хикәя төзү осталыгын формалаштыру; хайваннарны тасвирлаганда хаталарны табуда күнектерү;<br>2) игътибарны, конкрет-образлы фикерләүне, сөйләмне, күмәк эшләү осталыгын үстерү;<br>3) Яңа елга карата кызыксыну, хайваннарга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | Чыршыкай-купшыкай | 1) Яңа ел бәйрәме, чыршы турында күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү;<br>2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, хикәя төзү осталыгын, кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, бармаклар моторикасын үстерү;<br>3) күтәренке кәеф атмосферасы тудыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **01.01.–31.01.** | **Кыш** | Ап-ак тунлы кыш | 1) балаларның кыш турындагы белемнәрен киңәйтү; танып белү һәм эзләнүгә омтылыш формалаштыру; “аста”, ”өстә”, “төбендә” һәм эшчәнлектә кулланган башка фразалар, чагыштыру сыйфатлары хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру; “у” авазын ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү;<br>3) балаларда кызыксыну, бердәм эшләү хисләре тәрбияләү. |
| | | Кыргый хайваннар | 1) кыргый җәнлекләр турында күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү;<br>2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хикәя төзү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен үстерү;<br>3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну уяту. |
| **01.02.–23.02.** | **Ватанны саклау-чылар көне** | Хәрби һөнәрләр | 1) балаларның хәрби һөнәрләр һәм аларның төрләре, танк турындагы белемнәрен формалаштыру; исем, сыйфат кулланып, гади җөмләләр төзергә өйрәтү;<br>2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда хәрби һөнәрләргә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Очучылар | 1) балаларны очкычның (самолётның) өлешләрен, зурлыгын, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүдә күнектерүне дәвам итү;<br>2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, танып белүләрен, кызыксынуын үстерү;<br>3) төрле гаскәр төрләренә, очучы һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләре тәрбияләү |
| | | Иң яхшы эти (Йомгакла у чарасы) | 1) сәнгать әсәрләре аша балаларның сөйләм культурасын, татар халкының әдәби әсәрләрен белү теләген формалаштыру; сөйләм нормаларын үзләштерү;<br>2) татар җыр-биюләренә соклану, алар белән кызыксыну теләкләрен үстерү;<br>3) ана телендә аралашырга теләк уяту; үз гаиләң, эти-әниең белән горурлану хисе тәрбияләү. |
| **24.02.–08.03.** | **8 Март** | Әниләр бәйрәме | 1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы мәгълүматларын киңәйтү; әниләр турында тасвирлау хикәясе сөйләргә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерләрен, фотография кулланып, эзлекле сөйләүләрен үстерү;<br>3) әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | | “Эт көчекләре белән” дигән | 1) сюжетлы картинаның персонажларын игътибар белән карау; эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү; тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | картина буенча хикәя төзү | белән бергә сөйләү осталыгын формалаштыру; эчтәлекне сөйләгәндә, иҗадилык элементларын куллануга ярдәм итү; сөйләмне сыйфатлар куллану хисабына баету;<br>2) балаларның игътибарын, күрү хәтерен, тыңлау осталыгын, танып белүләрен, кызыксынуларын үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **09.03.–20.03.** | **Халык җәүһәр-ләре** | Бияләй һәм перчатка | 1) татар халкының кул эшләре белән таныштыру; тәрбиячнең сөйләмен аңларга, сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) сенсор культураны, сүзлек байлыгын, сөйләмнең грамматик төзелешен үстерү;<br>3) халкыбызның кул эшләре белән кызыксыну, чисталык, пөхтәлек, тырышлык, киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| **01.04.–20.04.** | **Яз** | Аюның язгы маҗара-лары | 1) балаларны исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү; язның төп билгеләрен ныгыту; бирелгән сүзләргә антонимнар сайлауны формалаштыру, балаларның сүзлек запасын киңәйтү;<br>2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Урман күлендә | 1) балаларның [с], [з], [у], [ш] авазларын дөрес әйтүләрен ныгыту, [ж] авазының артикуляциясен исләренә төшерү, бу авазны сүзләрдә, фразаларда әйтүдә күнектерү; язның төп билгеләре, айлары, табигать күренешләре турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның сүзлек запасын киңәйтү;<br>2) балаларның кызыксынуын, ишетү игътибарын, хәтерен, логик фикерләвен, вак моторикасын үстерү;<br>3) балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **21.04.–09.05.** | **Җиңү бәйрәме** | Транспорт | 1) балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү; төренә карап, аларны классификацияләргә, бер транспорт төре турында тасвирлау хикәясе төзергә өйрәтү; Җиңү көне уңаеннан транспорт турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның диалоглы сөйләмен, конкрет-образлы фикерләвен, классификацияләү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын, сүзлек запасын үстерү;<br>3) ветераннарга карата хөрмәт, горурлану хисләре һәм коллективта эшләү теләге уяту; уңай атмосфера тудыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **10.05.–31.05.** | **Җәй** | Бөҗәкләр | 1) балаларның бөҗәкләр турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү;<br>2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; сүзлекне киңәйтү; кызыксынуын, төсләрне аера белү осталыгын үстерү;<br>3) бөҗәкләргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Чәчәкле җәй | 1) җәй ел фасылына хас билгеләр белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, предметлы картиналар буенча “Җәй” темасына хикәя төзү осталыгын үстерү;<br>3) тырышып шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |

# *Беренче бүлек.*
# БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ

## Тема: БЕЗНЕҢ УЕНЧЫКЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларда предметларны тасвирлау, вак моториканы камилләштерү, исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү; предметлар атамасы, аларның өлешләрен атау, нинди материалдан ясалуы турында сөйләү хисабына сөйләмнәрен активлаштыру; “ш” авазын ныгыту;

2) балаларның кызыксынучанлыгын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;

3) балаларда уенчыкларга карата сакчыл караш, үзара дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** видеоплеер, “Лунтик” мультфильмы видеоязмасы, Лунтик уенчыгы, “серле янчык”, уенчык машина, йомшак куян уенчыгы, курчак, төркемдә уенчык почмагында агачтан, балчыктан ясалган уенчыклар, балалар санынча квадрат формасында киселгән кәгазьләр.

### Эшчәнлек барышы

Өстәлдә “серле янчык” тора. Тәрбияче балалар белән (Лунтик: “Мин тудым”, – дигән өлешкә кадәр) “Лунтик” мультфильмы видеоязмасын карыйлар. Тәрбияче видеоязманы сүндерә һәм балаларга Лунтик уенчыгын күрсәтә.

Тәрбияче. Исәнме, Лунтик! (Балаларны активлаштыру.)

Лунтик. Исәнмесез, балалар! Мин сезнең балалар бакчасын күрергә килдем. Сез монда ниләр эшлисез соң? *(Уйныйбыз, җырлыйбыз, биибез, саф һавада йөрибез, шөгыльләнәбез, әкиятләр укыйбыз, китаплар карыйбыз.)* Монда бик рәхәт икән. (Лунтик өстәлдәге “серле янчыкны” күреп ала.) Ә бу нинди матур әйбер? *(“Серле янчык”.)* (Балаларны активлаштыру.) Монда могҗизалар бармы әллә? Ә

аның эчен карарга ярыймы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.)

Тәрбияче. Әлбәттә, Лунтик, син бит кунак. Балалар, аңа рөхсәт итәбезме? (Балаларны активлаштыру.)

Лунтик. “Серле янчыкта” нәрсә бар икән? Ай, монда ниндидер дүрт тәгәрмәчле, кузовлы, кабиналы предмет бар. Нәрсә икән ул?

Тәрбияче. Балалар, Лунтикка ярдәм итегез әле, нәрсә икән ул? *(Машина.)*

Лунтик. Ә нәрсә соң ул – машина? Безнең Айда машиналар юк.

Тәрбияче. Балалар, кайсыгыз машина турында сөйли? Кәрим, кил, машина турында сөйлә.

Кәрим. Бу машина. Бу йөк машинасы. Аның тәгәрмәчләре, кузовы, кабинасы бар. Кабинасында руле, урындыгы, тизлек рычаглары бар. Машина белән йөк ташып уйнарга була.

Лунтик. Бигрәк матур итеп сөйләдең, мин барысын да аңладым.

Тәрбияче. Ә хәзер Лунтик, мин машина сүзен әйтәм һәм бер авазга басым ясыйм. Балалар, сез тыңлагыз һәм нинди аваз икәнен әйтерсез. Маш-шина. Балалар, сез нинди аваз ишеттегез? *(Ш авазы.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес. Хәзер “ш” авазын кызлар гына әйтә. *(Ш.)* Булдырдыгыз! Хәзер “ш” авазын малайлар гына әйтә. *(Ш.)* Булдырдыгыз!

Лунтик Сез бик матур итеп әйтәсез, мин алай булдыра алмыйм.

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, Лунтикны “ш” авазы белән дөрес суларга өйрәтәбез. Сулыш гимнастикасы ясыйбыз: сулыш алганда кулларны як-яктан өскә күтәрәбез, сулышны чыгарганда кулларны аска төшерәбез һәм “ш” авазын чыгарабыз. (Күнегү берничә тапкыр кабатлана.) Булдырдыгыз! Лунтик, син дә дөрес иттең.

Лунтик. Әйдәгез, тагын “серле янчык” эчен карыйк, тагын нинди уенчык бар икән?

Тәрбияче. Балалар, кайсыгыз Лунтикка ярдәм итә? Марат, кил, син ярдәм ит.

Марат. (Бала кулын янчыкка тыгып уенчыкны капшый.) Башы бар, ике күзе, күзе зур, авызы бар. Колагы озын. Койрыгы кечкенә. Тәпиләре дә кечкенә.

Тәрбияче. Балалар, нәрсә икән соң ул? *(Куян.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Марат бик дөрес, матур итеп куянның билгеләрен әйтте. (Тәрбияче куянны янчыктан ала.)

Лунтик. Бигрәк матур уенчык, минем беркайчан да куян күргәнем юк иде.

Тәрбияче. Балалар, кайсыгыз куян турында сөйли? Азалия, кил әле, куян турында сөйлә.

Азалия. Бу уенчык куян. Ул йомшак. Аның башы, ике күзе бар , күзләре зур, кыек карыйлар, авызы бар – кызыл. Колагы озын. Койрыгы кечкенә. Тәпиләре дә кечкенә. Куян бик куркак.

Лунтик. Куян турында бигрәк матур итеп сөйләдең, мин барысын да аңладым.

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, куллар белән куян ясап күрсәтик. (Балалар куллары белән куян ясап күрсәтәләр.) Балалар, Лунтик, безне куян уйнарга чакыра.

Ап-ак куян утыра *(балалар чүгәләп утыралар),*
Колакларын селкетә *(куян колакларын ясап, кулларын башка куялар һәм селкетәләр).*
Менә шулай, менә шулай,
Колакларын селкетә,
Аңа тик тору кыен,
Җылыта ул тәпиен *(кулларын сыйпыйлар, уалар).*
Һап, һап, һап *(кулларын чәбәклиләр).*
Җылыта ул тәпиен,
Куян тик торса туңа *(сикерәләр).*
Сикергәли ул шуңа.
Һап, һап, һап *(кулларын чәбәклиләр).*

Булдырдыгыз! Балалар, паласка утырыгыз.

Лунтик. Бу янчыкта тагын нәрсәдер бар. Миңа кайсыгыз ярдәм итә?

Рания. Аның башы бар, ике кулы, ике аягы, гәүдәсе бар.

Тәрбияче. Балалар, бу нәрсә? *(Курчак.)* Булдырдыгыз! Рания курчак турында бик дөрес итеп сөйләде. Румия, кил әле, курчак турында сөйлә.

Румия. Бу курчак, аның белән уйныйлар. Курчакның башы, башында чәче, колаклары, матур күзләре, кашы, борыны, авызы бар. Аның гәүдәсе бар, муены, ике кулы, ике аягы бар. Мин курчак белән уйнарга яратам.

Тәрбияче. Булдырдың Румия!

Лунтик. Курчак, куян, машина – алар миңа барысы да ошадылар. Сез дә алар турында матур итеп сөйләдегез.

Тәрбияче. Балалар, машинаны, куянны, курчакны без бер сүз белән ничек атыйбыз? *(Уенчыклар.)* (Балаларны активлаштыру.) Уенчыкларны сакларга кирәк.

Лунтик. Ә безнең Айда уенчыклар юк.

Тәрбияче. Лунтик, тирә-ягыңа кара әле, безнең төркемдә уенчыклар бик күп һәм алар барысы да төрле материалдан ясалганнар. Балалар, килегез әле, әйдәгез, Лунтикка төркемдәге уенчыкларның нинди материалдан эшләнгәнен күрсәтик, аңлатыйк. Без уен уйныйбыз.

Балчыктан ясалган уенчыклар – балчык уенчыклар *(күрсәтә).*

Агачтан ясалган уенчыклар – агач уенчыклар *(күрсәтә).*

Пластмассадан ясалган уенчыклар – пластмасса уенчыклар *(күрсәтә).*

Резинадан ясалган уенчыклар – резина уенчыклар *(күрсәтә.)*

Лунтик. Ничек кызык, ә кәгазьдән ясалган уенчыклар буламы? *(Була, алар кәгазь уенчыклар. Без кәгазьдән уенчыклар ясадык.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә мин ясый белмим.

Тәрбияче. Балалар, Лунтикка кәгазьдән уенчыклар ясарга өйрәтәбезме? (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу кәгазьләр нинди формада? *(Квадрат.)*

Балалар тәрбияче ярдәмендә квадрат формасындагы кәгазьләрдән оригами ысулы белән уенчык ясыйлар.

Лунтик. Бигрәк матур уенчыклар, ә минем дусларымның беркайчан да кәгазь уенчыклар күргәннәре юк.

Тәрбияче. Балалар, Лунтикның дуслары кәгазь уенчыклар ясарга өйрәнсен өчен, без нәрсә эшли алабыз? *(Үзебез ясаган уенчыкларны бүләк итә алабыз.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар!

Тәрбияче балалар ясаган уенчыкларны матур бүләк сумкасына сала һәм Лунтикка бирә.

Тәрбияче. Лунтик, мә бу бүләк синең дусларыңа.

Лунтик. Балалар, миңа Айга кайтырга вакыт. Сез мине бик күп нәрсәләргә өйрәттегез: уенчыклар турында сөйләдегез, уеннар уйнадыгыз, уенчык ясарга өйрәттегез. Рәхмәт сезгә! Мин үземнең дусларыма сезнең хакта сөйләрмен һәм бүләкләрегезне тапшырырмын. Сау булыгыз!

# *Икенче бүлек.*
# КӨЗ

## Тема: “ПЕСИ БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН” ДИГӘН СЮЖЕТЛЫ КАРТИНА КАРАУ ҺӘМ ХИКӘЯ ТӨЗҮ

**Бурычлар:**

1) балаларның көзге үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту; сюжетлы картина персонажларын игътибар белән карау; эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү; иҗадилык элементларын күрсәтү осталыгын формалаштыру; песи һәм аның балалары исемнәрен сөйләмдә куллану; җәнлекләр гамәлен билгеләүче сүзләр хисабына сүзлек запасын арттыру һәм активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сенсор сәләтен, уен кагыйдәләрен үтәү теләген үстерү;

3) песиләргә карата сакчыл мөнәсәбәт, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Песи балалары белән” дигән сюжетлы картина, туп.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, урамда елның кайсы вакыты? *(Көз.)* (Балаларны активлаштыру.) (Күмәк кабатлаулар.) Көз турында нәрсә беләсез? *(Яфраклар саргая, яңгырлар ява, кошлар җылы якка китәләр, бакчада җиләк-җимешләр, яшелчәләр өлгерә.)* Урамда салкын. Ә менә песигә һәм аның балаларына өйдә бик җылы. Нинди песигә дисезме, хәзер белерсез. Балалар, килегез монда. Мин сезгә бер картина күрсәтәм. Бу картинаның исеме “Песи балалары белән” дип атала. Башта без картинаны карарбыз, аннан соң картина буенча хикәя төзербез. Картинада нәрсә сурәтләнгән? *(Песи һәм аның балалары.)* (Балаларны активлаштыру.) Песи нинди? *(Зур, матур, йомшак, йонлач.)* (Балаларны активлаштыру.) Песи балалары нинди? *(Кечкенә, шук, йонлач.)* (Балаларны активлаштыру.) Песи нәрсә эшли? *(Ул ята, ял итә.)* (Балаларны активлаштыру.) Песигә нинди исем бирергә була? *(Тамчы, Йомшаккай.)* Бу песи баласы нәрсә эшли? (Тәрбияче йомгак белән уйный торган песи баласына күрсәтә.) *(Йомгак белән уйный.)* (Балаларны активлаштыру.) Бу песи баласына нинди исем бирергә була? *(Йонлач, Шук, Пескәй, Мырау.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә бу песи баласы нәрсә эшли? (Тәрбияче сөт эчүче песигә күрсәтә.) *(Сөт эчә.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, бу песи сөт эчә. Телен чыгара да сөтне теленә тидерә. Ул сөтне ялап эчә. (Балаларны активлаштыру.) Бу песи баласына нинди исем бирик? *(Йонлач, Шук, Пескәй.)* (Балаларны активлаштыру.) Өченче песи баласы нишли? (Тәрбияче әнисе янында ятучы песигә күрсәтә.) *(Әнисе янында ята, ял итә.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйдәгез, аңа исем уйлыйк. *(Йонлач, Шук,*

*Пескәй, Каракай.)* Балалар, картинада сурәтләнгән песиләрне ничек атарга була? *(Песи гаиләсе.)* (Балаларны активлаштыру.) Ничек уйлыйсыз, эти песи кайда икән? *(Ауга киткән, башка бүлмәгә чыгып киткән.)* (Балаларны активлаштыру.) Уйлагыз әле, кәрҗинне бүлмәгә кем алып килде икән? *(Әби, әни, өй хуҗасы.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, өй хуҗасы песине, песи балаларын бик ярата, алар турында кайгырта.

Түгәрәккә басыгыз әле. Хәзер уйнап алабыз. Мин сезгә туп ыргытам, песи нәрсә эшли белә? дип сорыйм. Тупны тоткан бала, сорауга җавап бирә. Мәсәлән, тырный (уйный, сикерә, чаба, сөт эчә, йоклый, ашый һ. б.). Бер ишеткән сүзне кабатламаска кирәк. (Уен берничә тапкыр кабатлана.)

Хәзер картина буенча хикәя сөйләргә өйрәнәбез. Өйгә кайткач, әниегезгә песи һәм аның балалары турында сөйләрсез. Аңа бик күңелле булыр. Мин сезгә булышырмын. Картинада ... *(песи балалары белән)* сурәтләнгән. Ана песи зур ... *(матур, йонлач, йомшак.)* Аның янында өч... *(песи баласы.)* Алар кечкенә... *(шук, йонлач, уйнарга яраталар.)* Бер песинең исеме... (Йонлач.) Ул... (*йомгак белән уйный.*) Икенче песинең исеме... (Мырау.) Ул ... *(сөт эчә.)* Өченче песинең исеме... *(Шук.)* Шук ашап туйган һәм ... *(әнисе янына яткан.)* Эти песи ... *(ауга киткән.)* Өй хуҗасы кәрҗингә йомгаклар салган. Песи балалары ... *(йомгак белән уйнарга яраталар.)* Бу картина миңа ошады, чөнки песи балалары ... *(матур, йомшак, җылы, шаян, шук.)*

Без бүген нәрсә турында сөйләштек? Нәрсәләр турында хикәя төзедек? Песи һәм аның балалары сезгә ошадымы? Кемгә нинди песи баласы ошады? Сез бүген булдырдыгыз. Сез дә миңа бик ошадыгыз. Сорауларга матур итеп җавап бирдегез, картина буенча хикәя төзәргә өйрәндегез.

# *Өченче бүлек.*
# МИН – ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ

## Тема: ГАИЛӘ

**Бурычлар:**

1) балаларда гаилә әгъзасы буларак үзләре турында күзаллаулар формалаштыру; кеше тормышында гаиләнең әһәмиятен күрсәтү;

2) үз гаилә әгъзалары турында сөйләү осталыгын, кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен үстерү; сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; сүзлек байлыгын ныгыту;

3) гаилә әгъзаларына карата хөрмәт, ярату, горурлык хисләре, ихтирам тәрбияләү.

**Җиһазлар:** гаилә фотографияләре, төлке, бүре, аю һәм аларның балалары сурәтләнгән картинкалар; 3 рәткә ясалган рәсемнәр: (1) тавык, сарык, сыер; 2) бозау, чеби, бәрән; 3) үгез, әтәч, тәкә), “тылсымлы чәчәк” – чәчәкнең үзәге һәм балалар санынча таҗ яфракчыклары.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, түгәрәккә басабыз һәм бер-беребезгә менә бу матур шарны җибәрәбез. Шар сезнең кулда булганда, сез иркәләү сүзе уйлап, аны шар белән бергә күршегезгә җибәрә аласыз, ә ул бала тагын шулай күршесенә тапшыра, һәм шулай түгәрәк буенча уен дәвам итә. Балалар, бер-берегезгә карагыз әле. Менә сез барыгыз да хәзер бергә җыелдыгыз. Бер гаилә кебек. Бер гаиләдә яшәгән кешеләр кебек бергәләп уйныйсыз, саф һавага чыгасыз, ашыйсыз, йоклыйсыз. Балалар, ә өйдә сез кемнәр белән яшисез? *(Әти, әни, энем һәм мин. Әти, әни, әби, бабай һәм мин. Әти, әни, апа һәм мин.)* Бу гаилә дип атала. Бергәләп кабатлагыз әле: гаилә. *(Гаилә.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кеше тормышында гаилә иң кадерле нәрсә. Гаиләдә яшәүче кешеләр бер-берсен яраталар, бер-берсе турында кайгырталар. Әтиегез

гаиләдә нинди эшләр башкара? (Балаларның җаваплары.) Әниегез гаиләдә нинди эшләр башкара? (Балаларның җаваплары.) Әти-әниләрегез сезне яратамы? (Балаларның җаваплары.) Әти-әниләрегезнең яратуын сез ничек тоясыз, әйтеп күрсәтегез әле. (Балаларның җаваплары.) Әйе, балалар, күренеп тора, әти-әниләрегез сезне бик яраталар. Алар сезне сәламәт, акыллы, тәртипле, тәрбияле итеп үстерергә телиләр. Сезнең һәрберегез әти-әниләрегез өчен иң кадерле кеше. Алсу да, Марат та, Энҗе дә (һәр баланың исемен әйтеп чыгарга була) әти-әниләре өчен бик кадерле. Үзегезнең гаилә турында сөйләгез әле, гаиләгез белән сез нәрсәләр эшләргә яратасыз? (Балаларның җаваплары.) Гаилә фотографияләрен күрсәтегез. Фотографиядә кемнәр сурәтләнгән? (Балаларның җаваплары.) Искә төшерегез әле, әти-әниләрегез сезнең турыда ничек кайгырталар? (Балаларның җаваплары.) Балалар, хайваннарның да әниләре балалары турында кайгырталар, ә әтиләре булышалар. Әйдәгез, искә төшерик әле. Аю балаларын әниләре су коендырырга алып килә, аңа әтиләре дә булыша. (Тәрбияче картинка күрсәтә.) Әни бүре үзенең балаларын сөт белән сыйлый, ә әти бүре аларга азык алып кайта. (Тәрбияче картинка күрсәтә.) Әни төлке куркыныч янавын сизсә, балаларын теше белән эләктереп, башка куркыныч булмаган урынга ташый. (Тәрбияче картинка күрсәтә.) Менә, балалар, хайваннар да балаларын ничек карыйлар, саклыйлар, яшәргә өйрәтәләр. Балалар, “Балаларына әти-әниләрен табарга ярдәм итегез!” дигән уен уйныйк әле.

Тәрбияче мольбертка 3 рәткә тавык, ат, сарык, сыер, эт, көчек, бәрән, колын, чеби, бозау, үгез, тәкә, әтәч ясалган рәсем куя. Балалар, хайван һәм кошларның балаларын әти-әниләренә туры китереп, сызыклар белән тоташтыралар.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Бик дөрес эшләдегез. Хайваннар һәм аларның балаларын якын беләсез икән. Әйдәгез, “тылсымлы чәчәк” ясыйбыз. Моның өчен менә бу чәчәкләрдән бер таҗ яфрагын алып, әниләр турында ягымлы, матур сүз әйтергә кирәк. (Балалар сүзләр әйтәләр, тәрбияче таҗ

яфракларын чәчәкнең уртасына куя.) “Тылсымлы чәчәк” җыелып бетте. Әйдәгез, үзебезне мактап кул чабабыз. Балалар, без сезнең белән бүген нәрсә турында сөйләштек? (Балаларның җаваплары.) Әйе, балалар, гаиләнең кеше тормышында әһәмияте зур. Юкка гына мәкальдә “Әти-әни – чын дустым” дип әйтелмәгәндер. Әйдәгез, бу мәкальне истә калдырырга тырышып, бергәләп кабатлагыз: “Әти-әни – чын дустым”. (Балалар кабатлыйлар.) Булдырдыгыз! Гаиләләрегез бәхетле, имин булсын!

## *Дүртенче бүлек.*
## МИНЕМ ШӘҺӘРЕМ, МИНЕМ ВАТАНЫМ

### Тема: СИНЕҢ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫҢ – СИНЕҢ КУЛЛАРДА

**Бурычлар:**

1) балаларны куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру; тротуар, юлны аркылы чыгу урыны, машина юлы, куркынычсызлык каешы, регулировщик кебек яңа сүзләр һәм сүзтезмәләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү; туган як, шәһәр, транспорт төрләре турындагы белемнәрен ныгыту,

2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;

3) балаларда дустанә мөнәсәбәт, ярдәмләшү хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** шәһәр юллары, андагы машиналар, светофор сурәте белән макет, ат белән ишәкнең контурлы рәсемнәре, диаметры 20 сантиметрлы 1 әр кызыл, сары, яшел төсле түгәрәкләр, балалар санынча төрле машина сурәте белән эмблемалар, балалар санынча А5 форматындагы 1 кара һәм 5әр тар ак төстәге тасма кәгазьләр.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Кадерле балалар, барыгызга да матур көн телим!

Тәрбияче шәһәр юллары, андагы машиналар, светофор сурәте белән макет куя. Юл читендә бер-берсенә кара-каршы ат белән ишәкнең контурлы рәсемнәре куелган.

Тәрбияче. Балалар, бүген сез бакчага килгәндә юлда нәрсәләр күрдегез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Юлда машиналар күп идеме? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, юлда машиналар бәреп китмәсен өчен, һәлакәтләргә очрамас өчен нишләргә кирәк? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, юл йөрү кагыйдәләрен белергә һәм аларны үтәргә кирәк. Балалар, бу рәсемгә карагыз әле, сез нәрсәләр күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу юл, анда машиналар күп. Балалар, юлда сез нинди машиналар күрәсез? *(Җиңел машина, йөк машинасы, автобус.)* Тагын нәрсәләр күрәсез? *(Трамвай, троллейбус.)* Балалар, машиналарны, автобусларны, газельләрне, трамвайларны, троллейбусларны башкача бер сүз белән ничек әйтәләр? *(Транспорт.)* (Балаларны активлаштыру.) Машиналар, автобуслар нинди? *(Зур, кечкенә, кызыл, сары, кара, яшел.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, юлда йөрергә безгә нәрсә ярдәм итә? Мин табышмак әйтәм, җавабын тапсагыз, нәрсә икәнен әйтә алырсыз.

Җәен, кышын, язын, көзен,
Иртән, кичен, көндезен,
Ача-йома өч күзен,
Телсез әйтәдер сүзен –
Бик тиз аңлыйлар үзен.
Бу нәрсә? *(Светофор.)*

(Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Әйе, балалар, светофор. Светофордагы өч төснең нәрсә аңлатканын искә төшереп үтик әле: кызыл төс янса ... *(Машиналар туктап тора, җәяүлеләр юл аша чыга (чөнки аларга яшел төс яна.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Сары төс янса... *(Машиналар кузгалып китәргә әзерләнә.)* Яшел төс янгач ... *(Машиналар кузгалып китә.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Дөрес, балалар, менә хәзер светофорда кызыл төс яна, димәк, безгә әлегә юл ябык. Ә хәзер светофорның ни өчен кирәк булуын искә төшерик: светофор җәяүлегә һәм машиналарга бер-берсенә комачаулык тудырмыйча хәрәкәт итү өчен кирәк. (Балаларны активлаштыру.) Ул кая куела? *(Ул юл чатларына куела.)* Булдырдыгыз! Светофор булмаганда яисә ул эшләмәсә, аны кем алыштыра? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, хәрәкәтне көйләүче полиция хезмәткәре. Аны регулировщик диләр. Бергәләп кабатлыйк әле: регулировщик. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, без сезнең белән "Светофор уены" уйнап алыйк.

Тәрбияче яшел төсле түгәрәк күтәрсә, балалар ирекле рәвештә күңелле бию башкаралар; сары төс күтәрсә – бер урында биеп торалар;
Кызыл төскә – туктыйлар.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, бу машиналар бер якка баралар, ә икенчеләре аларның юлларын кистереп, икенче якка баралар. Светофорның кызыл уты янгач, бер яктагы машиналар туктый, ә икенчеләре кузгала, чөнки аларга яшел ут яна. (Тәрбияче сөйләмен макетта күрсәтә.) Мондый юллар кисешкән юллар урам чаты дип атала. Бергәләп кабатлыйк: юллар кисешкән урын, урам чаты. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, карагыз, безнең макетта бер юл кара, ә икенчесе соры төстә. Кара юл киңлеге буенча нинди? *(Киң.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә соры юл нинди? *(Тар.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, киң юллар машиналар, транспорт йөрер өчен кирәк. Ә ул ни өчен шундый киң икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны

активлаштыру.) Әйе, чөнки машиналар зур һәм алар бик күп. Ә тар юл кешеләр йөрү өчен кирәк. Бу юлдан машиналар йөрми. Бу юл тротуар дип атала. Бергәләп кабатлыйк әле. *(Тротуар.)* Булдырдыгыз! Балалар, җәяү йөргән кешеләрне җәяүлеләр диләр. Бергәләп кабатлыйк. *(Җәяүле.)* Әгәр җәяүле кеше машина йөртә икән аны кем диләр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, ул машина йөртүче, шофёр була һәм ул киң, кара юлдан йөри. Без хәзер барыбыз да машина йөртүче булырбыз.

Тәрбияче машина сурәте белән эмблемалар тарата, балаларга куркынычсызлык каешларын эләктерергә һәм төркем буйлап йөрергә тәкъдим итә. Балаларга бәрелешү куркынычлыгы барын һәм сак булырга кирәклеген исләренә төшерә.

Тәрбияче. Булдырдыгыз! Балалар, безнең макеттагы ат белән ишәк машина йөртүчеләрме, әллә җәяүлеләрме? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Алар кайда басып торалар: машина йөри торган юлдамы, әллә тротуардамы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, менә ат белән ишәк очрашырга сүз куешкан булганнар, ләкин алар юлны аркылы чыгарга куркалар, чөнки юлда транспорт күп. Бер якта светофорның кызыл уты яна, икенче якта яшел уты яна. Ат белән ишәк юл аркылы кайчан чыгарга кирәклеген белмиләр. Аларга булышабызмы? (Балаларны активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, машиналар йөри торган юлны матур ак тасмалар бизи. Бу нәрсәне аңлата икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу җәяүлеләргә машина йөри торган киң юлны аркылы чыгу өчен билгеләнгән урын. Светофорның кызыл уты янгач, машиналар туктый һәм җәяүлеләр шул билгеләнгән җирдән юлны аркылы чыгалар. Бу – юл йөрү кагыйдәсе. Бергәләп кабатлыйк. *(Юл йөрү кагыйдәсе.)* Ат бик кыю, ул юлны аркылы чыгарга әзер, кайсыгыз атка ярдәм итә.

Бер бала макет янына чыга һәм атны җәяүле юлыннан аркылы чыгара, тәрбияче машинаны юлдан йөртә.

Тәрбияче. Булдырдың! Балалар, карагыз әле, ишәк юлны ярамаган урыннан кистереп чыгарга җыена. (Тәрбияче макетта күрсәтә.) Ул дөрес эшлиме? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ишәк, син дөрес эшләмисең. Балалар, юл аркылы дөрес чыгарга кем өйрәтә?

Бер бала макет янына чыга һәм ишәкне җәяүле юлыннан аркылы чыгара, тәрбияче машинаны юлдан йөртә. Ат белән ишәк очрашалар.

Тәрбияче. Булдырдың! Балалар, ат белән ишәк сезгә рәхмәт әйтәләр. Балалар, без бүген нинди юл йөрү кагыйдәләрен белдек? Җәяүлеләр йөри торган юл ничек дип атала? Машина юлы нинди? Машина юлын аркылы чыга торган юл нинди төс белән билгеләнгән? (Балаларны активлаштыру.)

Тәрбияче балаларга А5 форматындагы кара һәм 5әр тар ак төстәге тасма кәгазьләр тарата.

Тәрбияче. Балалар, менә бу киң машина юлы булыр, ә без җәяүлеләр өчен юлны аркылы чыгу урынын шушы ак тасмалар белән ясарбыз. Ак тасмаларны бер-бер артлы бераз ара калдырып кара “юлга” ябыштырырбыз. Безнең шәһәребез матур булсын. Юллары тигез куркынычсыз булсын! Булдырдыгыз, балалар!

## *Бишенче бүлек.*
# ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

## Тема: КЫШ БАБАЙ ТУРЫНДА ХИКӘЯ ТӨЗҮ

**Бурычлар:**

1) тәрбияченең сүзле күрсәтмәләре (схема) буенча күмәк хикәя төзү күнекмәләре формалаштыру; балаларны тәрбияче һәм яшьтәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү;

2) игътибарны, фантазияне, сөйләмдә еш кулланыла торган исемнәрне, сыйфатларны, фигыльләрне куллану, күмәк эшләү осталыгын үстерү;

3) Яңа елга карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** чыршы, Кыш бабай, конфет, Кар кызы сурәтләнгән картиналар, туп.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә кечкенә картина күрсәтәм, сез картинада сурәтләнгән предметка сүзләр уйлагыз. (Тәрбияче чыршы сурәтләнгән рәсем күрсәтә.) Бу нәрсә? *(Чыршы.)* Чыршы нинди? *(Матур, яшел, чәнечкеле, купшы, исле, биек һ. б.).* (Әгәр балалар предметның билгеләрен атауда авырсынсалар, тәрбияче өстәмә сораулар бирә). Чыршыга кагылсаң, ул ... *(чәнчи.)* Димәк, чыршы чәнечкеле.

Кыш бабай, конфет, Кар кызы сурәтләнгән рәсемнәр белән тәрбияче шундый ук эш үткәрә

Тәрбияче. Хәзер без Кыш бабайның балалар бакчасына юл эзләве турында хикәя төзәрбез. Мин җөмләне башлыйм, сез дәвам итәрсез. Күптән көтелгән ... *(кыш)* җитте. Бөтен җирне ... (*кар*) каплады. Кыш бабай капчыгына ... *(бүләкләр)* салды. Зур ... *(чанасына)* утырды да ... *(балалар бакчасына)* ашыкты. Кыш бабай барды, барды һәм ... *(адашты.)* Як-ягына карады, кайсы... (*якка*) барасын белмәде. Кинәт кенә башын тавыш

ишеткән якка ... *(борды)* һәм ... *(Кар кызын)* күрде. Кар кызы да ... *(Кыш бабайны)* күреп алды. Кар кызы бабайдан сорады: “Син урманда нишлисең?” Кыш бабай аңа болай диде: “Мин ... *(адаштым.)* Балалар бакчасына юлны таба алмыйм”. Кар кызы бабайны тынычландырды: “Юлны табарга мин булышырмын. Юлда минем ... *(эзләремне)* күрәсеңме? Мин балалар бакчасында булдым, балаларның ничек итеп Яңа елга әзерләнгәннәрен карадым. Минем эзләр буенча барсаң, ... *(балалар бакчасын табарсың)”.* Кыш бабай шулай эшләде дә. Ул Кар кызы эзләре буенча барды, барды ... *(балалар бакчасын тапты)*, балаларга ... *(бүләкләр)* бирде”. (Сөйләү барышында тәрбияче коврографта хикәя фрагментларын күрсәтә ала.)

Сезгә хикәя ошадымы? Кич белән әтиегезгә, әниегезгә сөйләрсез. Истә калдыру өчен, мин тагын бер тапкыр эчтәлеген сөйләргә кушам. Балалар, хикәя ничек башланды? Кыш бабай нәрсә эшләде? Юлда аның белән нәрсә булды? Урманда Кыш бабай кемне очратты? Кыш бабай аннан нәрсә сорады? Кар кызы ничек дип җавап бирде? Кар кызы Кыш бабайны ничек тынычландырды? Кыш бабай балалар бакчасына барып җитә алдымы? Ул балаларга нәрсә алып килде?

Хәзер уйнап алабыз. Кыш бабайның капчыгынданиләр барын без белмибез. Нәрсәләр бар икән анда, уйлыйк әле. Мин сезгә сорау бирәм һәм туп атам. Җавап биргәч, тупны миңа атыгыз. Кыш бабайның капчыгында түгәрәк бүләкләр бар. Нәрсә икән ул? *(Апельсин, алма, шарик, туп, сәгать, күзлек һ. б.)*. Кыш бабайның капчыгында турыпочмаклы предметлар да бар. Нәрсә булырга мөмкин? *(Китап, буяулар, фото өчен рамка, компьютер, картина, блокнот һ. б.)*. Кыш бабайның капчыгында баллы күчтәнәчләр бар. Нәрсә икән ул? *(Апельсин, алма, конфет, туңдырма, шоколад, торт һ. б.)*.

Балалар, без бүген нәрсә белән шөгыльләндек? Нәрсә истә калды?

## Тема: ӘКИЯТИ ҖӘНЛЕКЛӘРНЕҢ КЫШКЫ МАҖАРАЛАРЫ

**Бурычлар:**

1) тәрбиячenең сүзле күрсәтмәләре (схема) буенча күмәк хикәя төзү осталыгын формалаштыру; хайваннарны тасвирлаганда хаталарны табуга күнектерү;

2) игътибарны, конкрет-образлы фикерләүне, сөйләмне, күмәк эшләү осталыгын үстерү;

3) Яңа елга карата кызыксыну, хайваннарга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** 2 рәсем, бер рәсемдә авыл йорты, икенче рәсемдә урман сурәтләнгән; һәр балага җитәрлек санда йорт (сыер, ат, сарык, кәҗә) һәм кыргый хайваннар (аю, бүре, төлке, тиен, куян), хат.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, сезнең алда карточкалар ята. Бу карточкаларны ике группага бүләргә кирәк. Авыл йорты ясалган урынга йорт хайваннарының рәсемнәрен, урман ясалган урынга – кыргый хайваннарның рәсемнәрен куегыз. Ни өчен аюны урман сурәтләнгән урынга куясың? *(Аю – кыргый хайван, ул урманда яши.)* Ни өчен сыерны авыл йорты сурәтләнгән урынга куясың? *(Сыер – йорт хайваны, ул кеше белән яши.)* (Уен шулай дәвам итә.)

Әкияти хайваннарның урманда ничек итеп Яңа ел каршылаулары турында хикәя төзербез. Мин җөмләне башлармын, сез дәвам итәрсез. Бервакыт урманда хайваннар җыелыштылар һәм ... *(Яңа ел)* үткәрергә булдылар. Алар иң матур ... *(чыршы)* сайлап алдылар. Аны ... *(бизәү)* турында уйлый башладылар. “Мин чыршыга кишер эләм”, – диде ... *(Куян.)* “Мин гөмбәләрдән гирлянда ясыйм”, – диде... *(Тиен.)* “Мин чыршыны кар бөртекләре белән бизим”, – дип улады ... *(Бүре.)* “Ә мин йонлач озын койрыгым белән чыршы тирәсен чистартам”, – диде ... *(Төлке.)* Кинәт кенә чыршы янына зур

сакаллы ... (*Кыш бабай*) килеп чыкты. Ул әкияти хайваннарны Яңа ел белән котлады. Ничек итеп котлады икән, Алсу? (Мансур, Әмир һ. б.). (Балаларның җаваплары.) Кыш бабай хайваннарга ... *(бүләкләр)* таратты. Куянга җылы ... *(бияләйләр),* Бүрегә бәйләнгән ... *(бүрек),* Төлкегә кызгылт сары... *(тун)*, Тиенгә зур нарат ... *(күркәсе)* бүләк итте. Хайваннар Кыш бабайга ... *(рәхмәт)* әйттеләр. Аның белән чыршы тирәли ... *(әйлән-бәйлән)* уйнадылар, җырлар ... *(җырладылар),* ... *(биеделәр.)* (Сөйләү барышында тәрбияче ковpографта хикәя фрагментларын күрсәтә ала.)

Хикәя сезгә ошадымы? Ә әниегез аны ишетмәдеме? Яхшырак истә калдыру өчен һәм кич белән әти-әнигә сөйләү өчен, хикәяне кабатлап чыгыйк. Хикәя нинди сүзләр белән башланды? Нинди хайваннар бергә җыелган? Хайваннар бизәү өчен нинди чыршыны сайлап алганнар? Тиен чыршыны ничек бизәгән? Куян чыршыга нәрсә элгән? Бүре нәрсә белән бизәгән? Төлке нәрсә эшләгән? Кыш бабай хайваннарга нинди бүләкләр тапшырган? Яңа елны алар ничек каршы алганнар?

Ишек шакыйлар, почтальон хат китерә.

Тәрбияче. Балалар, бу хат Кыш бабайдан. Менә ул нәрсә дип яза: “Мин урманда булдым. Хайваннарны Яңа ел белән котладым”. Кыш бабай хайваннар турында яза. Балалар, Кыш бабай ялгышкан бугай. Тыңлагыз әле. Куян турында ул болай дип яза: “Куянның колаклары кечкенә, койрыгы озын йонлач. Ул ботактан ботакка сикерә”. Балалар, куян турында Кыш бабай дөрес язганмы? Аны төзәтегез. *(Куянның колаклары озын, койрыгы кечкенә. Ул тиз сикерә һәм йөгерә.)*

Төлке турында ул болай дип яза: “Төлкенең туны ак, койрыгы кыска. Төлке кышка гөмбәләр киптерә”. Кыш бабай нинди ялгыш җибәргән? *(Төлкенең туны кызгылт сары, койрыгы озын йонлач.)*

Бүре турында Кыш бабай болай дип яза: “Бүренең йоны кызгылт сары йонлач, арткы тәпиләре озын. Бүре тиз йөгерә, кишер ярата, куяннардан курка”. Сез Кыш бабай белән

килешәсезме? *(Юк. Бүренең йоны кыска, соры төстә. Бүре тиз йөгерә.)*

Тиен турында болай дип язган: “Тиеннең колаклары озын, тешләре үткен. Тиен бик хәйләкәр, тычканнарны аулый, тавыкларны урлый”. Кыш бабай дөрес язганмы? *(Юк. Тиеннең койрыгы йонлач. Ул кышка гөмбәләр киптерә.)*

Балалар, Кыш бабай безгә хайваннар турында сөйләргә ашыккан, ләкин барысын да бутаган. Ул арыгандыр, чөнки Кыш бабай бик карт. Кыш бабай ял итсен, көч җыйсын.

## Тема: ЧЫРШЫКАЙ-КУПШЫКАЙ

**Бурычлар:**

1) Яңа ел бәйрәме, чыршы турында күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү.

2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, хикәя төзү осталыгын, кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, бармаклар моторикасын үстерү;

3) күтәренке кәеф атмосферасын тудыру.

**Җиһазлар:** чын яки ясалма чыршы, һәр балага конверт (аның эчендә төрле зурлыктагы өчпочмак, бер куян сурәте), чыршыга элү өчен балалар санынча уенчыклар.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, игътибар белән тыңлагыз әле, мин сезгә бер агач турында табышмак әйтәм: “Җәен, кышын бер төстә”. Нинди агач икән ул? *(Чыршы.)* Дөрес, чыршы. Чыршы җәен дә, кышын да нинди төстә? (*Яшел.)* Әйе, яшел төстә. Ә сезнең чыршы агачын кайда күргәнегез бар? *(Яңа елда, урманда, паркта, балалар бакчасы мәйданчыгында, музыка залында, бакчада һ. б.)* (Балаларны активлаштыру.) Хәзер мин сезгә чыршы турында бер шигырь укыйм:

Әй чыршыкай,чыршыкай,
Үзең бигрәк купшыкай.

Яшел күлмәк кигәнсең,
Күп бизәкләр элгәнсең. (Мөҗәһит.)

Шигырьдә чыршы турында нинди иркәләү сүзләре әйтелә? *(Чыршыкай, купшыкай.)* (Балаларны активлаштыру.) Нинди ул чыршы? Аның турында тагын нинди сүзләр әйтергә була? *(Кечкенә, яшел, энәле, хуш исле, матур, төз, чын, ясалма.)* (Активлаштыру.) Балалар, мин сезгә уенчыклар бирәм. Сез аларны чыршыга элегез һәм нинди уенчык элүегез турында әйтегез. Алсу, син чыршыга нәрсә эләсең? *(Мин чыршыга шар эләм.)* Әмир, ә син чыршыга нәрсә эләсең? *(Мин чыршыга конфет эләм.)* (Тәрбияче һәр баладан сорап чыга.) Булдырдыгыз, балалар! Менә чыршыны бизәп тә куйдыгыз. Ул тагын да матурланды, купшыланды. Тиздән Яңа ел бәйрәме булыр. Яңа ел бәйрәменә кемнәр килә? *(Кыш бабай, Кар кызы, җәнлекләр һ. б).* Дөрес, Кыш бабай килер, бүләкләр алып килер. Азат, Кыш бабай сиңа бүләккә нәрсә алып килер? *(Кыш бабай миңа бүләккә уенчык машина алып килер.)* (Тәрбияче балалардан сорап чыга.) Балалар, бармакларга гимнастика ясыйбызмы? *(Әйе.)* Бармакларга гимнастика ял, күңел күтәренкелеге бирә. Гимнастиканы барыгыз да бергә эшләргә тырышыгыз. Бергә эшләгәндә, тагын да күңеллерәк булыр, бармакларга көч тә күбрәк килер. Әйдәгез, башлыйбыз!

Безнең каршыда чыршы *(бармаклар бер-берсенә үрелә, баш бармаклар чыршының очын ясыйлар),*

Күркәләр һәм энәләр *(куллар йодрыклана, аннан имән бармаклар турайтыла),*

Шарлар, фонарьлар *(кул учлары, бармаклар белән шар ясыйлар),*

Куяннар һәм шәмнәр *(имән, урта һәм баш бармактан “колаклар” ясыйлар, калган ике бармакны учларга таба бөклиләр),*

Йолдызлар һәм кешеләр *(учлар өстәлгә куела, бармаклар җәелә, урта һәм имән бармаклар өстәлгә куела).*

Булдырдыгыз, балалар. Менә бармакларга да гимнастика ясадыгыз. Ял итеп алдыгыз. Кәефләрегез дә күтәрелеп китте.

Балалар, чыршы янына якынрак килегез. Чыршы турында кечкенә хикәя төзеп карыйк. “Бу чыршы. Ул урманнан килгән. Чыршы кечкенә, яшел, энәле, хуш исле. Аның ботаклары күп. Ботакларга уенчыклар эленгән”. Чыршыга уенчыкларны кем элде? *(Балалар.)* Кем нинди уенчык элде? Өстә нинди уенчыклар эленгән? Ә аста? Уртада? (Балаларның җаваплары.) (Тәрбияче хикәяне 2–3 баладан сөйләтә.) Балалар, һәрберегезнең өстәл өстендә конверт бар. Конверт эчендә нәрсә бар икән, ачып карагыз әле? *(Өчпочмаклар.)* Ничә өчпочмак? (*Өч*.) Өчпочмаклар нинди төстә? *(Яшел.)* Алар барысы да бертөрле зурлыктамы? (*Юк*.) Берсе зур, икенчесе кечерәк, өченчесе тагын да кечкенә. Шул өчпочмаклардан өстәл өстендә чыршы төзегез. (Балалар төзиләр.) Конверттан алып чыршы төбенә куян куегыз. Куян кая качкан? *(Куян чыршы төбенә качкан.)* (Балаларны активлаштыру.) Менә нинди матур булды. (Тәрбияче шигырь укый.)

Чыршы үсә урманда,
Чыршылар бик күп анда,
“Уенчыклар эләм”, – дип,
Сикереп йөри куян да. *(К. Даян)*

(Балалар тәрбияче артыннан аның белән бергә шигырьне кабатлыйлар.) Балалар, сез бүген нәрсәләр белдегез? Бигрәк тә сезгә нәрсә ошады? (Балаларның җаваплары.) Балалар, сез бүген мине шатландырдыгыз. Бик тырыштыгыз! Тиздән Яңа ел бәйрәме җитә. Мин сезнең барыгызга да күтәренке кәеф телим!

## *Алтынчы бүлек.*
## КЫШ

### Тема: АП-АК ТУНЛЫ КЫШ

**Бурычлар:**

1) балаларның кыш турындагы белемнәрен киңәйтү; танып белү һәм эзләнүгә омтылыш формалаштыру; “аста”, ”өстә”,

“төбендә” һәм эшчәнлектә кулланган башка фразалар, чагыштыру сыйфатлары хисабына сүзлек запасын активлаштыру, “у” авазын ныгыту;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү;

3) балаларда кызыксыну, бердәм хезмәт хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** П. И. Чайковскийның «Времена года» альбомыннан өзекләр аудиоязмасы, посылка, конверт, И. Шишкинның «Кыш», В. Васнецовның «Кышкы йокы» репродукцияләре, коллектив эш өчен ватманда кышкы пейзаж күренеше, һәр бала санынча кар бөртекләре (аларның артына табышмаклар язылган.)

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, хәзер елның кайсы вакыты? *(Кыш.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кыш икәнен каян беләсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Табигатьтә нинди үзгәрешләр бар? *(Кар ява, көннәр суык.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, сез бүген бакчага килгәндә туңмадыгызмы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, урамда бүген җил. Җил нинди? (*Бүген җил суык, көчле*.) (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ул ничек улый? *(У-у-у!)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе балалар, карлы, суык чын кыш җитте. Бергәләп кабатлыйк: карлы, суык чын кыш җитте. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, монда кемдер посылка калдырып киткән, анда конверт бар.

Тәрбияче конверттан кар бөртекләре һәм кыш тасвирланган картина күчермәләре ала.

Тәрбияче. Балалар, бу картиналарны безгә кем җибәргән икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, аны безгә кыш җибәргән. Балалар сезгә

кыш ошыймы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Сез кышны ни өчен яратасыз? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) (Тәрбияче балалар белән кыш тасвирланган картиналар карыйлар.) Әйе, кыш матур ел фасылы. Карагыз әле кышны рәссам ничек сурәтли. Балалар, кыш нинди төсләр ярата? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, кыш ак, зәңгәрсу, соры төсләрне ярата, ләкин ак төс күбрәк. Бергәләп кабатлыйк: кыш ак, зәңгәрсу, соры төсләрне ярата, ләкин ак төс күбрәк. Балалар, кар нинди була? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Кар ак, суык, йомшак, ялтырый. Бергәләп кабатлыйк: кар ак, суык, йомшак, ялтырый. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, урамнарны, йортларны, агачларны, бөтен җирне кар каплауны нәрсә белән чагыштырырга була? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, кар белән бөтен җирне каплауны ак тун, ковёр, одеял, башлык, юрган белән чагыштырырга мөмкин. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кар нәрсәдән тора? *(Кар бөртекләреннән.)* Булдырдыгыз! Балалар, әйдәгез, без дә кар бөртекләре булыйк та бөтерелеп уйныйк, очыйк.

Тыныч, матур көй яңгырый, балалар текст эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.

Тәрбияче. Кар бөртеге, кун кулга,
Бераз ял ит син шунда.
Бер карасам, гел боз син,
Бер карасам, йолдыз син.
Искитәрлек, матур син.
Ничек җирдә ятарсың?
Ашыкмачы, очынма!
...Кар бөртеге учыма
Төште дә бөтерелеп,
Мактаудан бетте эреп!..

Балалар, сез онытмадыгызмы, безнең дә кар бөртекләре бар бит. Аны безгә кыш җибәргән. (Тәрбияче һәр балага кар бөртеге таратып чыга.) Балалар, игътибар белән карагыз әле, кар бөртекләре нинди? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, кар бөртекләре җиңел, матур, ак, үтә күренмәле, челтәр кебек. Бергә кабатлыйк: кар бөртекләре җиңел, матур, ак, кисеп ясалган, үтә күренмәле, челтәр кебек. (Балаларны активлаштыру.) Кар бөртекләре нәрсәгә охшаган? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, кар бөртекләре йолдызларга, чәчәкләргә охшаганнар. Балалар, ә кар бөртекләре нишлиләр? *(Очалар, җиргә төшәләр, бөтереләләр, эриләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә һавадан кар бөртекләре күп булып төшүне ничек дип атыйлар? *(Кар яву.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, урамда ничек күп итеп кар яуган. (Тәрбияче мольбертка ясалып бетмәгән рәсем куя). Балалар, ә бу рәсемдә кар бөтенләй юк. Бу агачларны, йортларны кыш кар белән капларга оныткан. Балалар, әйдәгез, кышка булышыйк. Кулларыгыздагы кар бөртекләрен картинага ябыштырыйк. (Тәрбияче тыныч музыка кабыза, балалар кар бөртекләрен картинага ябыштыралар.) Балалар, бер-берегезгә комачауламагыз, ярдәм итегез.

Йомшак кына кар яуды,
Бөтен җирне каплады.
Ап-ак булды болыннар,
Ап-ак булды киң кырлар.

Тыныч кына кар бөртекләре төшә. Агач өстенә дә төшә, агач төбенә дә төшә, тыныч йоклагыз, агачлар. Бөтен җир өстен кар каплаган, аларга суык куркыныч түгел. Балалар, сез, туңмас өчен, нәрсәләр киясез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Әйе, җылы киемнәр кигәнсез, шуңа туңмагансыз. Агачларны да кар каплагач, аларга да җылы. Кар бөртекләре нинди? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны

активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Сез бүген бик актив булдыгыз.

## Тема: КЫРГЫЙ ХАЙВАННАР

**Бурычлар:**

1) кыргый җәнлекләр турындагы күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү;

2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хикәя төзү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен үстерү;

3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну уяту.

**Җиһазлар:** урман ясалган картинка; бүре, төлке, аю, куян, керпе сурәтләнгән картинкалар; төлке, аю, тиен, куян уенчыклары, “Куяннар белән төлке” уены өчен аудиоязма (Р. Касыймов көе.)

### Эшчәнлек барышы

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Чиратлап янәшә басып торган иптәшләрен сәламлиләр: “Исәнме, Алсу!
Мин сине күрүемә бик шат!”

Тәрбияче. Балалар, мин дә сезне күрүемә бик шат! Барыгызга да матур көн телим! (Тәрбияче җыелма кесәгә урман ясалган картинка куя.) Балалар, бу нәрсә? *(Урман.)* Бик дөрес! Урманда елның кайсы вакыты? *(Кыш.)* Кыш икәнен каян белдегез? (Балаларның җаваплары.)

Тәрбияче җыелма кесәгә бер-бер артлы кыргый хайваннар (бүре, төлке, аю, куян, тиен, керпе) сурәтләнгән картинкалар куя. Җәнлекләрнең исемнәрен атап чыгалар.

Тәрбияче. Балалар, бер сүз белән бу җәнлекләрне нәрсә дип атыйлар? *(Кыргый җәнлекләр.)* Дөрес, кыргый җәнлекләр дип атыйлар. Кыргый хайваннар дип тә әйтергә була. Балалар, бүре, төлке, аю, куян, тиен, керпе кайда яшиләр? *(Урманда. Бүре урманда яши. Куян урманда яши. Төлке урманда яши. Аю*

*урманда яши. Куян урманда яши. Тиен урманда яши. Керпе урманда яши.)* Әйе, бүре, төлке, аю, куян, тиен, керпе урманда яшиләр, алар – урман җәнлекләре. (Балаларны активлаштыру.) Әйдәгез, “Кайсы җәнлеккә нәрсә кирәк?” уенын уйныйк. Кайсы җәнлек нәрсә белән туклана икән?

Тәрбияче бал, балык, кура җиләге, тавык, чеби, куян, ит, колбаса, кишер, кәбестә, чикләвекләр, гөмбәләр, алма, тычкан сурәтләнгән картинкалар күрсәтә. (Картинкаларны лотодан да алырга була.)

Тәрбияче. Балалар, бу нәрсә? *(Бал.)* Бал кайсы җәнлеккә кирәк? *(Аюга.)* (Шул рәвешле башка рәсемнәр белән дә эш алып барыла.) Булдырдыгыз, балалар! Кайсы җәнлекнең нәрсә белән тукланганын, нәрсә яратканын беләсез. Балалар, урманга сәяхәткә барып кайтабызмы? Барыгыз да минем янга килегез әле! (Тәрбияче балаларны кыргый җәнлек уенчыклары куелган уен почмагына алып килә.) Балалар, бу нәрсә? (Төлке күрсәтә.) *(Төлке.)* Әйдәгез, төлке турында сөйләшик. Ул нинди төстә? *(Җирән, кызыл, сары.)* Төлкегә нинди сыйфат хас әле, ул нинди? *(Хәйләкәр.)* (Балаларны активлаштыру.) Кем төлке турында сөйләп күрсәтә? (Тәрбияче 1–2 баладан сорый.) *(Бу төлке. Ул җирән, хәйләкәр, өнендә яши.)* Бу нәрсә? *(Аю.)* Аюга нинди сыйфатлар хас, ул кайда яши? (Балаларның җаваплары.) Аю турында кем сөйли? (Тәрбияче 1–2 баладан сорый.) *(Бу аю, ул зур, чалыш аяклы, кышын өнендә йоклый.)* (Активлаштыру.) Бу нәрсә? (*Тиен*.) Балалар, тиенгә нинди сыйфатлар хас, ул кайда яши? *(Менә тиен, ул кечкенә, җитез, агач куышында яши.)* Бу нәрсә соң? (Куянга күрсәтә.) Куян нинди, кайда яши? *(Менә куян, ул ак, тиз чаба, яхшы сикерә, ул куак астында яши.)* (1–2 бала куян турында сөйлиләр.) Булдырдыгыз, балалар! Җәнлекләр турында бик кызыклы итеп сөйләдегез. Балалар, ничек уйлыйсыз, җәнлекләрне рәнҗетергә ярыймы? *(Юк, аларны сакларга кирәк.)* Әйе, җәнлекләр табигатькә күп файда китерәләр. Аларга тимәсәң, алар кешегә тимиләр. Җәнлекләрне яратыгыз! Балалар, “Куяннар белән төлке” уенын уйныйк әле. (Тәрбияче аудиоязма куя.) Балалар, күңелле итеп уйнадыгыз. Мин әйткән җөмләләрне игътибар белән тыңлагыз

да дәвам итегез: Куянның колаклары озын, ә аюныкы ... *(кыска.)* Төлкенең койрыгы озын, ә куянныкы ... *(кыска.)* Тиеннең койрыгы озын, ә аюныкы ... *(кыска.)* Тиеннең аяклары кыска, бүренеке ... *(озын.)* Аюның Койрыгы кыска, ә төлкенеке ... *(озын.)* Керпенең колаклары кыска, ә куянныкы ... *(озын.)* Бик яхшы! Дөрес итеп җавап бирдегез. Балалар, менә миндә "Тылсымлы капчык" бар. Аның эчендә бер җәнлек яшеренгән. Тотып капшап карагыз әле, нәрсә икән ул? (Балалар куян икәнен әйтәләр. Әйтә алмасалар, тәрбияче табышмак әйтә.) Әйе балалар, безгә тагын бер куян кунакка килгән. "Куянкай" дип буламы? *(Әйе.)* "Йомшаккай"? *(Әйе.)* "Тиенкәй"? *(Юк.)* Бик дөрес, балалар, "куян", "куянкай", "йомшаккай", "куркаккай". Куянны шундый матур сүзләр белән атарга була. Балалар, сез бүген нәрсә турында белдегез? Бигрәк тә сезгә нәрсә ошады, нәрсә күңелегезгә кереп калды? (Балаларның җаваплары.) Мин бүген сездән бик канәгать. Җәнлекләрне яратыгыз. Күрсәгез, аларны игътибар белән күзәтегез!

## *Җиденче бүлек.*
## ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

### Тема: ХӘРБИ ҺӨНӘРЛӘР

**Бурычлар:**

1) балаларның хәрби һөнәрләр һәм аларның төрләре, хәрби техника турында белемнәрен формалаштыру; исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү;

2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтен, фикерләвен үстерү;

3) балаларда хәрби һөнәрләргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** А4 форматында хәрбиләр (диңгезче, чик сакчысы, разведчик, танкчылар) сурәтләнгән рәсемнәр, танк рәсеме, малайлар санынча "медаль", дугалар, шакмаклар, кеглилар, пакет, балалар санынча рәсем ясау өчен кәгазь битләре, каләмнәр.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, уң кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең уң кулыгыз! Уң кулыгызга сокланып карагыз! Сул кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең сул кулыгыз! Уң кул бармаклары чиратлап сул кул бармаклары белән исәнләшәләр: бер-берегезгә шатлык, тынычлык теләгез. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кешеләр тыныч яшәсен, эшләсен, балалар бакчага йөрсен, мәктәптә укысын өчен нәрсә кирәк? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, кешеләр тыныч яшәсен, эшләсен, балалар бакчага йөрсен, мәктәптә укысын өчен илдә тынычлык кирәк. Бергәләп кабатлыйк: тынычлык. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, безнең илебездә, Ватаныбызда тынычлыкны кемнәр саклый? *(Ватанны, илне саклаучылар.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, безнең илдә сугыш булмасын өчен Ватан сакчылары бөтен көчләрен куя. Балалар, Ватанны саклаучылар бәйрәмен кайчан билгеләп үтәләр? (Балаларның җаваплары.) Булдырдыгыз, балалар! Дөрес, 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне. Балалар, исегезгә төшерегез әле, Ватанны кемнәр саклый? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Әйе безнең илебезне солдатлар, очучылар, диңгезчеләр саклый. Балалар, Ватаныбызны тагын әле башка хәрби һөнәр ияләре дә саклый. (Тәрбияче хәрби һөнәр ияләре рәсемен күрсәтә.) Бу рәсемнәрне карагыз, монда кемнәрне күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бер сүз белән генә аларны кем дип әйтәләр? *(Солдатлар.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, башкача аларны хәрбиләр диләр. Бергәләп кабатлыйк: хәрбиләр. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу рәсемдә хәрбиләр, солдатлар сурәтләнгәнен сез ничек белдегез? *(Киемнәренә карап.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә бу һөнәрләр кирәклеме соң? (*Әйе.*) Ни өчен? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар. Бу бик мөһим һөнәрләр. Хәзер без сезнең белән һәрберсе турында сөйләшербез. Балалар, бу

рәсемдә нинди хәрби сурәтләнгән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, балалар, диңгезче. Диңгезчеләр турында кем сөйли? Алмаз, әйдә син сөйлә.

Алмаз. Диңгезчеләр диңгездә, океанда корабльләр йөзәләр. Алар су өстендә һәм су астында су чикләрен саклыйлар. Диңгезчеләр көчле, кыю булалар.

Тәрбияче. Булдырдың, Алмаз! Балалар, бу рәсемдә нинди хәрби сурәтләнгән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, балалар, бу чик сакчысы. Бергәләп кабатлыйк: чик сакчысы. (Балаларны активлаштыру.) Чик сакчылары безнең илнең чикләрен саклыйлар. Алар көнгә берничә тапкыр үзләренә билгеләнгән территорияне карап чыгалар. Әгәр ил чиген бозучылар булса, көрәшәләр. Алар батыр, курку белмәс. Балалар, армиядә разведчиклар да бар. Менә аларның рәсеме. Бергә кабатлыйк: разведчик. Сезнең алар турында ишеткәнегез бармы? Кем сөйли? (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Әйе, аларның эшләре бик катлаулы һәм җаваплы. Информацияле пакетны дошманга эләкмичә урынына алып барып җиткерергә кирәк. Әле юлда күпме авырлыклар очрый. Алар бик кыю. Балалар, әйдәгез, сез дә разведчиклар булырсыз, уен уйнап алырбыз.

Тәрбияче малайларга пакет бирә. Балалар дугалар астыннан үрмәләп чыгалар, шакмакларга басып йөриләр, кеглилар арасыннан йөгерәләр һәм пакетны иптәшләренә бирәләр. Уен берничә тапкыр кабатлана.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, егетләр! Сез бик батырлар, кыюлар, без сезнең белән горурланабыз! (Балалар биргән пакетны ача.) Генерал Сафиннан пакет алып килделәр, ачып карыйк әле, нинди хәбәр бар икән! “Ватанны саклаучылар бәйрәме хөрмәтенә барлык малайларга медаль бирергә!” (Малайларга медаль бирелә.) Малайлар, солдатларга бүләк биргәч, алар кычкырып “Россиягә хезмәт итәм!” дип рәхмәт белдерәләр. (Балаларны активлаштыру.) Менә бу рәсемгә карагыз әле, кемне күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу танкист. Алар кайда хезмәт итәләр? *(Танкта.)* (Балаларны активлаштыру.)

Дөрес, танкистлар танкта хезмәт итәләр, илне саклыйлар. Балалар, бу нәрсә? *(Танк.)* (Балаларны активлаштыру.) Ул нинди өлешләрдән тора? Бу танкның нәрсәсе? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Бу танкның тәгәрмәчләре, аны башкача гусеница – тәгәрмәч чылбыры дип йөртәләр. Бергә кабатлыйк: гусеница – тәгәрмәч чылбыры. (Балаларны активлаштыру.) Бу танкның нәрсәсе? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Бу – танкның башнясы, башкача әйтсәк – манарасы. Бергә кабатлыйк: башня – манара. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, танкның кабинасына керү өчен, менә бу капкачын ачалар һәм керәләр. Балалар, ә монысы танкның пушкасы. Бергә кабатлыйк: пушка. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бүген без кемнәр турында, нинди бәйрәм турында сөйләштек? Диңгезне, су чикләрен, илебез чикләрен кемнәр саклый? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Сез бүген эшчәнлектә бик актив катнаштыгыз. Безнең дә төркемдәге малайлар, зур үскәч, илебезне саклармар. Балалар, ә хәзер барыбыз да бу рәсемгә карап, танк рәсеме ясыйбыз.

## Тема: ОЧУЧЫЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларны очкычның (самолётның) өлешләрен, зурлыгын, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүдә күнектерүне дәвам итү;

2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, танып белүләрен, кызыксынуын үстерү;

3) төрле гаскәр төрләренә, очучы һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләр тәрбияләү

**Җиһазлар:** төрле хәрби баш киемнәре, уенчык самолётлар.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, тиздән әтиләр, бабайлар бәйрәме җитә. Бу бәйрәмне безнең илдә Ватанны саклаучылар көне буларак бәйрәм итәләр. Безнең илне төрле төр гаскәре булган армия саклый. Армия үз илен диңгездә дә, коры җирдә дә, һавада да саклый ала. Балалар, һәр гаскәр төренең хәрби киеме бар. (Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә: диңгезчеләр, очучылар, чик сакчылары, десантниклар.) Карагыз әле, аларның хәрби киемнәре бер-берсеннән аерыла. Минем өстәлдә хәрбиләрнең баш киемнәре ята. Әйдәгез, аларның кемнеке икәнен билгелик. Бу нинди баш киеме, ничек атала? *(Шлем.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Шлемны кем кия? *(Танкист.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес әйттегез, танкистлар башларына шлем кияләр. Тотып карагыз, шлем нинди? *(Каты, калын, кара төстә.)* Шлем танкистларның башын бәрелүдән саклый. (Рәсем күрсәтә.) Ә бу баш киеме ничек атала? *(Бескозырка.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, бескозырканы кем кия? *(Матрос.)* Бескозырка нинди? *(Бу фуражканың козырёгы юк, аның кара тасмалары бар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Бескозырка бик матур! (Рәсем күрсәтә.) Күрегез әле, диңгезчегә бескозырка ничек килешә! Балалар, бу баш киеме ничек атала? *(Пилотка.)* Пилотканы кем кия? *(Солдат.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Пилотка нинди төстә? *(Яшел.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Пилотка солдатка бик килешә. (Рәсем күрсәтә.) Балалар, минем өстәлдә тагын бер фуражка бар. Бу фуражканың төсе нинди? *(Яшел.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Яшел фуражканы чик сакчылары кия (Рәсем күрсәтә.) Минем өстәлдә тагын бер фуражка бар. Аны кем кия? *(очучылар.)* (Рәсем күрсәтә.) Зәңгәр фуражканы кемгә бирәбез? *(Очучыга.)* Булдырдыгыз. Сез бик яхшы эшләдегез. Ял итеп алабыз.

Кояш елмая күктә *(балалар кулларын югары күтәрәләр),*

Кар җем-җем итә җирдә *(кулларны алга сузган хәлдә, кул чукларын дүрт тапкыр әле аска, әле өскә әйләндерү),*

Тауда чана, чаңгы шуу *(чана, чаңгы шуу хәрәкәтләре ясау)*

Аяк-кулны көчле итә *(кулларны як-якка сузып чүгәләргә, аяк башларын кочакларга.)* (2–3 тапкыр кабатлана.)

Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, сез тыңлагыз, аннан соң җавабын әйтерсез.

Канаты бар – җилпеми,
Эче җылы – җил тими.
Корыч йөрәкле кош ул,
Безнең яраткан дус ул.

Җавабын кем белде? *(Очкыч.)* Ни өчен очкыч дип уйлыйсыз? (Балаларның җаваплары.) Монда карагыз әле, бу нәрсә? *(Очкыч.)* (Балаларны активлаштыру.) Самолётны, вертолётны кем йөртә? *(Очучылар.)* Дөрес, балалар. (Активлаштыру) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, әйдәгез карыйк әле, очкыч нинди өлешләрдән тора? Балалар, менә бу очкычның кабинасы, анда очучы утыра. Очкычның бу өлешендә – салонда – пассажирлар утыра. Очкычның утыргычлары пассажирлар өчен уңайлы итеп ясалган. Очкычның тагын, кошларныкы кебек, канатлары бар. Ә монысы очкычның койрыгы. (Активлаштыру.) Очкычның “аяклары” да бар. Алар шасси дип атала. (Балаларны активлаштыру.) Һавага очып менгәндә, очкыч шассилары җыела. Җиргә төшкәндә, очучы шассиларны яңадан чыгара, очкыч шассилары белән җиргә төшә. Алар җиргә җиңел, бәрелмичә төшәргә ярдәм итә. Балалар, очкыч очканда нинди тавыш чыгара? *(“У-у-у” дип оча.)* (Очкычны “очыртып” күрсәтә.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, менә очкыч очып китте. Очкыч нәрсә эшләде? *(Очып китте.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, очкыч аска очамы, әллә өскәме? *(Өскә.)* (Балаларны активлаштыру.) Менә очкыч борылып китте. Ул кая борылды, сулгамы, әллә уңгамы? *(Уңга.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә хәзер кайсы якка борылды? (*Сулга.)* (Балаларны активлаштыру.) Очкыч кая таба оча? *(Аска.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә хәзер, балалар,

очкыч яңадан очып килде. Очкыч нәрсә эшләде? *(Очып килде.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, сез ничек уйлыйсыз, бөтен кеше дә очучы була аламы? (Балаларның җаваплары.) Очучы булу өчен нәрсә эшләргә кирәк? (Балаларның җаваплары.) Очучы булу өчен, укырга кирәк. Әйе, очучы бик кыю, тәвәккәл, батыр, сәламәт булырга тиеш. Балалар, сез зур үскәч, бәлки, очучылар булырсыз. Малайлар армиядә хезмәт итәрләр. Ватанны сакларлар. Балалар, әйдәгез, очкычлар булып уйнап алыйк. Сез барыгыз да очкычлар булырсыз. Кулларны як-якка канатлар кебек җәябез һәм очкыч тавышы чыгарып (у-у-у) "очып китәбез" һәм "очып киләбез". (Уен берничә тапкыр кабатлана.)

## Тема: ИҢ ЯХШЫ ӘТИ
## (Йомгаклау чарасы)

**Бурычлар:**

1) сәнгать әсәрләре аша балаларның сөйләм культурасын, татар халкының әдәби әсәрләрен белү теләге формалаштыру; сөйләм нормаларын үзләштерү;

2) татар җыр-биюләренә соклану, алар белән кызыксыну теләкләрен үстерү;

3) ана телендә аралашырга теләк уяту; үз гаиләң, әти-әниең белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** плакатлар, чакыру билетлары, фотокүргәзмә, рәсем күргәзмәсе, табигый материаллар, курчак, медальләр, бүләкләр, "Совет Армиясе маршы" (С. Сәйдәшев муз.), "Солдатлар" (К. Булатова сүзләре, М. Минһаҗев көе), "Көчегем" (Л. Лерон сүзләре, З. Гыйбадуллина көе), "Чишмә янында" биюе өчен көй аудиоязмалары.

### Кичә барышы

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Тамашачылар урынында балаларның әниләре утыра. Музыка астында балалар керә, залның ике ягына утыралар.

Тәрбияче. Хөрмәтле тамашачылар һәм балалар! Бүген бездә зур бәйрәм – әтиләр бәйрәме. Хәзер барыбыз да басыйк һәм кул чабып безнең яраткан кадерле әтиләребезне зал түренә чакырыйк. (Музыка астында әтиләр керә, үзләренә әзерләп куелган урыннарга утыра.)

1 нче бала. Ул җирдә иң шәп кеше,
Шәп кеше, гаҗәп кеше,
Ул иң-иң көчле кеше,
Юк бүтән аның эше.
Ул зирәк тә, шаян да,
Акыллы да, әйбәт тә.
Кем дисезме ул кеше? –
Минем әти, әлбәттә!

2 нче бала. Һәр вакытта иңнәремдә
Тоям әти кулларын.
Әти янәшә булганда,
Якты булыр юлларым.

3 нче бала. Үзе бик уңган булганга,
Ялкауны сөйми әти.
Эш сөючеләрне мактап
Гел безгә сөйли әти.

4 нче бала. Син, әтием, минем өчен
Бар дөньяда бер генә.
Елмайганда йөзләреңнән
Бар өйгә нур бөркелә.

Хөрмәтле әтиләр, без сезнең иң-иң уңган, иң-иң тырыш, иң-иң булган икәнлегегезне беләбез, шуңа бәйрәмебезне дә ярыш формасында уздырабыз. Әниләребез жюри әгъзалары булыр.

**1 нче ярыш**. “Мең дә бер кичә”. Әни кешенең кичкә таба бик каты итеп башы авырта башлады. Ә бала көн дә әкият

тыңлап йоклап китәргә гадәтләнгән. Кем үзенең якыннарына авыр чакта ярдәм итәргә тели? (Әтиләр әкият сөйли.)

Бала. Без сезне бик яратабыз,
Бәйрәм белән котлыйбыз
Бүләк итеп үзегезгә
Бер матур җыр җырлыйбыз.

“Солдатлар” җыры К. Булатова сүзләре, М. Минһаҗев көе.

**2 нче ярыш**. “Үзеңне таныйсыңмы?”. Ә хәзер үзегезгә читтән, балаларыгыз күзе белән карагыз. Үзегезне танырсызмы? (Тәрбияче балаларның үз этиләре турында сөйләгәннәрен укый. Үзен таныган эти баса.)

Бала. Әтием.
Әнием янында әтием булганда,
Без бергә булганда – күңелле бар дөнья.
Кирәксә, үтүкне төзәтеп бирә ул,
Әти бит ир кеше, бар эшне белә ул.
Әнигә күтәртми әтием сумканы,
Үскәч, мин күтәреп кайтырмын аларны.
Иң матур, иң көчле, иң әйбәт кеше дә –
Ул минем әтием. Иң якын, кадерле,
Иң кирәк кеше дә – ул минем әтием!

**3 нче ярыш.** “Әлли-бәлли, бәбкәем”. Өйдә яшь бала барында әнигә бик авырга туры килә: ашарга да пешер, өйне дә кара, бала да күп вакытны ала, җитмәсә, кайвакытта төннәр буе елап чыга. Сез барда әни кеше азрак ял итеп алсын. Кайсыгыз баласына бишек җырын җырлап күрсәтә? (Әтигә бала кебек төрелгән курчак бирелә.)

Бала. Әтиләрне мактаганга без дә каршы килмибез.
Карап торыгыз, әтиләр, сезнең өчен биибез!
“Парлы бию”.

**4 нче ярыш**. “Табын күрке – чәкчәк”. Ә хәзер әтиләргә яңа бирем – үзегез белгән татар халык ашлары исемнәрен

языгыз. Кем күбрәк яза ала? Ә яраткан ашларыгызның астына сызыгыз. Моны әниләребез күрми калмас, шул ризыкларны ешрак әзерләргә тырышыр, чөнки алар “Ир-ат йөрәгенә юл – ашказаны аша” дигән гыйбарәне беләләр дип уйлыйм.

Бала. Сез көчле дә, сез кыю да, сез уңган да, этиләр.

Тагын җыр бүләк итәрбез, сез тыңлагыз, этиләр.

“Көчегем” җыры. Л. Лерон сүзләре, З. Гыйбадуллина көе.

**5 нче ярыш.** “Оста куллар”. Балагыз әле бер уенчыгын ала, әле икенчесен, тик уйнап китә алмый. Аңа нинди дә булса яңа уенчык кирәк. Кайсы эти үз баласына ярдәм итәргә тели? (Табигый материаллардан уенчык ясарга.)

Шушының белән ярышларыбыз тәмам. Жюри әгъзалары киңәш-табыш иткән арада этиләребезгә тагын бер бию тәкъдим итәбез.

Бию. “Чишмә янында”.

Сүзне жюри әгъзаларына бирәбез.

Әни. Без барлык әниләр сөйләштек, киңәштек тә, барлык этиләр дә иң яхшы, иң уңган, иң булган, иң оста, иң акыллы, иң моңлы, иң бала җанлы дигән фикергә килдек. Шуңа күрә һәр этигә дә беренче урынны бирергә булдык.

Тәрбияче. Жюри фикере белән мин дә килешәм, чөнки бүлмәбезгә ремонт ясыйбызмы, түтәлләр казыйбызмы, ком ташыйбызмы, уенчыклар ремонтлыйбызмы – бөтен эштә дә тәрбиячеләргә этиләребез ярдәмгә килә. Моның өчен аларның барысына да зур рәхмәт. Ә хәзер аларга “Иң яхшы эти” медале һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

Этиләр тезелеп баса, әниләр аларга тасмага тагылган медальләрне кидерә, балалар үзләре ясаган бүләкләрне тапшыра.

Тәрбияче. Бәйрәмебезнең соңгы өлеше – гаилә белән кичке чәй эчү. Табынга рәхим итегез.

## *Сигезенче бүлек.*
# 8 МАРТ

### Тема: ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕ!

**Бурычлар:**

1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы мәгълүматларын киңәйтү; әниләр бурында тасвирлау хикәясе сөйләргә өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерләрен, фотография кулланып, эзлекле сөйләүләрен үстерү;

3) әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** әниләрнең фотографияләре, кәгазьгә берничә ваза ябыштырылган, чәчәкләр силуэтлары.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Кадерле балалар, мин сезгә бер әкият сөйлим. Борын-борын заманда яшәгән ди бер тылсымчы. Ул гаҗәеп оста кеше булган. Бу тылсымчы кадаксыз йорт төзи алган, теләсә, кыш көне урамда чәчәкләр үстергән, җәен Кыш бабайны чакыра алган. Арысланны – тычканга, чебенне филгә әйләндерә алган. Ләкин әниләрен тыңламаган, аларның кәефен бозган балаларга ул булыша алмаган. Бу очракта аның тылсымлы сүзләре ярдәм итмәгән. Тылсымчы әйтә торган булган: иң якын кешеләр генә кешене бәхетле итә. Тылсымчылар бу очракта көчсез. Балалар, сез ничек уйлыйсыз, әниләр өчен иң якын кеше кем ул? Әни арыган чакта кем аңа булыша ала, кәефен яхшырта, арганлыгын бетерә? (Балаларның җаваплары.) Дөрес әйтәсез. Балалар, сез, әниләр яшь, матур, бәхетле, ягымлы булсын дисәгез, үзегез могҗизалар эшли аласыз. Моның өчен әниләргә игътибарлы булырга, аларны тыңларга, күбрәк ягымлы, иркәләү сүзләрен әйтергә кирәк. Сез әниләрегезгә нинди ягымлы сүзләр әйтәсез? (Балаларның җаваплары.)

Сездә әниләрегезнең фотографияләре бар. Хәзер әниләрегез турында сөйләрсез. Минем дә әнием бар. Менә аның фотографиясе. Әнием турында сөйләгәнне тыңлагыз әле. Минем әниемнең исеме Әминә. Ул озын буйлы, сары чәчле, зәңгәр күзле. Әнием табиб булып эшли. Ул эшен бик ярата. Өйдә тәмле ашлар, бәлешләр пешерә. Мин аны яратам. Балалар, мин башта нәрсә турында сөйләдем, ә аннан соң? Мин хикәяне ничек тәмамладым? (Балалар әниләре турында сөйлиләр, тәрбияче аларның сөйләмен бәяли.) Хәзер ял итеп алырбыз

Әнигә булышам – керләрне юышам *(кер юу хәрәкәте ясыйлар),*

Югачтын, әйбәтләп чайкатып аламын *(кер чайкау хәрәкәте ясыйлар),*

Чайкагач, көч белән ныгытып сыгамын *(керне сыгу хәрәкәте ясыйлар)*

Һәм бауга эләмен *(керне элеп кую хәрәкәте ясыйлар),*

Кипкәчтен, шәп итеп үтүкләп куямын *(уң кулга үтүк "тотып" үтүкләү хәрәкәте ясыйлар.)*

Булдырдыгыз! Менә кер дә юып карадыгыз. Бик тырыштыгыз.

Балалар, тиздән нинди бәйрәм якынлаша? *(Әниләр бәйрәме.)* (Балаларны активлаштыру.) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, балалар, әниләр бәйрәме якынлаша. Әниләр бәйрәме – иң ягымлы, иң гүзәл, иң матур бәйрәм, чөнки әниләр безнең иң кадерле кешеләребез. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Безнең әниләребез – ягымлы, гүзәл, иң матур затлар. Шуңа күрә әниләр бәйрәме – иң ягымлы, иң гүзәл, иң матур бәйрәм. Балалар, әниләр бәйрәмен елның кайсы вакытында билгеләп үтәләр? *(Яз көне.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Дөрес, балалар, әниләр бәйрәмен яз көне бәйрәм итәләр. Яз билгеләрен әйтегез әле. *(Кар эри, боз сөңгеләре барлыкка килә, көннәр җылына.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, 8 Март әниләр бәйрәме генә булып торамы? Тагын кемнәр бәйрәме соң 8 Март? (*Әбиләр, апалар, кызлар бәйрәме.*) (Индивидуаль һәм күмәк

кабатлаулар.) Дөрес, балалар, 8 Март – әниләр, әбиләр, апалар, кызлар бәйрәме. Икенче төрле аны Хатын-кызлар бәйрәме диләр. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: “Хатын-кызлар бәйрәме”. Булдырдыгыз! Балалар, әниләрегез бик тырышып эшлиләр. Эштән кайткач та, әниләрнең өйдә эше күп. Алар нәрсәләр эшлиләр? *(Ашарга әзерлиләр. Кер юалар. Савыт-саба юалар.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Балалар, сез әниләрегезгә булышасызмы? Нәрсәләр эшлисез? (Балаларның җаваплары.) Бик яхшы, балалар! Әйе, сез инде чәй өстәле әзерли беләсез, шуңа күрә өстәл әзерләгәндә кирәкле савыт-сабаны өстәлгә куярга, ашагач җыеп куярга ярдәм итә аласыз. Әниләргә, әбиләргә булышырга кирәк. Бәйрәмдә бүләкләр бирәләр. Әниләр өчен без гадәти булмаган букет ясарбыз. Менә бу ваза сурәте. Вазага чәчәкләрябыштырырбыз. Эшләп бетергәч, вазаны әниләр почмагына элләрбез.

Балалар өстәл артына утыралар, контур буенча чәчәкне кисеп алалар, вазага ябыштыралар.

## Тема: “ЭТ КӨЧЕКЛӘРЕ БЕЛӘН” ДИГӘН КАРТИНА БУЕНЧА ХИКӘЯ ТӨЗҮ

**Бурычлар:**

1) сюжетлы картинаның персонажларын игътибар белән карау, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, тәрбияче белән бергә сөйләү осталыгын формалаштыру; эчтәлекне сөйләгәндә иҗадилык элементларын куллануга ярдәм итү; сөйләмне сыйфатлар куллану хисабына баету;

2) балаларның игътибарын, күрү хәтерен, тыңлау осталыгын, танып белүләрен, кызыксынуларын үстерү;

3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Эт көчекләре белән” дигән сюжетлы картина, Л. Лерон сүзләре, З. Гыйбадуллина көенә язылган “Көчегем” дигән җырның аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, тыңлагыз, мин сезгә бер табышмак әйтәм, сез җавабын әйтерсез. “Кешенең дусты, йортның сакчысы”.

Кем җавабын әйтә? *(Эт.)* (Балаларны активлаштыру.) Бүген “Эт көчекләре белән” дигән картинаны карарбыз, аннан соң аның буенча хикәя төзербез. (Тәрбияче картинаны балаларга күрсәтә.) Картинада нәрсә сурәтләнгән? *(Эт.)* (Балаларны активлаштыру.) Эт нинди? *(Зур, кара, йонлач, мәрхәмәтле.)* (Балаларны активлаштыру.) Эт нәрсә эшли? *(Ята, ял итә, күзәтә, йортны саклый, сакта тора.)* (Балаларны активлаштыру.) Беренче көчек нәрсә эшли? (Тәрбияче эт белән бергә яткан көчеккә күрсәтә.) *(Әнисе белән янәшә ята.)* (Балаларны активлаштыру.) Икенче көчек нәрсә эшли? (Тәрбияче чыпчыкларга карап торучы көчеккә күрсәтә.) *(Чыпчыкларны күзәтә.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, карагыз әле, савытка (мискига) азыкны кем куйган икән? *(Хуҗа яисә хуҗаның малае, кызы.)* (Балаларны активлаштыру.) Ничек уйлыйсыз, савытта нинди азык икән? *(Сөт, ит, сөяк.)* (Балаларны активлаштыру.) Картинада тагын нәрсәләр сурәтләнгән? *(Чыпчыклар.)* (Балаларны активлаштыру.) Чыпчыклар нәрсә эшли? *(Савыттагы азыкны чүплиләр.)* Чыпчыклар нигә очып китмиләр? (Балаларның җаваплары.) Дөрес, алар эт белән көчекләрдән курыкмыйлар, чөнки алар бик мәрхәмәтле. (Балаларны активлаштыру.) Картинада тагын нәрсә сурәтләнгән? *(Эт оясы.)* (Балаларны активлаштыру.) Яңгыр яуганда, җил искәндә, карлар яуганда эт үзенең оясына керә, анда ял итә, суыктан, җилдән саклана. Эт оясын кем төзеде икән? *(Йорт хуҗасы.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, йорт хуҗасы эт, аның көчекләре турында кайгырта. Ул эткә оя ясаган, аны ашата, эчертә. Эт тә хуҗага булыша. Ул аның йортын караклардан саклый. Балалар, ана эт үзенең көчекләре турында ничек кайгырта? (Балаларның җаваплары.) Ана эт көчекләрен бик ярата. Ул аларны кирәк

булса яклый да, саклый да. Аның күзләре бик ягымлы. Ул балаларына яратып карап ята.

Хәзер уйнап алырбыз. Уен “Кем бик игътибарлы?” дип атала? Мин картинаны алып куям, сезгә сораулар бирәм. Картинада ничә көчек сурәтләнгән? Ничә савыт бар? Эт нинди төстә? Нинди кошлар азык белән тукла752налар? Эт кайда ята: җирдәме, җәймәдәме? Балаларның җаваплары картина элементларын чагыштырып карау юлы белән тикшерелә.

Без картинаны игътибар белән карадык. Сорауларга җавап бирдек. Хәзер картина буенча хикәя төзергә өйрәнербез. Өйгә кайткач, эт һәм аның көчекләре турында әниегезгә-әтиегезгә сөйләрсез. Аларга сезне тыңлау күңелле булыр.

Картинада эт ... (*көчекләре белән*) сурәтләнгән. Ана эт зур, тагын нинди? *(кара, йонлач.)* Аның ике ... *(көчеге)* бар. Берсенең исеме ... *(Акбай),* икенчесенеке ... *(Актырнак.)* Көчекләр ... *(кечкенә.)* Алар турында тагын нәрсә әйтеп була? *(Алар шаян, йомшак.)* Эт белән көчекләр төшке ашны ашаганнар. Йорт хуҗасы савытка ... *(аш белән ит)* салган. Эт ... *(көчекләре белән)* итне һәм ашны ... *(ашап бетергәннәр.)* Аш бик ... *(тәмле.)* Ашап алгач, ана эт... *(ял итәргә)* булган. Акбай әнисе янына ... *(ятты.)* Актырнак бик шаян, ул ... *(чыпчыкларны)* күзәтә. Эт көчекләре белән безгә бик ... *(ошады.)*

Хәзер “Көчегем” дигән җырны тыңлыйк һәм кушылып җырлыйк. (Тәрбияче “Көчегем” дигән җырның аудиоязмасын куя.)

## *Тугызынчы бүлек.*
## ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

### Тема: БИЯЛӘЙ ҺӘМ ПЕРЧАТКА

**Бурычлар:**

1) татар халкының кул эшләре белән таныштыру; тәрбияченең сөйләмен аңларга, сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;

2) сенсор культураны, сүзлек байлыгын, сөйләмнең грамматик төзелешен үстерү;

3) халкыбызның кул эшләре белән кызыксыну, чисталык, пөхтәлек, тырышлык, киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәрҗингә салынган йон җебеннән ясалган йомгаклар, төрле төстәге һәм бизәкле берничә пар бияләй, перчаткалар, төсле кәгазьдән киселгән бияләй формасы, түгәрәкләр һәм кәгазь тасмалар (аппликация өчен.)

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, кулга-кул тотынышып басыгыз! Әйдәгез, башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып: “Хәерле иртә!” – дип әйтәбез. (Тәрбияче башына яулык бәйли, ә кулына кәрҗин тота.) Мин – әби. Карагыз әле, минем кәрҗинемдә нәрсәләр бар икән? (Балаларга йон җебеннән ясалган йомгаклар тарата.) Нәрсә бу, балалар? *(Йомгаклар.)* Әйе, йон җебеннән ясалган йомгаклар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) (Балалар йомгакларны карыйлар.) Алсу, синең йомгагың нинди төстә? Гүзәл, синеке нинди төстә? (Балаларның җаваплары.) (Балаларны активлаштыру.) Йомгакны өстәлдә тәгәрәтеп карыйм әле. Сез дә тәгәрәтеп карагыз! (Балалар тәгәрәтәләр.) Йомгаклар тәгәриме? *(Тәгәри.)* Ни өчен тәгәри? *(Аның почмаклары юк.)* Әйе, балалар, почмаклары булмагач, йомгак тәгәри. Балалар, йомгаклар нинди формада? *(Шар формасында.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Йомгаклар нинди төстә? *(Сары, зәңгәр, кызыл.)* Аларның сары, зәңгәр, кызыл төстә булуын бер сүз белән ничек әйтергә була? *(Төрле төстәге, төрле төсле.)* (Балаларны активлаштыру.) Йомгаклар нәрсәгә охшаганнар? *(Сары йомгак кояшка, зәңгәр йомгак тупка, кызыл йомгак кызарган алмага охшаган.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, йомгаклар җептән ясалган. (Сүтеп күрсәтә, аннары кире урый.) Менә шулай җепне урый-урый йомгак килеп чыга. Сез дә шулай эшләп карагыз. Җепне азрак сүтегез һәм кире урагыз. Менә шулай! Булдырасыз! Балалар йомгак йон

җебеннән ясалган. Бу нинди җеп? (Йомгактагы җепне күрсәтә.) *(Йон җеп.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Йон җепне тотып карагыз. Ул нинди? *(Йомшак, калын, җылы.)* Йон җеп нәрсә өчен кирәк дип уйлыйсыз? *(Бәйләр өчен.)* Бик дөрес! Йон җебеннән нәрсә бәйләргә була? (Балаларның җаваплары.) Сезнең әбиләрегезнең, әниләрегезнең бәйләгәнен күргәнегез бармы? (Балаларның җаваплары.) Алар нәрсә белән бәйлиләр? *(Энә белән, крючок (кечкенә ыргак) белән.)* Хәзер мин дә сезгә бәйләп күрсәтәм. (Тәрбияче берничә рәт бәйли.) Бәйләгәч, менә шундый бияләйләр килеп чыкты. (Кәрҗиннән берничә пар бәйләнгән бияләй алып, өстәлгә куя.) Балалар, безгә бияләйләр ни өчен кирәк? (Балаларның җаваплары.) Минем кәрҗинемдәге бияләйләр буталып беткәннәр. (Күрсәтә.) Бертөрле төсле һәм бертөрле бизәкле бияләйләрне табып, парлап тезеп куегыз әле. (Балалар бияләйләрнең парларын табалар.) Бияләйләрне битегезгә куеп карагыз әле. Алар нинди? *(Йомшак.)* (Балаларны активлаштыру.) Хәзер кулыгызга киегез. Нинди? *(Җылы.)* (Балаларны активлаштыру.) Мин сезгә табышмак әйтәм, сез җавабын табыгыз:

Бер агачта биш тармак,
Тармагы саен бармак. *(Перчатка.)*

(Балаларның җаваплары.) Дөрес, балалар, перчатка. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: перчатка. Бу сүз рус телендә дә, татар телендә дә шулай әйтелә. Куллар туңмасын өчен, бияләйдән тыш тагын нәрсә кияләр? *(Перчатка.)* (Кәрҗиннән перчаткалар алып, балаларга күрсәтә.) Балалар, перчаткалар формасы буенча бияләйләргә охшаганмы? *(Юк.)* Дөрес, перчаткалар формасы буенча бияләйләргә охшамаганнар. Перчаткада һәр бармак өчен аерым “бүлмә” бар. Балалар, бияләй дә , перчатка да куллар туңмасын өчен безгә бик кирәк. Аларны кигәч, бармакларга җылы. Безнең курчакларның бияләйләре юк. Әйдәгез, аларга матур бияләйләр ясап бирик. (Тәрбияче кәгазьдән киселгән бияләй формасы тарата. Балалар аппликация ясыйлар.) Балалар курчаклар бик шатланырлар,

сезгә рәхмәт әйтерләр. Чиста, пөхтә итеп эшләргә тырышыгыз! Булдырдыгыз!

Балалар, менә курчакларга да бияләйләр булды. Сезнең дә һәрберегезнең бияләе бар. Бияләйләрне сезнең өчен әниләр, әбиләр бәйли. Аларны саклап кияргә, юешләнсә, киптерергә кирәк. Кешеләр электән үзләрен шулай салкыннан сакларга өйрәнгәннәр, җылы бияләйләр, оекбашлар, шарфлар, кофталар бәйләгәннәр. Безнең халкыбыз һәрвакыт тырыш булган. Сез дә бүген бик тырыштыгыз. Әйдәгез, үзебезне мактап кул чабыйк!

## *Унынчы бүлек.*
## ЯЗ

### Тема: АЮНЫҢ ЯЗГЫ МАҖАРАЛАРЫ

**Бурычлар:**

1) балаларны, исем, сыйфат кулланып, гади җөмләләр төзергә өйрәтү, язның төп билгеләре турындагы белемне ныгыту; бирелгән сүзләргә антонимнар сайлауны формалаштыру, балаларның сүзлек запасын киңәйтү;

2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;

3) балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** А3 форматында ике сюжетлы картина: а) табигатьтә яз, кар эри, аю кышкы йокыдан уянмаган, аюның оясына кар сулары тулган да, аның туны чыланган; б) аю йокысыннан уянган да, оясыннан чыгып киерелгән һәм өскә караган, күк йөзе чиста, зәңгәрсу), куянның, бүренең, тиеннең, песинең контурлы рәсемнәре, 5әр данә тиеннең, куянның, бүренең, май коңгызының, күбәләкнең, кырмысканың, 1 данә яңгыр болытының контурлы рәсемнәре, күңелле музыка аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче (Р. Вәлиеваның шигырен укый).

Яз килде, кояш көлде,
Дөньяга нур бөркелде.
Уянды бар агачлар,
Куанды алмагачлар.

Балалар, шигырьдә елның кайсы вакыты турында сүз бара? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә сез язның нинди айларын беләсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, мин сезгә бер рәсем күрсәтәм. (Тәрбияче кышкы йокыдан уянган аю рәсемен күрсәтә) Әле аю кышкы йокыдан уянмаган иде. Менә аюның оясына кар сулары тулган да, аның туны чыланган. Аю йокысыннан уянган да, оясыннан чыгып киерелгән һәм өскә караган. Өскә карагач, нәрсә күргән? *(Һава, күк йөзе.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә күк йөзе нинди? *(Язгы, чиста, зәңгәрсу, биек.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Әйе, яз көне күк йөзе нәкъ шундый була. Анда ак болытлар йөзә. Менә аю һавага карый да, уйга бата: “Эх, минем канатларым булса иде, зәңгәрсу һавада йөзәр идем. Очар идем дә, кояш, зәңгәр болытлар турында җырлар идем”, – ди. Кинәт кенә аюга бөтен нәрсә зәңгәрсу булып күренә: кошлар да, агачлар да, үләннәр дә, хәтта кояш та. Аю йоклап киткән икән бит. Ул тәмле төш күрә.

Аю зәңгәр төш күрә:
Зәңгәр үлән,
Зәңгәр урман,
Хәтта сары кояш та
Зәңгәр булып күренә.

Әйдәгез, аю белән бергә без дә күзләрне йомыйк та үләннәрне, болытларны күз алдына китерик. Матурмы? Ә хәзер күзләрегезне ачыгыз. Балалар, сез беләсезме, һәр болытның кешеләрнеке кебек кәефе йә күтәренке, йә төшенке була. Алар бер-берсенә охшамаганнар. Әгәр болытларның кәефе күтәренке булса, алар нинди була? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әгәр болытларның кәефе төшенке булса, ул нинди була? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Болытлар арасында аю зур кояшны күреп ала. Балалар, кояш нинди? *(Якты, нурлы, җылы, ягымлы, язгы.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Аю як-ягына караган да агачлар, үләннәр, чәчәкләр, төрле җәнлекләр күргән. Әйдәгез, без дә карыйк әле, аю нинди җәнлекләр күргән икән? (Тәрбияче куянның, бүренең, тиеннең, песинең контурлы рәсемнәрен күрсәтә.) Балалар, монда ничә җәнлек бар? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, күп, бергәләп санайк әле: бер, ике, өч, дүрт. Ничә җәнлек булды? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, кайсы җәнлек артык? *(Песи.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, ни өчен? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, песи йорт хайваны, ә башкалар кыргый хайваннар. Балалар, тагын кайсы җәнлекне артык дип әйтеп була? *(Тиен.)* Ни өчен? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, тиен агачта яши, йөри, ә башка җәнлекләр җирдә йөри. Булдырдыгыз! Балалар, менә аю нинди урман күргән. (Тәрбияче язгы урман сурәтләнгән рәсем күрсәтә.) Ләкин бу урманда берәү дә юк. Балалар, әйдәгез, һәр җәнлеккә, бөҗәкләргә үз урыннарын табарга ярдәм итик.

Күңелле көй яңгырый. Тәрбияче балаларга тиеннең, куянның, бүренең, май коңгызының, күбәләкнең, кырмысканың контурлы сурәтләрен тарата. Балалар бу сурәтләрне урман рәсеменә ябыштыралар. Яңгыр болыты сурәтен тәрбияче ябыштыра.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар! Менә безнең урманыбыз матурланды. Балалар, монда бер яңгыр болыты килеп чыкты, һәм яңгыр ява башлады. Әйдәгез, без дә уйнап алабыз. Мин “әни” болыт булырмын, ә сез минем балаларым – тамчылар булырсыз. (Күңелле музыка яңгырый.) Тамчылар җиргә очып төшәләр. Сикерәбез, уйныйбыз. Аларга берәрләп сикерү күңелсез булган, дүртәр булып берләшеп, гөрләвек ясаганнар. Бу гөрләвекләр барысы да очрашкан да, бер зур елгага әверелгәннәр. (Балалар кулга-кул тотынышалар, бер-бер артлы йөриләр.) Бу елга аккан, аккан да бер океанга кушылган. (Балалар кулга-кул тотынышып зур түгәрәк ясыйлар.) Бу тамчылар океанда йөзеп озак кына йөргәч, әниләре-болытның сүзе исләренә төшкән. Ул бит аларга кайтырга кушкан иде. Шул вакыт кояш кыздыра башлый. (Балалар чүгәлиләр.) Тамчылар җиңеләеп калганнар һәм өскә күтәрелә башлаганнар. (Балалар, кулларын күтәреп, өскә тартылалар.) Кояш җылысында алар парга әйләнгәннәр һәм әниләре-болыт янына кайтканнар. Булдырдыгыз, балалар! Шул вакыт аюга бик күңелсез булып киткән һәм ул дуслары – башка аюлар янына барырга уйлаган. Баргач, иптәшләренә бер бик кызык уен өйрәткән. Әйдәгез бу уенны без дә уйныйбыз. Уен “Барысы да киресенчә” дип атала. Мин сезгә сүзләр әйтәм, ә сез аның киресен әйтерсез. Зур – (*кечкенә, бәләкәй.*) Әче – *(баллы.)* Кайнар – *(салкын.)* Йомшак – *(каты.)* Киң – *(тар.)* Булдырдыгыз балалар! Сезгә бүген эшчәнлек ошадымы? Сез бүген нәрсәләр белдегез? Сез бердәм булганга, бер-берегезгә ярдәм иткәнгә, сезгә барысы да җиңел генә бирелде.

## Тема: УРМАН КҮЛЕНДӘ

**Бурычлар:**

1) балаларның [с], [з], [у], [ш] авазларын дөрес әйтүләрен ныгыту, [ж] авазының артикуляциясен исләренә төшерү; бу авазны сүзләрдә, фразаларда әйтүдә күнектерү; язның төп

билгеләре, айлары, табигать күренешләре турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның сүзлек запасын киңәйтү;

2) балаларның кызыксынуын, ишетү игътибарын, хәтерен, логик фикерләвен, вак моторикасын үстерү;

3) балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф, җылы яктан кайта торган кошлар тавышы һәм гөрләвек аккан тавышлар белән аудиоязмалар, елмайган кояшның, черкинең, ябалакның, баканың, еланның, май коңгызының контурлы сурәтләре, А3 форматында урман күле сурәтләнгән картина.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, күзләрне ял иттереп алыйк әле.

Кояш иртән торган да
Болытларны санаган.
Башта өскә караган,
Аннан аска караган,
Уңга, сулга караган
Һәм күзләрен ул йомган.

Балалар, текстка туры китереп, күзләр белән хәрәкәтләр ясыйлар.
Балаларның күзләре йомык вакытта тәрбияче фланелеграфка
елмайган кояш сурәте куя.

Тәрбияче. Балалар, карагыз әле, безнең бүлмәдә нинди матур кояш чыккан. Кояш елмая, һава торышы матур, җылы. Ни өчен икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, чөнки урамда яз. Балалар, хәзер язның башымы, әллә ахырымы? *(Яз ахыры.)* Сез моны каян белдегез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, сезнең урман күлен күрәсегез киләме? *(Әйе.)* Күзләрегезне йомыгыз һәм тыңлагыз. (Кошлар сайраган тавыш ишетелә.) Менә без урман күленә

килеп чыктык. (Урман күле сурәтләнгән картина күрсәтелә яки бу сурәт экранда күрсәтелә.) Балалар, яз килү белән, урман төрле авазлар белән тула. Сез нәрсә ишетәсез? *(Кошлар сайрый.)* Ә менә мин урман күленә гөрләвекләр ашыкканын һәм кар эрегән суның күлгә акканын ишетәм. Балалар, су акканда нинди тавыш чыга? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, с-с-с дигән авазлар ишетелә. Бергәләп кабатлыйк: с-с-с. (Балаларны активлаштыру.) Су өстендә черкиләр безелдәп очып йөриләр. (Черкинең контурлы рәсеме куела.) Черкиләр ничек җырлыйлар? *(Без-з-з.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә мин бака чурлаган тавышны да ишетәм. (Баканың контурлы рәсеме куела.) Балалар, бакалар ничек чурлый? *(Чурр-чурр, бака-ка-ка.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, хәзер бармаклар белән бакаларның черки тотканын күрсәтербез. Учларыбызны җәеп, Бакалар булып уйныйк. (Кулларның учы алга карый, баш бармак аерылып алга сузыла, башка бармаклар бергә кушылып, аз гына бөгелеп баш бармак белән тоташа.) Балалар, ә монда бер ябалак та утыра. (Ябалакның контурлы рәсеме куела.) Ул ничек кычкыра? *(У-у-у.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу куаклар арасында нәрсәдер бар, бу бауга да охшаган, ләкин ул ышылдый. (Рәсемгә елан контурлы рәсемен куя.) Бу нәрсә икән? (*Елан.*) (Балаларны активлаштыру.) Ул ш-ш-ш дип ышылдый. Балалар, әйдәгез бергәләп тыныч кына ышылдыйк: ш-ш-ш. (Балаларны активлаштыру.) Ә хәзер кычкырып ышылдыйк: ш-ш-ш. (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, мин әле тагын күл өстендә “ж-ж-ж” дигән тавыш ишетәм. Бу нинди бөҗәкнең җыры? *(Май коңгызы.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, май коңгызлары да уянган. (Май коңгызының контурлы рәсеме куела.) Балалар, безгә май коңгызы кебек матур итеп җырлар өчен, тел уртасын аңкауга терәп, тел очын аскы тешләр артына яшерергә һәм тешләрне ябып, иреннәрне түгәрәкләп ясап аваз чыгарырга кирәк. Май коңгызы ничек ыжылдый. *(Ж-ж-ж.)* (Балаларны активлаштыру.) Башта кызлар әйтеп карасын. *(Ж-ж-ж.)* (Кызларны активлаштыру.)

Хәзер малайлар әйтеп карасын. *(Ж-ж-ж.)* (Малайларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Без хәзер сезнең белән май коңгызлары булырбыз. Көндез коңгызлар очалар, ыжылдыйлар, Төн җитсә, аркаларына яталар һәм әкрен генә кулларын, аякларын селкетәләр. (Сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.) Булдырдыгыз! Балалар, мин сезгә май коңгызы турында бер вакыйга сөйлим.

Безнең күл буенда бик күп матур чәчәкләр үсә. Бервакыт бер май коңгызы үз җырын җырлап очып йөргән. Ничек җырлый икән? *(Ж-ж-ж.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, "Ж-ж-ж, минем су эчәсем килә", – ди. Ул бер матур зәңгәр кыңгырау чәчәге күргән дә бик сөенгән: "Менә мин монда су эчәрмен" – ди икән. Кыңгырау чәчәге эченә керә дә: "Ж-ж-ж, монда матур икән", – ди. Май коңгызы нәрсә дигән? *(Ж-ж-ж, монда матур икән.)* (Балаларны активлаштыру.) Үзенең мыеклары белән кыңгырау чәчәгенең төбен татып карый да: "Ж-ж-ж, бу бит тәмле сок", – дип сөенә. Балалар, май коңгызы ничек сөенә? *(Ж-ж-ж, бу бит тәмле сок.)* (Балаларны активлаштыру.) Бу тәмле сокны эчкән дә, май коңгызы җырлаган: "Ж-ж-ж, ж-ж-ж, ж-ж-ж, яшәүләре бик рәхәт". Сез дә шулай итеп җырлап карагыз әле. *(Ж-ж-ж, ж-ж-ж, ж-ж-ж, яшәүләре бик рәхәт.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Май коңгызы шулай җырлаган, җырлаган да йокыга киткән. Шул вакыт бер кечкенә кыз болын буйлап, чәчәк җыеп йөри икән. Кәрҗиненә төрле чәчәкләр җыйган да өенә кайткан. Бервакыт ыжылдаган тавыш ишетелгән: "Ж-ж-ж, мин кая эләктем, ж-ж-ж"? Кыз куркып калган. Май коңгызы ничек ыжылдаган (*Ж-ж-ж, мин кая эләктем, ж-ж-ж?)* (Балаларны активлаштыру.) Менә, балалар, без урман күлендә йөрдек, хәзер бакчага кайтыр вакыт җитте. Күзләрегезне йомыгыз, безнең өчен кошлар җырлый. (Кошлар җырлаган тавыш ишетелә.) Менә бакчага "кайтып та җиттек". Балалар, сез урман күле янында нинди тавышлар ишеттегез? Нәрсәләр күрдегез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар!

## *Унберенче бүлек.*
# ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

## Тема: ТРАНСПОРТ

**Бурычлар:**

1) балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү; төренә карап, аларны классификацияләргә, бер транспорт төре турында тасвирлау хикәясе төзергә өйрәтү; Җиңү көне уңаеннан транспорт турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү;

2) балаларның диалоглы сөйләмен, конкрет-образлы фикерләвен, классификацияләү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын, сүзлек запасын үстерү;

3) ветераннарга карата хөрмәт, горурлык хисләре һәм коллективта эшләү теләге уяту; уңай атмосфера тудыру.

**Җиһазлар:** мольберт, сугыш чорында кулланылган транспорт үрнәкләре (машина, самолёт), төрле транспорт төрләре (һава, җир өсте, су транспортлары), транспорт өлешләре (мәс. шасси, пропеллер, самолёт койрыгы, салоны, канатлары һ. б.), сөйләү өчен схема.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез исәнләшәбез. Иртә белән кешеләргә сәлам бирү гадәте бар. Сары кояшка сәлам! Чиста һавага сәлам! Олылар һәм кечеләр, сезгә чын йөрәктән сәлам! Һәр яңа көнне яхшы кәеф белән башларга кирәк. Кәефебез күңелле һәм яхшы булсын өчен, куллар тотышыйк, күзләрне йомыйк, йөрәгебездә булган җылылык һәм мәхәббәт чаткыларын бер – беребезгә бирик. Күзләребезне ачыйк, елмаеп бер-беребезгә хәерле иртә һәм яхшы кәеф телик.

| | |
|---|---|
| Очрашканда кешеләр –<br>Олылар һәм кечеләр –<br>Бер-берсен сәламлиләр:<br>“Исәннәрмесез”, – диләр. | Очрашсалар бик иртә,<br>Бик матур теләк әйтә.<br>Нинди теләк? Кем әйтә?<br>Ул сүз ... *(Хәерле иртә)!* |
| Күрешсәләр көндезен<br>Кышын, җәен, яз, көзен.<br>Нинди теләк әйткәнен<br>Кем белә?.. *(Хәерле көн)!* | Күрешсәләр алар кич,<br>Сәлам бирми үтми һич.<br>Сәламләшү сүзләре<br>Булачак... *(Хәерле кич)!* |

Җиңү көне турында сөйләшүебезне дәвам итәбез. Сугыш тәмамлангач, халкыбыз тыныч тормышта яши башлаган. Без хәзер җылы йортларда яшибез, матур бакчаларга йөрибез, теләгән уенчыкларыбыз белән уйный алабыз. Балалар, сугыш барган вакытта да кешеләргә төрле төр машиналар ярдәмгә килгән. Карагыз әле монда. (Тәрбияче машиналар күрсәтә.) Нәрсә күрәсез? *(Җиңел машиналар, йөк машиналары, автобуслар, трамвай, очкычлар.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, аларның барысын бер сүз белән ничек әйтергә була? *(Транспорт.)* (Балаларны активлаштыру.) Сугыш барган вакытта күбрәк йөк машиналарын кулланганнар. Ничек уйлыйсыз, йөк машиналары нинди эш башкардылар икән? *(Солдатларны фронтка илткәннәр, азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары: снарядлар, патроннар ташыганнар.)* Хәзерге вакытта да транспорт киң кулланыла. Балалар, карагыз әле, сугыш чорында кулланылган һәм хәзерге көндә кулланыла торган транспорт ничек аерыла? (Балаларның җаваплары.) Әйе, хәзерге транспорт заманча ясалган, матур.

Безнең шәһәрдә нинди транспорт бар? *(Автобуслар, трамвайлар, йөк машиналары, җиңел машиналар.)* (Тәрбияче балалар атаган транспортны рәсемдә күрсәтә.) (Балаларны активлаштыру.) Башка шәһәргә нинди транспорт белән барырга була? *(Поезд, автобус, җиңел машина, очкыч.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, нинди транспорт рельслар буенча йөри? *(Поезд, трамвай, троллейбус.)* Балалар, бу транспорт төрләре электр тогы белән эшли. Алар йөрсен өчен электр тогы кирәк. Йөк һәм җиңел машиналар,

автобуслар, трамвайлар – болар барысы да коры җир транспорты дип атала. Алар коры җирдә йөриләр. (Тәрбияче бу транспорт төрләренең рәсемнәрен күрсәтә.) (Балаларны активлаштыру.) Суда нинди транспорт йөри? *(Корабль, пароход, көймә.)* (Балаларны активлаштыру.) Без әйткән көймә, пароход, корабль су транспорты дип атала. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, һавада нинди транспорт төрләре бар? *(Самолет, вертолёт.)* (Балаларны активлаштыру.) Самолет, вертолёт һава транспортына керә. (Балаларны активлаштыру.)

Балалар, хәзер уйнап алабыз. Сезнең алда тартмалар ята. Анда төрле транспорт төрләре бар. Сез аларны игътибар белән карагыз, һәр транспорт төрен: су транспортын, һава транспортын, коры җир транспортын аерып күрсәтегез. (Балалар биремне үтиләр.) Булдырдыгыз. Хәзер икенче уен уйнап алабыз. Уен "Дәвам ит" дип атала. Мин сезгә картиналар күрсәтәм, картиналарда транспорт сурәтләнгән. Сез аның нинди төргә кергәнен әйтерсез. (Тәрбияче мольбертка рәсемнәр элә.) Көймә, пароход, теплоход – болар ... *(су транспорты.)* Самолет, вертолёт – болар *(һава транспорты.)* Автобус, машина, трамвай – болар *(җир транспорты.)* Булдырдыгыз. Тагын бер уен үткәрербез. Мин сезгә транспортның өлешләрен күрсәтәм, сез транспортны атагыз. (Тәрбияче мольбертка транспорт өлешләрен куя.) Койрык, канатлар, шасси, пропеллер – бу нәрсәнең өлешләре? *(Очкыч.)* (Балаларны активлаштыру.) (Машина, автобус, пароход белән дә эш шулай оештырыла.)

Аз хәрәкәтле уен "Очкычлар".

Балалар, нәрсә тизрәк: очкычмы, пароходмы? Нәрсә әкренрәк: көймәме, вертолётмы? Нәрсә авыррак: пароходмы, көймәме? (Балаларның җаваплары.)

Хәзер сез машиналар турында сөйләрсез. Машина турында сөйләргә схема (схеманы мольбертка куя) ярдәм итәр:

1. Бу нәрсә? Нәрсәне белдерә?
2. Бу транспорт нинди төстә, аның нинди детальләре бар?
3. Транспортның зурлыгы: зурмы, әллә кечкенәме?
4. Уенчык белән ничек уйнарга була?

Иң элек мин сөйлим, тыңлагыз. Бу йөк машинасы. Аның кабинасы кызыл төстә, кузовы яшел төстә. Тәгәрмәчләре кара. Машина кечкенә. Бу машинада кубиклар, уенчыклар ташырга була. Машина миңа бик ошый. (2–3 баланың хикәясе тыңлана, бәя бирелә.) Булдырдыгыз, балалар!

## *Уникенче бүлек.*
## ҖӘЙ

### Тема: БӨҖӘКЛӘР

**Бурычлар:**

1) балаларның бөҗәкләр турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү;

2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, сүзлек байлыгын киңәйтү, кызыксынуын, төсләрне аера белү осталыгын үстерү.

3) бөҗәкләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** бөҗәкләр (май коңгызы, бал корты, күбәләк, чебен, черки, кырмыска) сурәтләнгән картинкалар.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, без сезнең белән бүген бик кызыклы тереклек ияләре турында сөйләшербез. Нәрсәләр турында икән? Мин хәзер сезгә бер шигырь укыйм. Нәрсәләр турында икәнен шул шигырь аша белеп карагыз әле. Игътибар белән тыңлагыз:

Выжылдаган бөҗәкләрне
Күрсәм, жу итә йөрәк.
Миннән ярдәм көтәләр күк,
Жәллләтәләр бит бигрәк. *(Мөҗәһит)*

Балалар, шигырьдә нәрсәләр турында сүз бара? *(Бөҗәкләр.)* Дөрес, бөҗәкләр турында. Сез нинди бөҗәкләр

беләсез? (Балаларның җаваплары.) (Балалар бөҗәкләрне атыйлар, тәрбияче бөҗәкләр төшерелгән картинкаларны җыелма кесәгә куя бара.) Балалар, май коңгызы, бал корты, күбәләк, чебен, черки, кырмыска бер сүз белән ничек аталалар? *(Бөҗәкләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, бөҗәкләр. Бөҗәкләр зурмы әллә кечкенәме? *(Кечкенә.)* Дөрес, кечкенә. Бөҗәкләр – иң кечкенә тереклек ияләре. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: бөҗәкләр – иң кечкенә тереклек ияләре. (Балаларны активлаштыру.) Бөҗәкләрнең тышкы кыяфәтенә игътибар итегез әле, аларның нәрсәләре бар? *(Канатлары, мыеклары, аяклары бар.)* (Балаларны активлаштыру.) Бөҗәкләр нәрсә белән тукланалар, алар өчен нәрсә азык булып тора икән? *(Үсемлекләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Бөҗәкләр ничек хәрәкәтләнәләр? *(Очалар, йөгерәләр, үрмәлиләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйдәгез, уйнап алыйк әле. Уен "Ул нинди?" дип атала. Мин сезгә бөҗәкләр төшкән картинкалар күрсәтәм. Сез бөҗәкләрнең нинди икәнен әйтегез. Бу нәрсә? (Күбәләк күрсәтә.) *(Күбәләк.)* Дөрес, күбәләк. Күбәләк нинди? (*Матур, җиңел, төрле төсле.)* (Балаларны активлаштыру.) Май коңгызы нинди? *(Алтынсыман, алтын кебек ялтырый.)* Черки нинди? *(Бәләкәй, кечкенә, усал.)* (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, бөҗәкләр төрлечә хәрәкәтләнәләр. Әйдәгез, кайсы бөҗәк ничек хәрәкәтләнгәнен әйтеп карагыз. Май конгызы *(үрмәли, оча.)* (Балаларны активлаштыру.) Күбәләк *(оча.)* (Балаларны активлаштыру.) Бал корты *(оча.)* (Балаларны активлаштыру.) Хәзер бармакларыгызга гимнастика ясап, ял итеп алыгыз!

Чәчәккә кунган күбәләк *(ике кулның да кул чукларын чалыштырып, кул аркаларын бер-берсенә тәңгәл китерелә – күбәләк утыра),*

Күзен йомып утырмый!

Канат җәеп очып китә *(учлар туры һәм киеренке, бармаклар туры),*

Еласаң да тоттырмый! *(Кул беләзекләре белән җиңел һәм кискен хәрәкәтләр ясап, күбәләк очканын күрсәтергә)*.

Балалар, ничек уйлыйсыз, бөҗәкләрне рәнҗетергә, юк итәргә ярыймы? *(Юк.)* Дөрес, бөҗәкләрнең тынычлыгын бозарга ярамый. Кырмыска ояларын туздырмагыз. Бөҗәкләр табигатькә матурлык өстиләр. Балалар, бүген сезнең янга да күбәләкләр очып килделәр. Күбәләкләр нинди төстә? *(Кызыл, сары, яшел, зәңгәр, шәмәхә, ак.)* (Балаларны активлаштыру.) Хәзер һәрберегез берәр күбәләк алыгыз! (Алдан ук тәрбияче келәмгә күбәләкләр төсендәге чәчәкләр куя.) Балалар, күбәләкләргә кошлардан качарга ярдәм итәбезме? *(Әйе.)* Кошлар күрмәсен өчен, һәр күбәләкне үз төсендәге чәчәккә кундырырга кирәк: кызыл күбәләк – кызыл чәчәккә, сары – сарыга, яшел – яшелгә һ. б. Балалар, булдырдыгыз! Төсләрне бик оста аерасыз икән. Балалар, сез бүген нәрсәләр белдегез? Сезгә бигрәк тә нәрсә ошады? (Балаларның җаваплары.) Мин сездән бик канәгать. Барыгызга да матур көн телим!

## Тема: ЧӘЧӘКЛЕ ҖӘЙ

**Бурычлар**

1) балаларны җәй ел фасылына хас билгеләр белән таныштыруны дәвам итү.

2) сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, предметлы картиналар буенча “Җәй” темасына хикәя төзү осталыгын үстерү;

3) тырышып шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** чәчәкләр, гөмбәләр, күбәләкләр, яфраклар, кошлар, яңгыр төшерелгән картинкалар; җөмлә төзү өчен картинкалар (Ромашка агач төбендә үсә. Гөл тәрәзә төбендә үсә. Гөмбә чыршы төбендә үсә. Күбәләк агач астыннан оча. Кырмыска куак төбендә утыра. Май коңгызы таш астына качкан), һәр балага бүләк итү өчен җәй темасына предметлы картинкалар яки уенчыклар, Р. Сәлмәнов сүзләре һәм көенә язылган “Җәй” җырының аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, яз артыннан соң кайсы ел вакыты килә? *(Җәй.)* (Балаларны активлаштыру.) Карагыз әле, бүген безгә җәй үзе килде. (Җәй киеме кигән кыз керә һәм балалар белән исәнләшә.) Җәй белән исәнләшегез әле! *(Исәнме, җәй! Рәхим ит! Түрдән уз!)* Балалар, ни өчен җәйне “чәчәкле җәй” диләр икән? (Балаларның җаваплары.) Балалар, хәзер җәй турында җыр тыңлагыз әле. (“Җәй” җырының аудиоязмасы куела.) Җәй кызы, син дә балалар янына утыр. Без бүген балалар белән җәй турында сөйләшербез. Теләп шөгыльләнгән балага Җәй кызы бүләкләр дә алып килгән. Балалар, сез җәйне яратасызмы? (Балаларның җаваплары.) Җәй сезгә нәрсәсе белән ошый? *(Җылы була, җиләкләр пешә, су коенабыз, урманда, бакчада ял итәргә рәхәт һ. б.).* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, Җәй кызы безгә менә шундый картинкалар алып килгән. Шул картинкаларга карап, җәй көне нәрсәләр күп була икән, шуны билгеләрбез.

Тәрбияче җыелма кесәгә (коврографка, фланелеграфка) 1шәр картинка куя. Мәсәлән, чәчәкләр, гөмбәләр, күбәләкләр, яфраклар, кошлар, яңгырлар һ. б.

Тәрбияче. Балалар, бу картинкага карагыз әле, җәй көне нәрсәләр күп була? (Чәчәкләр төшерелгән картинка куя.) *(Җәй көне чәчәкләр күп була.)* (Балаларны активлаштыру.) (Калган картинкалар белән дә шундый ук эш оештырыла.) Балалар, булдырдыгыз! Җәй кызы сезгә башка төрле картинкалар да алып килгән. Ул картинкалар буенча җөмләләр төзергә кирәк.

Тәрбияче җыелма кесәгә 2шәр картинка куя. Балалар җөмләләр төзиләр: Ромашка агач төбендә үсә. Гөл тәрәзә төбендә үсә. Гөмбә чыршы төбендә үсә. Күбәләк агач астыннан оча. Кырмыска куак төбендә утыра. Май коңгызы таш астына качкан.

Тәрбияче. Балалар, сез бик матур һәм дөрес итеп җөмләләр төзедегез. Җәй кызын да, мине дә шатландырдыгыз.

Балалар, хәзер түгәрәккә басыгыз әле. Җәй кызы сезнең белән уйнап алырга тели. Ул сезгә сүзләр әйтеп, туп ыргытыр. Сез ул сүз алдына “җәйге” сүзен куегыз. Мәсәлән, көн – җәйге көн; кояш – җәйге кояш; һава – җәйге һава, күлмәк –җәйге күлмәк, аяк киеме – җәйге аяк киеме, кәеф – җәйге кәеф, урман – җәйге урман. Балалар, Җәй кызы белән бик күңелле итеп уйнадыгыз. Урыннарыгызга утырыгыз! Картинкага карап җәй турында сөйләшербез. “Җәй җитте. Күктә кояш яктырта. Көн кызу. Балалар су коеналар, самокатта йөриләр. Кешеләр сарафаннар, шортылар кигәннәр. Җәй көне бик күңелле!” (Тәрбияче картинканы җыелма кесәгә куя.) Балалар, кем җәй турында сөйләргә тели? (2–3 бала чакырыла.) Балалар, Җәй кызына китәргә кирәк. Ул сезгә бик кызыклы биремнәр алып килгән. Сез аларны тырышып башкардыгыз. Җәй кызы сезгә күңелле җәй тели һәм сезгә бүләкләрен бирә. (Җәй темасына предметлы картинкалар яки уенчыклар бирә. Саубуллашалар.)

# МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ ӨЛКӘСЕ

| Срок-лар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.–10.09.** | **Белем бәйрәме** | Ә. Хәсәновның “Балалар бакчасында” хикәясен уку | 1) балаларда китапка карата кызыксыну һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыруны, әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешүне дәвам итү; ягымлы сүзләр куллану хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның әдәби сөйләмен, кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) балаларда культура-гигиена күнекмәләре, әхлак сыйфатлары тәрбияләү. |
| | | Г. Лотфиның “Ул бакчаны ярата” шигырен уку | 1) балаларның сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту; шигырьне укыганда, шигырьнең аерым сүзләрен әйтергә мөмкинлек бирү;<br>2) балаларның эмоциональ сферасын үстерү;<br>3) балаларда нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләү. |
| **11.09.–30.09.** | **Көз** | Л. Леронның “Яфрак бәйрәме” шигырен уку | 1) балаларны көзге табигать матурлыгы белән таныштыру; шигырьнең эчтәлеге буенча җавап биргәндә авторның шигъри юлларын кулланырга өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлеген, тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | артыннан сәнгатьле итеп кабатлау осталыгын үстерү;<br>3) балаларда бергә шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге уяту; көзге табигать белән соклану тәрбияләү. |
| | | Г. Гомәрнең “Аю Әппәс” әкиятен уку | 1) балаларга әкиятнең эчтәлеген истә калдырырга һәм сорауларга җавап бирергә ярдәм итү; тәрбияче артыннан персонажларның кайбер фразаларын кабатлау; яшелчәләрнең характерлы билгеләрен ачыклауларына ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, күзәтүчәнлеген, хәтерен, конкрет-образлы фикерләвен, сыйфатлар хисабына сүзлек байлыгын (эшчән, бәләкәй, юмарт) үстерү;<br>3) балаларда бергә шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге, бер-береңә карата уңай сыйфатлар тәрбияләү. |
| **1.10.–20.10.** | **Мин – Дөнья-ның бер кешесе** | Б. Рәхмәтнең “Бакчага киләчәк” шигырен уку. Һөнәрләр турында сөйләшү. | 1) әдәби әсәрне эмоциональ кабул итәргә өйрәтү; һөнәрләр белән танышуны дәвам итү; сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, [һ] авазын сөйләмдә ныгыту;<br>2) кабул итүне, игътибарны, хәтерне, бәйләнешле сөйләм телен үстерү; сүзлек запасын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | баету;<br>3) һөнәрләргә хөрмәт тәрбияләү. |
| **21.10.–04.11.** | **Минем шәһәрем, минем Ватаным** | Ә. Рәшитнең “Кояшлы ил” шигырен уку | 1) балаларның тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын, Татарстан Республикасы турындагы белемнәрен ныгыту; Татарстан Республикасы гимны, картасы турында күзаллаулар формалаштыру;<br>2) балаларның эмоциональ сферасын, кызыксынуын, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда нәфис сүзгә кызыксыну, патриотлык хисләре тәрбияләү. |
| **15.11.–31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Хәйдәрнең “Керпе туны” әкиятен уку | 1) балаларны әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру; сорауларга дөрес җавап бирү осталыгын камилләштерү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга мөмкинлек бирү;<br>2) кабул итүне, хәтерне, игътибарны, сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әкиятләргә уңай караш тәрбияләү. |
| | | М. Фәйзул-линаның “Кыш бабай” шигырен ятлау | 1) балаларны шигъри әсәр белән таныштыру; тәрбияче ярдәме белән шигырьне яттан сөйләргә омтылышларын хуплау; сорауларга текст сүзләре белән җавап бирүдә күнектерү;<br>2) балаларның кабул |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | итүләрен, хәтерен, сүзлек байлыгын, игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменә карата уңай эмоциональ хисләр тәрбияләү. |
| | | Ә.Кариның “Кыш” Шигырен уку | 1) балаларны Ә. Кариның шигыре белән таныштыру; эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүдә күнектерү; резинаның сыйфаты һәм үзлеге белән таныштыру; материал һәм аны куллану ысулы арасындагы бәйләнешне күрергә өйрәтү;<br>2) игътибарны, конкрет-образлы фикерләүне, шигырьдә кулланылган сүзләр хисабына (ап-ак, мамык кебек, бәс) сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) Яңа елга, шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| **01.01.– 31.01.** | **Кыш** | Хәйдәрнең “Керпе туны” әкиятенең эчтәлеген сөйләү | 1) балаларны әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру; сорауларга дөрес җавап бирү осталыгын камилләштерү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга мөмкинлек бирү; эчтәлеген аңларга, сәнгатьле һәм бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) балаларда кайгыртучанлык, ярдәмләшү хисләре тәрбияләү. |
| **01.02.–23.02.** | **Ватанны саклаучылар көне** | К. Булатованың “Солдатлар” шигырен уку | 1) әдәби әсәр аша Ватанны саклаучылар көне белән таныштыруны дәвам итү; шигырьнең эчтәлеген балаларның аңына җиткерү, куелган сорауларга җавап бирүне камилләштерү; [л] авазы белән таныштыру, аның әйтелешен иҗекләрдә, сүзләрдә ныгыту, каты һәм йомшак әйтелешен аеру;<br>2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, танып белү активлыгын, [л] авазын дөрес әйтү культурасын үстерү;<br>3) солдатларга карата хөрмәт, патриотлык хисләре, шигъриятькә мәхәббәт тәрбияләү. |
| **24.02.–08.03.** | **8 Март** | Д. Хәбибуллинаның “Бүләк” шигырен уку | 1) хатын-кызлар бәйрәме турында белемнәрен тирәнәйтү; шигырь текстын тыңларга һәм эчтәлеген аңларга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, сөйләмдә ирекле аралашуларын, башкаларга аңлаешлы итеп җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әниләргә хөрмәт, ярату |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | хисе тәрбияләү. |
| **09.03.–20.03.** | **Халык җәүһәрләре** | Без әкият яратабыз | 1) халык авыз иҗаты – әкиятләр белән таныштыруны дәвам итү; магнитның металлдан ясалган предметларны тарту көче белән таныштыру;<br>2) кабул итүләрен, игътибарын, тикшерү (эксперимент үткәрү), сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; диалоглы сөйләмне камилләштерү;<br>3) балаларда чисталык, пөхтәлек, үзара ярдәм, яхшылыкка омтылу теләге тәрбияләү. |
| **01.04.–20.04.** | **Яз** | К. Ушинскийның “Хайваннар бәхәсе” әсәрен уку | 1) балаларның сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту; сюжетның эзлеклелеген истә калдырырга ярдәм итү; әсәрне игътибар белән аңлап тыңларга өйрәтүне дәвам итү; балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның эмоциональ сферасын, “тип-тап-тап, тип-тап-тап”, “пух-пах-пах”, “ах-ох-ух”, “пу-ту-ту”, “у-у-у”, “чаң-чаң-чаң”, “дың-дың-дың”, “пуф-пуф-пуф”, “уф-уф-уф” аваз ияртемнәре хисабына авазларның дөрес әйтелешен камилләштерү, үстерү;<br>3) балаларда нәфис сүзгә мәхәббәт, йорт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | хайваннарына карата кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| **21.04.–09.05.** | **Җиңү бәйрәме** | Ә. Рәшитнең “Кояшлы ил” шигырен яттан өйрәнү | 1) балаларга шигырнең эчтәлеген аңларга булышу, сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү; кайбер сүзләрнең (ашлык, кыр, күк, аяз) мәгънәсен аңлату, бер-береңнең индивидуаль үзенчәлекләрен күрергә өйрәтү;<br>2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, ишетү хәтерен, иптәшең турында сөйләү теләген үстерү;<br>3) Туган илгә карата патриотлык хисләре, шигърияткә мәхәббәт һәм бер-берсенә карата ягымлы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | “Тавык, Тычкан, Көртлек” татар халык әкиятен сөйләү | 1) балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга булышу, персонажларның гамәлләрен анализлау сәләтен формалаштыру; чикләнгән территориядә бер-береңә бәрелмичә йөгерүдә күнектерү;<br>2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, конкрет-образлы фикерләвен, физик сыйфатларын (тизлек, көч) үстерү;<br>3) татар халык әкиятләренә, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | уңай геройларга карата уңай мөнәсәбәт һәм уенның кагыйдәләрен үтәү теләген тәрбияләү. |
| **10.05.– 31.05.** | **Җәй** | "Күбәләкләр ничек килеп чыккан?" филиппин халык әкиятен уку | 1) әкиятнең эчтәлеген кабул итәргә һәм аңларга өйрәтү; җәй турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, сүзлек байлыгын, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әкиятләр белән кызыксыну, чәчәкләргә, күбәләкләргә сакчыл караш тәрбияләү. |

# *Беренче бүлек.*
# БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ

## Тема: Ә. ХӘСӘНОВНЫҢ "БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА" ХИКӘЯСЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларда китапка карата кызыксыну һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыруны, әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешүне дәвам итү; ягымлы сүзләр куллану хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру;

2) балаларның әдәби сөйләмнәрен, кызыксынуын, игътибарын, хәтерен үстерү;

3) балаларда культура-гигиена күнекмәләре, әхлак сыйфатлары тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Н. Гайсин сүзләренә, Н. Зарипова көенә язылган "Балалар бакчасында" җырының аудиоязмасы,

“Балачак аланы”: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия, 113 бит (авторы – К. В. Закирова).

## Эшчәнлек барышы

“Балалар бакчасында” җырының аудиоязмасы яңгырый.

Тәрбияче. Балалар, игътибар белән җырны тыңлагыз әле. Нинди матур җыр! Ул нәрсә турында икән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу җыр безнең бакча турында. Сез бакчаданиләр эшлисез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар. Ә сез китаплар укыганны тыңларга яратасызмы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, сез нинди китаплар укыганны яратасыз. (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, әкиятләр, шигырьләр, хикәяләр бик кызыклы. Китап укып, күп нәрсәләр белергә була. Шуңа күрә китапларны сакларга кирәк, аларны ертырга, ташларга, пычратырга ярамый. Мин бүген сезгә менә бу китаптан бер матур хикәя укырмын. Ул “Балалар бакчасында” дип атала. Аны Әнәс Хәсәнов сезнең өчен язган. Әнәс Хәсәнов бу хикәянең авторы. Бергәләп кабатлыйк: хикәянең авторы. Игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче хикәяне укый.) Балалар, сезгә хикәя ошадымы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, хикәя кем турында? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, ә Наилә мәктәпкә йөриме, әллә бакчагамы? *(Бакчага.)* Аны иртән бакчага кем илтеп куя? (*Әтисе.*) (Балаларны активлаштыру.) Кич белән өйләренә кем алып кайта? (*Әнисе.*) (Балаларны активлаштыру.) Бакчадан кайтканда әнисе белән Наилә нишлиләр? *(Матур итеп сөйләшәләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Әнисе Наиләдән нәрсә дип сораган? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, “Апалар биргән ризыкларның

барын да ашадыңмы соң?” – дип сораган әнисе. Ә Наилә ничек җавап биргән? *(Әйе, ашадым.)* Тагын әнисе нәрсә дип сораган? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әнисе: “Син алдашмыйсың бит. Ә шулай да иртәгә тәрбияче апаңнан сорармын әле”, – дигәч, кыз нәрсә ди? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар! Ә Наилә әнисенә дөресен әйткәнме? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, ул дөресен әйтмәгән, кыз ашын ашамаган булган. Балалар, әниләрне, гомумән бер кешене дә алдарга ярамый. Әниләр алдаганны шунда ук белеп алалар. Балалар, ашны ашамый калдырырга ярыймы? *(Юк.)* (Балаларны активлаштыру.) Бакчада биргән бөтен ризыкны да ашарга кирәк. Хәзер кулларны юабыз да төшке аш ашарга утырабыз.

## Тема: Г. ЛОТФИНЫҢ “УЛ БАКЧАНЫ ЯРАТА” ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларның сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту, шигырьне укыганда, шигырьнең аерым сүзләрен әйтергә мөмкинлек бирү;

2) балаларның эмоциональ сферасын үстерү;

3) балаларда нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Балачак аланы”: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия, 373 бит (авторы – К. В. Закирова).

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Хәерле иртә, балалар! Кәефегез ничек, әйбәтме? Йокыларыгыз туйдымы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Бүген иртән

барыгызның да бакчага барасы килдеме? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Сез бакчага йөрергә яратасызмы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Мин хәзер сезнең кебек бакчага йөрергә яратучы кыз турында шигырь укырмын. Ул Гасыйм Лотфиның “Ул бакчаны ярата” шигыре.

Көн саен Ләйлә
Бакчага килә.
Соң гына кайта
Кич белән өйгә.

Төрле уенчыклар,
Курчаклар монда.
Кайтасы килми
Ләйләнең шуңа.

Ярата Ләйлә
Көн үткәрергә
Иптәшләр белән
Бакчада бергә.

– Әнием, – ди ул, –
Ашыгып йөрмә.
Мине алырга
Бик иртә килмә.

Балалар, шигырь матурмы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Кызның исеме ничек? *(Ләйлә.)* (Балаларны активлаштыру.) Ул көн саен кая килә? *(Бакчага.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә Ләйлә өенә кайчан кайта? *(Соң гына, кич белән.)* (Балаларны активлаштыру.) Ләйлә бакчада көнен кемнәр белән үткәрә? *(Иптәшләре белән.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, Ләйләнең ни өчен бакчадан кайтасы килми? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, чөнки монда төрле уенчыклар, курчаклар күп. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, Ләйлә әнисенә нәрсә ди? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, без дә туп белән уйнап алыйк әле. Мин тупны сезгә ыргытам, ә сез безнең төркемдә нинди уенчыклар бар, шуларны әйтерсез. Булдырдыгыз! Балалар, әйдәгез шигырьне бергәләп укыйбыз. Мин әйтә башлыйм, сез дәвам итәрсез.

Көн саен... *(Ләйлә)*
Бакчага... (*килә*.)
Соң гына кайта
Кич белән... *(өйгә.)*

Ярата... *(Ләйлә)*
Көн үткәрергә
Иптәшләр белән
Бакчада... *(бергә.)*

Төрле... *(уенчыклар),*
Курчаклар монда.
Кайтасы килми
(*Ләйләнең шуңа*.)

– Әнием, – ди ул, –
Ашыгып... *(йөрмә.)*
Мине алырга
Бик... *(иртә килмә.)*

Булдырдыгыз, балалар! Безнең бакчада бик күңелле, рәхәт. Без сезне һәрвакыт көтеп калабыз. Балалар, әйдәгез, үзебезне мактап кул чабып алыйк әле! Исән-сау булыгыз!

## *Икенче бүлек.*
## КӨЗ

### Тема: Л. ЛЕРОННЫҢ ЯФРАК БӘЙРӘМЕ” ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны көзге табигать матурлыгы белән таныштыру; шигырьнең эчтәлеге буенча җавап биргәндә авторның шигъри юлларын кулланырга өйрәтү;

2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлеген, тәрбияче артыннан сәнгатьле итеп кабатлау осталыгын үстерү;

3) балаларда бергә шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге уяту, көзге табигать белән соклану тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәрҗин, балалар санынча сары яфраклар, яфраклары коелган каен агачы сурәтләнгән ватман, пумала, җилем, салфеткалар, “Яфрак бәйрәме” (Р. Еникеева көе, Л. Лерон сүзләре) җырының аудиоязмасы.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, тыңлагыз әле:

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява,
Җирләр дымлана,
Бу кайчан була?

*(Көз.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес әйттегез. Көз икәнен кайдан белдегез? (Балаларның җаваплары.) Әйе, бу көз көне була. Чөнки көз көне кырлар буш кала, яңгырлар ява. Яңгыр яугач, җир дымлана. Җил агачның яфракларын өзеп кала да, җиргә төшерә. Хәзер мин сезгә Ләбиб Леронның "Яфрак бәйрәме" дигән шигырен укыйм. Игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче сәнгатьле итеп шигырь укый.) Балалар, җиргә нәрсә ява? *(Яфраклар.)* (Балаларны активлаштыру.) Нинди яфраклар җиргә ява? *(Сары, сап-сары.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, сап-сары яфрак нинди була ул? (Балаларның җаваплары.) Дөрес әйтәсез, сап-сары яфрак ул куе сары төстә. Менә мин сезгә андый яфракларны күрсәтәм. (Тәрбияче балаларга куе сары яфраклар күрсәтә.) Сары, сары, сап-сары агачның яфраклары. Ни өчен агачлар яфракларын коялар? (Балаларның җаваплары.) Балалар, көз көне кояш аз яктырта, яфраклар тукланыр өчен витаминнар җитми, аларның сабакка урнашкан урыннары йомшара. Җил исүгә, яфраклар үскән урыннарын калдырып, җиргә төшәләр. Балалар, ни өчен шагыйрь көзне матур чак дип атый. (Балаларның җаваплары.) Мин дә сезнең белән килешәм. Яфраклар төрле төскә керәләр: сары, кызыл, кызгылт, коңгырт. Бик матур яфраклар! Алар төсле келәм кебек җирдә яталар. Агачлардан коелганда, яфраклар бер-берсе белән уйныйлар, бөтереләләр, әйләнәләр. Бу турыда шагыйрь менә нәрсә дип яза:

Җил исә, ява яфрак,
Көзнең матур чаклары.

Оча яфрак, уйный яфрак,
Һаваларда әйләнеп.

Балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле бу юлларны. (Күмәк кабатлау.) Хәзер уйнап алабыз. Сез көзге яфраклар булырсыз. (Тәрбияче “Яфрак бәйрәме” җырының аудиоязмасын куя. Балалар музыка астында яфраклар булып бииләр.) Булдырдыгыз, сез бик матур яфраклар булдыгыз. Мин шигырьне тагын бер тапкыр укып чыгам, сез игътибар белән тыңлагыз, аннан соң үзегезгә ошаган урынын әйтерсез. (Тәрбияче шигырьне укый, аннан соң балаларга ошаган урыннарын яңадан укып чыга.)

Хәзер без дә сезнең белән каен агачын сары яфраклар белән бизәрбез. Менә бу кәрҗиндә яфраклар бар: сары, сап-сары яфраклар.

Алдан ук ватман әзерләп куела. Балалар каен агачына яфраклар ябыштыралар. Тәрбияче ябыштыру кагыйдәләрен искә төшерә: пумала белән юка гына итеп җилем сылап, буялган ягы белән яфракны ябыштырырга һәм салфетка белән басып торырга. Балалар эшләгән вакытта тәрбияче “Яфрак бәйрәме” җырының аудиоязмасын куя.

Тәрбияче. Хәзер сары яфракларны менә бу каен агачына ябыштырабыз. Булдырдыгыз, балалар! Менә нинди матур көзге агач килеп чыкты! Дөрес, чиста, пөхтә итеп эшләдегез! Кич белән әти-әниләрегезгә күрсәтерсез.

## Тема: Г. ГОМӘРНЕҢ “АЮ ӘППӘС” ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларга әкиятнең эчтәлеген истә калдырырга һәм сорауларга җавап бирергә ярдәм итү; тәрбияче артыннан персонажларның кайбер фразаларын кабатлау, яшелчәләрнең характерлы билгеләрен ачыклауларына ирешү;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, күзәтүчәнлеген, хәтерен, конкрет-образлы фикерләвен,

сыйфатлар хисабына сүзлек байлыгын (эшчән, бәләкәй, юмарт) үстерү;

3) балаларда бергә шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге, бер-береңә карата уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәрҗингә салынган яшелчәләр, аю баласының, кишер, кәбестә, чөгендер, кыяр, помидор, шалкан түтәленең контурлы сурәтләре

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, мин сезгә кәрҗин алып кердем. Анда яшелчәләр. Нинди яшелчәләр икән анда? Мин сезгә табышмаклар әйтәм, җавабын табарга тырышыгыз.

Җир астында алтын казык,
Алдык без аны казып.

Бу нәрсә? *(Кишер.)* Кишер икәнен ничек белдегез? (Балаларның җаваплары.) (Тәрбияче кәрҗиннән кишер алып, тәлинкәгә куя.)

Икенче табышмакны тыңлагыз:

Утыра бер ак чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.

Кем җавабын тапты? *(Кәбестә.)* Ни өчен кәбестә? (Балаларның җаваплары.) (Тәрбияче кәрҗиннән кәбестә алып, тәлинкәгә куя.)

Өченче табышмак болай:

Җир астында кызыл әтәч.

Бу нәрсә? *(Чөгендер.)* Кем аңлата ала табышмакның җавабын? (Балаларның җаваплары.) (Тәрбияче кәрҗиннән чөгендер алып, тәлинкәгә куя.)

Алдагы табышмакны тыңлагыз.

Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт.

Кем җавабын тапты? *(Кыяр.)* (Тәрбияче кәрҗиннән кыяр алып, тәлинкәгә куя.)

Игътибар белән алдагы табышмакны тыңлагыз:

Итләч, йомры, яшелен

Өзеп алдым, яшердем;
Гаҗәпләндем бераздан:
Кояшсыз да кызарган.

Кем белде, бу нәрсә? *(Помидор.)* (Тәрбияче кәрҗиннән помидор алып, тәлинкәгә куя.)

Соңгы табышмакны тыңлагыз:

Ите симез – мае юк,
Тиресе калын – йоны юк.

Балалар, кем әйтә табышмакның җавабын? *(Шалкан.)* (Тәрбияче кәрҗиннән шалкан алып, тәлинкәгә куя.)

Менә булдырдыгыз. Табышмакларның җавабын дөрес әйтә алдыгыз. Тәлинкәдә нинди яшелчәләр бар? (Балалар санап чыгалар.) Бу яшелчәләр бик файдалы, сусыл һәм тәмле. Хәзер без ял итеп алырбыз.

Аюның өе зур *(кулларын өскә күтәрәләр),*

Куянныкы кечкенә *(чүгәлиләр),*

Аю бара алпан-тилпән *(алпан-тилпән йөрү хәрәкәтен күрсәтәләр),*

Ә куяннар сикерә *(алда кулларыннан тәпиләр ясап сикерәләр).*

Балалар, мин сезгә бер аю баласы һәм яшелчәләр турында бер әкият сөйлим, тыңлагыз әле. (Тәрбияче “Аю Әппәс” әкиятен сөйли. Сөйләүне рәсемнәр күрсәтү белән бергә алып бара.) Аю баласының исемен әйтегез әле. *(Аю Әппәс.)* (Балаларны активлаштыру.) Аю баласы нинди? *(Бәләкәй, эшчән.)* (Балаларны активлаштыру.) Аю Әппәс нәрсәләр утырткан? *(Кишер, кәбестә, чөгендер, кыяр, помидор, шалкан.)* (Балаларны активлаштыру.) (Балалар әйтергә онытсалар, тәрбияче тәлинкәгә күрсәтә.) Көз җиткәч, аю баласы нишләгән? (Балаларның җаваплары.) Әйтегез әле, яшелчәләрне ашаганда, Аю Әппәс нинди сүзләр әйткән? *(Мәм-мәм мәм, баллы, тәмле, татлы мәми.)* Без дә Аю Әппәснең сүзләрен кабатлыйк әле. (Кабатлыйлар.) Иң беренче булып аю баласы янына нәрсә килгән? *(Куян.)* Куянга Аю Әппәс нәрсә биргән? *(Бер кишер, бер кәбестә, бер чөгендер, бер кыяр, бер помидор, бер шалкан.)* Куян ничек итеп аю баласына рәхмәт әйткән?

(Балаларның җаваплары.) Аю Әппәс тагын нәрсәләрне яшелчә белән сыйлаган? *(Керпене, тиенне.)* Аю баласы турында нәрсә әйтергә була? *(Ул юмарт.)* (Балаларны активлаштыру.) Юмарт кеше үзенең булган әйбере белән уртаклаша, бүлешә, ул бернәрсәсен дә башкалардан кызганмый. Сезгә әкият ошадымы? Нәрсәсе белән ошады? (Балаларның җаваплары.) Сез дә бер-берегезгә карата ягымлы, дус, юмарт булыгыз! Хәзер кулларыгызны юыгыз, Аю Әппәс үстергән яшелчәләр белән сыйланыйк әле. (Балалар яшелчәләр белән сыйланалар.)

## *Өченче бүлек.*
## МИН – ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КЕШЕСЕ

### Тема: Б. РӘХМӘТНЕҢ “БАКЧАГА КИЛӘЧӘК” ШИГЫРЕН УКУ. ҺӨНӘРЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Бурычлар:**

1) әдәби әсәрне эмоциональ кабул итәргә өйрәтү; һөнәрләр белән танышуны дәвам итү; сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, [h] авазын сөйләмдә ныгыту;

2) кабул итүне, игътибарны, хәтерне, бәйләнешле сөйләмне үстерү, сүзлек запасын баету;

3) һөнәрләргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Белмәмеш (уенчык), уенчыклар, зур сумка, шофёр, сатучы, тәрбияче сурәтләнгән картинкалар.

### Эшчәнлек барышы

Балалар, кулга-кул тотынышып түгәрәккә басалар. Чиратлап бер-берсенең кулын кысалар һәм: “Исәнме, ... (исемен әйтә)!
Мин сине күрүемә бик шат!” – диләр.
Тәрбияче балаларга балалар бакчасында уйнаучы балалар һәм тәрбияче сурәтләнгән картина күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, игътибар белән карагыз әле, картинкада кемнәрне күрәсез? *(Балалар һәм бер апа.)* Балалар нишлиләр? *(Уйныйлар.)* Дөрес, балалар, алар уйныйлар. Алар янындагы бу апаны кем дип уйлыйсыз? *(Тәрбияче.)* Тәрбияче апалары балаларны яратамы? (*Әйе*.) Каян белдегез? *(Ул балаларга карап елмаеп тора.)* Без хәзер сезнең белән шул турында шигырь укыйбыз. Шигырь “Бакчага килгәч” дип атала. Аны Бари Рәхмәт язган. Игътибар белән тыңлагыз! (Тәрбияче шигырьне укый.) Шигырьнең исеме нинди? *(Бакчага килгәч.)* Шигырьдә кемнәр турында сөйләнә? (Балалар һәм тәрбиячеләр.) Бакчадагы апалар балаларны яраталармы? (*Яраталар*.) Бакчага килгән балаларны апалар ничек каршы алалар? *(Елмаялар, кочаклап алалар.)* (Индивидуаль күмәк кабатлаулар.) Бакчадагы апалар кемнәр кебек? *(Әниләр кебек.)* шофер Сезне дә балалар бакчасында шулай каршы алалармы? Тәрбияче апагызның исеме ничек? Сез аны яратасызмы? (Балаларның җаваплары.) Ул сезне яратамы? Аның сезне яратуын каян беләсез? (Балаларның җаваплары.) Тәрбияче апалар балаларны бик яратканга күрә, менә шундый матур шигырь язганнар.

Ишек шакыган тавыш ишетелә. Тәрбияче ишекне ачып карый,
Белмәмеш керә.

Тәрбияче. Балалар, безгә бүген кунакка Белмәмеш килгән. Ул үзе белән зур сумка алып килгән.

Белмәмеш. Исәнмесез, балалар! (Исәнләшәләр.) Мин сездән ярдәм сорарга килдем. Шушы зур сумкада бик күп әйберләр бар. Зинһар өчен, миңа шуларны аерырга ярдәм итегез! (Белмәмеш өстәлгә сумкасындагы әйберләрне сала.) Карагыз әле, бу нәрсә? *(Машина.)* Бу нәрсә? *(Китап.)* Ә монысы нәрсә? *(Үлчәү.)* Бу нәрсә? *(Тәгәрмәч.)*

Тәрбияче. Белмәмеш, бигрәк күп әйберләр салып йөрисең икән сумкаңа! Нәрсәләр генә юк монда! Тукта әле, ашыкма, Белмәмеш. Ашыккан ашка пешкән, диләр. Әйдә, алып килгән әйберләреңне балалар белән бергә карыйк. Син менә

монда утырып тор, ә балалар сиңа ярдәм итәләр. (Тәрбияче Белмәмешне өстәлгә утырта, балаларга үлчәү, алъяпкыч күрсәтә.) Балалар, үлчәү, алъяпкыч нинди һөнәр иясенә кирәк? *(Сатучыга кирәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Тәгәрмәч, руль, машина нинди һөнәр иясенә кирәк? *(Шофёрга.)* Әкият китабы, уенчыклар, кайчы, төсле карандашлар кайсы һөнәр иясенә кирәк? *(Тәрбиячегә кирәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Менә күрәсезме инде, Белмәмеш, балалар сиңа бик тиз аңлатып бирделәр. Шофёр, тәрбияче, сатучы – һөнәрләр. Балалар, шофёр, тәрбияче, сатучы – ... *(һөнәрләр.)* (Кабатлыйлар.) Белмәмеш, син дә аңлагансыңдыр, шофёр, тәрбияче, сатучы – һөнәрләр. Балалар, әйдәгез "һ" авазын иҗекләрдә, сүзләрдә ныгытыйк әле. Белмәмеш, син дә кабатла. Минем арттан кабатлагыз: һа-һа-һа-һава; һо-һо-һо-һоп; һу-һу-һу-һуш; һә-һә-һә-һәйкәл; һө-һө-һө-һөнәр. Балалар, "һ" авазы кергән нинди сүзләр әйттегез? (һава, һоп, һуш, һәйкәл, һөнәр.) Әйдәгез, бу сүзләрне тагын бер кат бергәләп кабатлап чыгабыз. (Балалар кабатлыйлар.) Булдырдыгыз! Хәзер һөнәрләр турында сөйләп алыйк. Бу кем? (Тәрбияче шофёр төшерелгән картинка күрсәтә.) *(Шофёр.)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар.) Ул нишли? (*Ул машина йөртә.*) (Балаларны активлаштыру.) Кемнең әтисе шофёр булып эшли? Ул нинди машина йөртә? (Балаларның җаваплары.) Балалар, сезгә Марат "Шофёр булам" шигырен сөйләп күрсәтер. (Бала шигырьне алдан ук өйрәнә.)

Мин дә әтием шикелле
Шофёр булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт
Машинам белән уйныйм.
Тизрәк үсеп, шофёр булсам,
Нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы
Утыртып йөрер идем. *(Зәкия Туфайлова)*

Балалар, Марат шигырьне сәнгатьле итеп сөйләде. Әйдәгез, аны мактап, кул чабабыз. (Кул чабалар.) (Алга таба сатучы, тәрбияче турында сөйлиләр.)

Белмәмеш. Балалар, мин бик күп нәрсәләргә өйрәнеп утырдым. Мин хәзер шофёр, сатучы, тәрбияче һөнәрләрен беләм. Сезгә зур рәхмәт. Бу турында дусларыма да сөйлисем килә. Мин китәм. Уенчыкларны мин сезгә уйнарга калдырам. Сау булыгыз!

Тәрбияче. Бик яхшы, Белмәмеш. Без синең өчен сөенәбез. (Белмәмеш китә.) Балалар, сез бүген нәрсәгә өйрәндегез? Нәрсә белдегез? Сезгә нәрсә ошады? (Балаларның җаваплары.) Хәзер Белмәмеш калдырып киткән уенчыклар белән уйнап алыйк. Сезгә матур көн телим!

## *Дүртенче бүлек.*
## МИНЕМ ШӘҺӘРЕМ, МИНЕМ ВАТАНЫМ

### Тема: Ә. РӘШИТНЕҢ “КОЯШЛЫ ИЛ” ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларның тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын, Татарстан Республикасы турындагы белемнәрен ныгыту; Татарстан Республикасы гимны, картасы турында күзаллаулар формалаштыру;

2) балаларның эмоциональ сферасын, кызыксынуын, фикерләвен үстерү;

3) балаларда нәфис сүзгә кызыксыну, патриотлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Балачак аланы”: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия, 136 бит (авторы – К. В. Закирова), Р. Байтимеров сүзләре, Р. Яхин көе, русчага Ф. Пираев тәрҗемәсендә «Туган ягым» (Татарстан Республикасы гимны) аудиоязмасы, “тылсымлы тартма”, аның эчендә Татарстан Республикасы картасы.

## Эшчәнлек барышы

Татарстан Республикасы гимны аудиоязмасы куела.

Тәрбияче. Балалар, барыгызга да хәерле көн телим! Уң кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең уң кулыгыз! Уң кулыгызга сокланып карагыз! Сул кулыгызны күрсәтегез! Нинди матур сезнең сул кулыгыз! Уң кул бармаклары чиратлап сул кул бармаклары белән исәнләшәләр:

Саумы, кояш!
Саумы, һава!
Саумы, иртә!
Саумы, йомшак җил!
Саумы, Туган ил!

Балалар, сез нәрсә ишетәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Бу матур көй – безнең Татарстан Республикасының гимны. Бергәләп кабатлыйк: гимн. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, һәр илнең, һәр дәүләтнең флагы, гербы булган кебек, җыры да була, аны башкача “гимн” дип йөртәләр. Әйдәгез, бергәләп тыңлыйк әле. (Татарстан Республикасы гимнының бер тыңлыйлар.) Балалар, менә нинди матур безнең Республика гимны. Балалар, Туган илебез дә шундый матур. Аның турында бик күп җырлар, шигырьләр язылган. Хәзер мин сезгә Әхмәт Рәшит язган “Кояшлы ил” шигырен укырмын.

Кояшлы ил – безнең ил,
Күге аның гел аяз.
Кыш китерсә Кыш бабай,
Чәчәк алып килә Яз.
Сандугачлы урманы,
Ашлык тулы кырлары,
Бөтен җирдә яңгырый
Безнең бәхет җырлары.
Һавасы да, җире дә,

Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да –
Безгә якын бары да...

Сезгә шигырь ошадымы? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, безнең ил нинди? *(Кояшлы ил.)* (Балаларны активлаштыру.) Безнең илнең күге нинди? *(Гел аяз.)* (Балаларны активлаштыру.) Кышны кем китерә? *(Кыш бабай.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә Яз нәрсә алып килә? *(Чәчәк алып килә.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, безнең илнең урманы нинди? *(Сандугачлы.)* (Балаларны активлаштыру.) Кырлары нәрсә белән тулган? *(Ашлык.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә хәзер минем арттан кабатлагыз:

Бөтен җирдә яңгырый
Безнең бәхет җырлары.
Һавасы да, җире дә,
Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да –
Безгә якын бары да...

(Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Бу нәрсә икән? (Тәрбияче өстәлдә торган тартма янына килә.) Балалар, "тылсымлы тартма" ахрысы. Монда килегез әле, бергә карыйк. (Тәрбияче тартманы ача.) Балалар, сез беләсезме, бу нәрсә? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу безнең Татарстан Республикасының картасы. Бергәләп кабатлыйк: Татарстан Республикасының картасы. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу безнең Татарстан Республикасының кечерәйтеп ясалган рәсеме. Әйдәгез, бергәләп карыйк. Менә, балалар, монда сандугачлы урманы, ашлык тулы кырлары, монысы зур шәһәрләре. Менә шундый матур, зур, кояшлы безнең Туган илебез! Сез бүген дөрес җаваплар бирдегез, актив булдыгыз.

Хәзер карта карауны дәвам итәрсез, безнең шәһәрне (авылны) табарсыз.

## *Бишенче бүлек.*
# ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

### Тема: ХӘЙДӘРНЕҢ “КЕРПЕ ТУНЫ” ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру; сорауларга дөрес җавап бирү осталыгын камилләштерү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга мөмкинлек бирү;

2) кабул итүне, хәтерне, игътибарны, сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирү осталыгын үстерү;

3) әкиятләргә уңай караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** әкиятнең эчтәлеге буенча картинкалар (1) җәй – җәнлекләр күлмәкчән йөриләр; 2) кыш килгән, аю – тиреләр кайтарткан; 3) керпе туннар тегә; 4) керпе күлмәгенә энәләр кадый; 5) керпе өнендә йоклый).

### Эшчәнлек барышы

Балалар, кулга-кул тотынышып түгәрәккә басалар.
Чиратлап бер-берсенең кулын кысалар һәм
“Исәнме, ... *(исемен әйтә)*! Мин сине күрүемә бик шат!” – диләр

Тәрбияче. Балалар, нинди бәйрәм якынлаша? *(Яңа ел бәйрәме.)* Без сезнең белән бу бәйрәмне түземсезлек белән көтәбез. Урман җәнлекләре дә Яңа елга килергә әзерләнәләр икән. Балалар, сез урманда яши торган нинди җәнлекләрне беләсез? (Балаларның җаваплары.) Кыш бабай җәнлекләрнең барысын да Яңа ел бәйрәменә чакырган. Бер җәнлек килә алмый икән. Кайсы җәнлек икән ул? Табышмак әйтәм, тыңлагыз, җавабын тапсагыз белерсез:

Ул өстенә җәй дә кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе
“Йомшагым” диеп сөя.

Балалар, кайсы җәнлек Яңа ел бәйрәменә килә алмый? *(Керпе.)* Ни өчен икән? Шул турыда мин сезгә әкият сөйләрмен. Әкият “Керпе туны” дип атала. Игътибар белән тыңлагыз.

Тәрбияче әкият сөйли, сөйләгәндә әкиятнең эчтәлеге буенча сюжетлы картинкалар күрсәтә. Әкиятне сөйләгәч, аның эчтәлеге буенча фикер алышалар.

Тәрбияче. Балалар, мин сөйләгән әкиятнең исеме ничек? *(Керпе туны.)* (Балаларны активлаштыру.) Әкияттә нәрсә турында сөйләнә? (Балаларның җаваплары) Әкият башында кайсы ел вакыты турында сүз бара? (Җаваплар.) Җәй көне җәнлек – җанварлар ничек киенеп йөргәннәр? *(Күлмәкчән генә йөргән.)* (Балаларны активлаштыру.) Бервакыт нинди хәбәр таралган? *(Кыш килә.)* Кыш килгәч нәрсә булган? *(Суык җилләр искән, кар төшкән.)* Урман хуҗасы булып нинди җәнлек торган? *(Аю.)* Ул нәрсә эшләгән? *(Җәнлекләргә тун тектергән.)* (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар) Керпе кем булып эшләгән? *(Тегүче.)* Ни өчен? *(Аның энәләре булган.)* Керпе тунны нәрсәдән теккән? *(Тиредән.)* Ни өчен керпе үзенә тун тегә алмаган? *(Тире җитмәгән.)* Тун тегә алмагач, керпе нәрсә эшләгән? *(Күлмәгенә энәләр кадап чыккан.)* Энәле тун керпене салкыннан саклаганмы? *(Юк.)* Салкынга түзә алмагач, керпе нишләгән? *(Җирне тишеп өн ясаган)* Дөрес, балалар, керпе җирне тишеп өн ясаган һәм салкын кышны өнендә үткәргән. Хәзер дә керпеләр шулай эшлиләр. Ни өчен керпе Яңа ел бәйрәменә килә алмый? *(Аңа салкын, ул өнендә йоклый.)* Балалар, сезгә әкият ошадымы? Бигрәк тә сезгә нәрсә ошады? Керпе башка җәнлекләргә бик булышкан, аларны тунлы иткән.

Уңган, тырыш тегүче керпе турында менә нинди матур әкият язылган.

## Тема: М. ФӘЙЗУЛЛИНАНЫҢ “КЫШ БАБАЙ” ШИГЫРЕН ЯТЛАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны шигъри әсәр белән таныштыру; тәрбияче ярдәме белән шигырьне яттан сөйләү омтылышын хуплау; сорауларга текст сүзләре белән җавап бирүдә күнектерү;

2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, сүзлек запасын, игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;

3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменә карата уңай эмоциональ хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Балачак аланы”: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия, 123 бит (авторы – К. В. Закирова), А3 форматында шигырь эчтәлегенә туры килгән Яңа ел бәйрәме күренеше сурәтләнгән картина, Яңа ел темасына күңелле көй аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче фланелеграфка Яңа ел бәйрәме күренеше сурәтләнгән картина куя.

Тәрбияче. Балалар, нинди бәйрәм якынлаша? *(Яңа ел, чыршы бәйрәме, ёлка.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, карагыз әле монда нинди матур картина. Сез монда нәрсәләр күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Яңа ел бәйрәмендә балалар нишлиләр? *(Җырлар җырлыйлар, бииләр, чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйныйлар.)* (Балаларны активлаштыру.) Балаларның бәйрәменә кем килгән? *(Кыш бабай.)* (Балаларны активлаштыру.) Кыш бабайның җилкәсендә нәрсә бар? *(Капчык.)* (Балаларны активлаштыру.) Кыш бабайның капчыгында нәрсәләр бар икән соң? *(Күчтәнәчләр, бүләкләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә ул бүләкләрен кемгә бирә? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.)

(Балаларны активлаштыру.) Әйе, ул бүләкләрен җыр җырлаган, шигырь сөйләгән балаларга бирә. Балалар, без дә бүген сезнең белән яттан сөйләргә бер шигырь өйрәнербез. Мин аны башта сезгә бер кат укыйм. Ул Мәрзия Фәйзуллинаның “Кыш бабай” шигыре.

Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде.
Төрле кызык сүзләр әйтеп,
Бүләк өләшеп йөрде.
Аннан Кыш бабай тыпырдап,
Бик шәп бии башлады.
Биемәскә, аягында –
Безнең апа башмагы.

Менә нинди кызык шигырь. Балалар, әйдәгез, без дә Кыш бабай кебек биеп алыйк. (Яңа ел темасына туры килгән күңелле көй аудиоязмасы куела.) Булдырдыгыз, балалар! Игътибар белән тыңлагыз, шигырьне тагын бер кат укыйм. (Тәрбияче шигырьне тагын бер кат сәнгатьле итеп укый.) Ә хәзер шигырьне укырга сез миңа булышырсыз. Мин шигырь юлларын әйтә башлыйм, ә сез дәвам итәрсез.

Җилкәсенә... *(капчык асып),*
Кыш бабай... *(килеп керде).*
Төрле кызык... *(сүзләр әйтеп),*
(*Бүләк*) өләшеп йөрде.
Аннан... *(Кыш бабай)* тыпырдап,
Бик шәп... *(бии башлады).*
Биемәскә, аягында –
*(Безнең апа башмагы).*

(Балаларны активлаштыру.) Балалар, әйдәгез, шигырьне мин тагын бер кат укыйм, сез минем арттан кабатлагыз һәм хәрәкәтләр ясагыз. (Шигырь эчтәлегенә туры китереп,

хәрәкәтләр ясыйлар.) Булдырдыгыз, балалар! Шигырьне кайсыгыз сөйләп күрсәтә? (Балаларны активлаштыру.) (Тәрбияче берничә баладан сөйләтеп карый.) Булдырдыгыз, балалар! Бу шигырьне сөйләсәгез, Кыш бабай бик сөенер, сезгә рәхмәт әйтер. (Ятлау авыррак бирелгән балалар белән тәрбияче эшне дәвам итә.)

## Тема: Ә. КАРИНЫҢ “КЫШ” ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны Ә. Кариның шигыре белән таныштыру, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүгә күнектерү; резинаның сыйфаты һәм үзлеге белән таныштыру; материал һәм аны куллану ысулы арасындагы бәйләнешне күрергә өйрәтү;

2) игътибарны, конкрет-образлы фикерләүне, шигырьдә кулланылган сүзләр хисабына (ап-ак, мамык кебек, бәс) сүзлек байлыгын үстерү;

3) Яңа елга, шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кыш сурәтләнгән рәсемнәр (ак карга төренгән урамнар, бәскә күмелгән агачлар; урамда уйнаучы балалар: таудан чана шуалар), 1 кабартылган, 1 кабартылмаган һава шарлары, таз яки табак белән су, резин перчаткалар.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, балалар бакчасында тиздән нинди бәйрәм булачак? *(Яңа ел.)* (Балаларны активлаштыру.) Яңа ел бәйрәмендә балалар нишлиләр? *(Җырлар җырлыйлар, бииләр, чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйныйлар.)* Дөрес, балалар, без җырлар, биюләр, уеннар өйрәнәбез. Яңа ел бәйрәменә кемнәр килә? *(Кыш бабай, Кар кызы, әтиләр, әниләр.)* Бик дөрес, балалар. Яңа ел бәйрәмендә иң кадерле кунак – Кыш бабай. Әйдәгез, без дә Кыш бабай, кыш турында шигырь өйрәник әле. Шигырьне игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче сәнгатьле итеп шигырь укый.) Балалар, кемне балалар сагынып алалар? *(Кыш*

*бабайны.)* Кыш бабай нәниләрне ничек сагынган? *(Ул балалар өчен карлар яудырган.)* Карны нәрсә белән чагыштырып була? *(Мамык белән.)* Әйе, кар мамык кебек ак, йомшак. Урамнар, кырлар нәрсә белән капланган? *(Ап-ак кар белән капланган.)* Кышын агачлар бәс белән каплана. Балалар, карагыз әле бу рәсемгә. Агачлар бәс белән капланган. Нәрсә белән капланган? (Күмәк һәм индивидуаль җаваплар.) Балалар кышын нишлиләр? *(Чана шуалар, шаулашалар, "на-на" дип кычкыралар.)* Әйе, кышын балаларга бик күңелле, алар кар белән уйныйлар, чана, тимераякта шуалар, Кар бабай ясыйлар. Кыш – балалар өчен көтелгән бәйрәм. (Тәрбияче балаларга рәсемнәр күрсәтә.) Мин тагын бер тапкыр шигырьне укып чыгам, сез тыңлагыз. (Тәрбияче шигырь укый.)

Балалар, хәзер без сезнең белән уйнап алабыз.

Без суыктан курыкмыйбыз
Куллар белән колакларны *(колакларын, борыннарын ышкыйлар),*
Борыннарны ышкыйбыз.
Кулларны чәбәклибез *(кул чабалар),*
Яканы күтәрәбез *(яканы күтәргән хәрәкәт ясыйлар).*
Урында сикерәбез *(урында сикерәләр),*
Аннары йөгерәбез *(урында йөгерәләр).*
Суыктан курыкмыйбыз *(аяк очларына басып, кулларын өскә күтәреп чәбәклиләр).*

(2–3 тапкыр кабатлыйлар.)

Балалар, Яңа ел бәйрәме алдыннан бүлмәләрне, музыка залын бәйрәмчә бизиләр. Мишуралар, чыршы уенчыклары эләләр, гирляндалар асалар. (Тәрбияче уенчыклар белән бизәлгән чыршы рәсеме күрсәтә.) (Шул вакыт төркем бүлмәсенә шар очып керә.) Балалар, бу нәрсә? (Балаларны активлаштыру.) Бүлмәне шарлар белән дә бизәргә була. Балалар, шар үзе турында бернәрсә дә белми икән. Әйдәгез, аның нинди материалдан ясалуы турында сөйлик. Балалар, шар нинди материалдан эшләнгән? *(Резинадан.)* (Балаларны активлаштыру.) Резина йомшак һәм шома. (Балалар тотып карыйлар.) (Балаларны активлаштыру.) Шар зур. Ул кечкенә дә

була ала. (Тәрбияче һавасы чыгарылган шар күрсәтә.) Балалар, шарны таздагы суга салам. Шар нишләде? (Балалар шарны тотып карыйлар.) *(Юешләнде.)* (Балаларны активлаштыру.) Карагыз әле, шарны сөртәм. Ул хәзер нинди? (Тотып карыйлар.) *(Коры.)* (Балаларны активлаштыру.) Ничек уйлыйсыз, шар су үткәрәме? *(Юк, шар су үткәрми.)* Әйдәгез тәҗрибә үткәреп карыйк әле. Кулларга перчаткалар киябез, суга тыгабыз. Куллар юешләндеме? *(Резинадан эшләнгән әйберләр су үткәрми.)* Балалар, резинадан эшләнгән нинди әйберләр беләсез? *(Резин итек, чәч өчен резинка, перчаткалар.)* (Балаларны активлаштыру.) Менә резинадан ясалган шарга аның турыда сөйләдек. Ул канәгать калды, сезгә "рәхмәт" ди.

# *Алтынчы бүлек.*
# КЫШ

## Тема: ХӘЙДӘРНЕҢ "КЕРПЕ ТУНЫ" ӘКИЯТЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕН СӨЙЛӘҮ

**Бурычлар:**

1) балаларны әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру; сорауларга дөрес җавап бирү осталыгын камилләштерү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга мөмкинлек бирү, эчтәлеген аңларга, сәнгатьле һәм бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәтү;

2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;

3) балаларда кайгыртучанлык, ярдәмләшү хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** "Балачак аланы". Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия, 102 бит (авторы – К. В. Закирова), А4 форматында керпе рәсеме, фланелеграф.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балаларга керпе рәсеме күрсәтә.

Тәрбияче. Балалар, бу рәсемдә нәрсә күрәсез? *(Керпе.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә керпенең нәрсәләре бар? Ул нинди? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, аның энәләре бар. Ул энәләре белән дошманнарыннан саклана. Куркыныч янаса, ул йомгак булып бөтерелә дә энәләрен тырпайта. Балалар, хәтерлисезме, мин сезгә керпе энәләренең, аның тунының каян килеп чыгуы турында Хәйдәр дигән язучының “Керпе туны” әкиятен укыган идем. Хәзер тагын бер кат укырмын, тыңлагыз әле. (Тәрбияче әкиятне укый.) Балалар, борын-борын заманда кыш булганмы? *(Юк.)* (Балаларны активлаштыру.) Җәнлекләр ничек йөргән? *(Күлмәкчән.)* (Балаларны активлаштыру.) Алар ни өчен шулай йөргәннәр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бервакыт нинди хәбәр таралган? *(Кыш килә!)* (Балаларны активлаштыру.) Кыш ничек килгән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ә суык җилләр ничек исә? Җилләр ничек улый? *(У-у-у.)* Күрсәтик әле, барыбыз да кулларны як-якка җәеп, җил кебек улап йөгерик. (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз! Балалар, урман хуҗасының исеме ничек? *(Аюхан.)* Аюхан ни өчен тире кайтарткан? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Ә ул туннарны кайсы җәнлек теккән? *(Керпе.)* (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен Керпе теккән? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Керпе кыш килеп җиткәнче, һәммәсен дә тунлы иткән. Балалар, ә Керпенең үзенә тун тегәргә тире калганмы соң? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әкиятнең бу өзеген тагын бер кат тыңлагыз әле.

Караса, үзенә тун тегеп киярлек тире дә калмаган. Шуннан соң Керпе күлмәгенә энәләр кадап чыккан да тунлы булган. Әмма аның туны салкын җилләрдән сакламаган шул... Керпе, салкынга түзә алмыйча, җирне тишеп, өн ясаган да шунда кереп яткан. Салкын кыш үтеп киткәнче, өнендә йоклаган. Бу хәлдән соң күпме заманнар узган инде. Әмма Керпе әле һаман да салкын кышларны өнендә үткәрә, ди.

Балалар, тире калмагач, Керпе күлмәгенә нәрсәләр кадаган? *(Энәләр.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә аның туны кышкы салкыннардан, җилләрдән саклаганмы соң? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Керпе, салкынга түзә алмыйча, җирне тишеп, өн ясаган да шунда кереп яткан. Керпе салкын кышларны кайда үткәрә? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Менә шулай, балалар, Керпе башкаларга ярдәм иткән. Сез дә шундый дус, ярдәмчел булыгыз!

Хәзер мин сезгә әкиятне тагын бер кат укыйм, ә сез аның эчтәлеген сөйләрсез, шуңа күрә исегездә калдырырга тырышыгыз! (Тәрбияче әкиятне тагын бер кат укый)

Балалардан әкиятне тулысынча яки өлешчә сөйләтергә мөмкин.

Тәрбияче. Балалар, булдырдыгыз! Әкиятнең эчтәлеген ятлагансыз, аны яхшы итеп исегездә калдыргансыз. Бүген сез нәрсәгә өйрәндегез? Нәрсә ошады? Нәрсә исегездә калды? (Балаларның җаваплары.)

## *Җиденче бүлек.*
## ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

### Тема: К. БУЛАТОВАНЫҢ “СОЛДАТЛАР” ДИГӘН ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) әдәби әсәр аша Ватанны саклаучылар көне белән таныштыруны дәвам итү; шигырьнең эчтәлеген балаларның аңына җиткерү, куелган сорауларга җавап бирүне камилләштерү; [л] авазы белән таныштыру, аның әйтелешен иҗекләрдә, сүзләрдә ныгыту, каты һәм йомшак әйтелешен аеру;

2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, танып белү активлыгын, [л] авазын дөрес әйтү культурасын үстерү;

3) солдатларга карата хөрмәт, патриотлык хисләре, шигърияткә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** коврограф (мольберт), бабай, әти, олы һәм кече абый рәсемнәре, уенчык көчек.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, тиздән нинди бәйрәм җитә? *(Иртәгә бабайлар, әтиләр бәйрәме, Ватанны саклаучылар бәйрәме.)* Булдырдыгыз. Әйе, иртәгә Россия армиясендә хезмәт иткән һәм хезмәт итүче солдатлар бәйрәме. Балалар, һәр илнең армиясе бар. Армиянең бурычы үз Ватанын саклау, аны дошманнарга бирмәү. Безнең илнең дә үз армиясе бар. Россия армиясе үз халкын илбасарлардан саклаган, хәзер дә саклый. Безнең армия зур һәм көчле. Армиядә һәр егет хезмәт итәргә тиеш. Хәзер мин сезгә Клара Булатованың “Солдатлар” дигән шигырен укыйм. Сез игътибар белән тыңлагыз, аннан соң сорауларга җавап бирерсез.

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган,
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган...
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына.
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

(Икенче тапкыр укыганда коврографка бабай, әти, зур абый, кече абый һәм кечкенә малай рәсемнәрен куя.) Балалар, бу шигырьдәге сүзләрне кем әйтә, сез ничек уйлыйсыз? *(Малай.)* (Балаларны активлаштыру.) Малай кечкенәме, зурмы? *(Кечкенә, бәләкәй.)* Малайның кемнәре солдатта булган? *(Бабасы, әтисе, зур абыйсы, кече абыйсы.)* (Балаларны активлаштыру.) Армиядә малайның бабасы, әтисе, ике абыйсы нәрсә эшләгән? *(Илне, Ватанны саклаганнар.)* (Балаларны активлаштыру.) Малай солдатка барырга телиме? *(Үскәч, ул да солдат булырга тели.)* Дөрес әйтәсез, малай да бабасы, әтисе, ике абыйсы кебек армиядә хезмәт итәргә, солдат булырга тели. Солдат булу өчен шөгыльләнергә кирәк: йөгерергә, сикерергә, үрмәләргә.

Хәзер без уйнап алырбыз.

Балалар “Күрсәт әле, үскәнем” дигән уенны уйныйлар:
1) Менә шулай, менә шулай, шулай сикерәләр солдатлар;
2) Менә шулай, менә шулай, шулай йөгерәләр солдатлар;
3) Менә шулай, менә шулай, шулай үрмәлиләр солдатлар.

Тәрбияче. Булдырдыгыз, балалар. Шөгыльләнгән солдатлар гына көчле, кыю, сәламәт, җитез булалар. Солдатлар белән без горурланабыз. Шигырьне мин тагын бер тапкыр укып чыгам, тыңлагыз. (Тәрбияче шигырь укый.) Хәзер без солдатлар булырбыз. Икешәрләп тезелегез. Менә шулай. Шагом марш! (Марш көе яңгырый.) Аркалар төз, аякларны күтәрәбез. Булдырдыгыз. (Балалар солдатлар кебек атлыйлар.)

Балалар, солдат сүзендә *л* авазы бар. Минем телем *л* авазының җырын өйрәнде. Карагыз әле, минем телем бу җырны менә ничек итеп җырлый: телегезне чыгарыгыз, аны киң итеп ясагыз, өскә күтәрегез һәм югары тешләргә китерегез. Яңакларыгызны кабартыгыз, яңгыравык тавыш белән җырлагыз *(Л-л-л)*. Булдырдыгыз. Азрак ял итеп алыгыз да, тагын бер тапкыр җырлагыз. Бу җырны Алсу ничек итеп җырлый, тыңлап карыйк әле. (Балаларны активлаштыру.) Балалар, бу нәрсә? *(Кыңгырау.)* Тыңлагыз әле кыңгырауның җырын *(Ли-ли-ли)*. (Кызлар аерым, малайлар аерым җырлый, берничә бала индивидуаль җырлый.) Булдырдыгыз, балалар. Без хәзер төрле җырлар җырларбыз *(Лә-лә-лә-лә, ла ла-ла-ла, лү-лү-лү-лү, лу-лу-лу-лу, ли-ли-ли-ли)*. Балалар, нинди җыр кыңгырау җырына ошаган: ла-ла-ла җырымы әллә лә-лә-лә җырымы? (Каты яки нечкә *л* авазын бутаучы баладан сорарга.) Балалар, бу нәрсә? *(Көчек.)* (Тәрбияче уенчык көчекне күрсәтә.) Көчек нинди? *(Кечкенә.)* *(л* авазын сүзләрдә ныгыту*)*. Балалар, көчек өрә беләме? *(Юк, ул әле кечкенә.)* Сез бүген актив катнаштыгыз. Сорауларга матур итеп җавап бирдегез, солдатлар булып йөрдегез, *л* авазын дөрес әйтергә өйрәндегез.

## *Сигезенче бүлек.*
## 8 МАРТ

### Тема: Д. ХӘБИБУЛЛИНАНЫҢ “БҮЛӘК” ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларның хатын-кызлар бәйрәме турындагы белемнәрен тирәнәйтү; шигырь текстын тыңларга һәм эчтәлеген аңларга өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, сөйләмдә ирекле аралашуларын, башкаларга аңлаешлы итеп җавап бирү осталыгын үстерү;

3) әниләргә хөрмәт, ярату хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** һәр балага альбом битләре, төсле карандашлар, П. И. Чайковский музыкасының аудиоязмасы (“Ел вакытлары” циклыннан “Умырзая. Апрель” пьесалары.)

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басыгыз. “Хәерле иртә!” – дип, башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып әйтегез. Мин дә сезгә хәерле иртә телим. Балалар, елның кайсы вакыты *(Яз.)* Әйе, яз. Язның беренче ае – март. Март аенда нинди бәйрәм була? *(8 Март бәйрәме.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, 8 Март – Язның беренче бәйрәме. 8 Март – әниләр, әбиләр, апалар, сеңелләр бәйрәме. Икенче төрле ничек әйтәләр? *(Хатын-кызлар бәйрәме.)* (Балаларны активлаштыру.) Әниләргә нәрсә бүләк итәргә була икән соң? Сорауга җавап биргәнче Данис Хәбибуллинның “Бүләк” дигән шигырен тыңлагыз:

Нәни кыз Гөлчәчәк
Салкын кыш көнендә
Чәчәкләр үстерә
Тәрәзә төбендә.
Су сибә аларга
Һәр иртә һәм кичен,
Беләмсез ул шулай
Тырыша ни өчен?
Тиздән бит әниләр
Бәйрәме җитәчәк,
Шул көнгә зур бүләк
Әзерли Гөлчәчәк.

Балалар, әниләргә нәрсә бүләк итәргә була? *(Чәчәкләр.)* Шигырьнең исеме дә ничек дип атала? *(Бүләк.)* (Активлаштыру.) Шигырьдә кем исемле кыз турында сүз бара? *(Гөлчәчәк.)* Ул нәрсә эшли? *(Чәчәкләр үстерә.)* Гөлчәчәк чәчәкләрне ничек карый? *(Аларга һәр иртә һәм кичен су сибә.)*

Гөлчәчәк әнисенә бүләккә нәрсә бирер? *(Чәчәкләр.)* Булдырдыгыз! Балалар, җайлап утырыгыз. Аркаларыгыз төз. Күзләрне йомыгыз. Сез үзегезне орлык итеп хис итегез. Сезне кояш җылыткан җиргә утырттылар. Җиргә эләккәч, орлыклар җылындылар. Орлыклардан кечкенә генә нәфис үсентеләр тишелеп чыктылар. Кояш көннән-көн ныграк җылыта, һәм үсентеләр дә тизрәк үсә башладылар. Үсенте, көч җыеп, җирне тишеп, саф һавага чыкты. Яфракларыгыз үсте, сабакларыгыз ныгыды, сез яктыга, кояшка үреләсез. Бик яхшы. Менә сабакта чәчәк бөресе барлыкка килде. Ул үсә, бүртә, таҗ яфраклары чыга башлады. Таҗ яфраклары башта бөгәрләнгән кебек тоелсалар да, алар матур булып тигезләнделәр, һәм бик матур язгы чәчәк барлыкка килде. Чәчәкләрдән тирә-якка хуш ис таралды. Үз чәчәкләрегезнең хуш исен тоемлап карагыз әле. Менә нинди тәмле ис килә, иснәп карагыз әле. Булдырдыгыз! Хәзер инде сез чәчәкләрнең ничек үскәнен беләсез. Балалар, әйдәгез, сез дә әниләрегезгә бүләккә чәчәкләр ясагыз әле. Телисезме? Һәрберегезнең альбом бите һәм карандашларыгыз бар. Альбом битенә үзегезгә ошаган чәчәкне ясагыз. (Тәрбияче П. И. Чайковский музыкасының аудиоязмасын куя. Балалар рәсем ясыйлар.) Балалар, менә нинди матур чәчәкләр ясадыгыз. Бик тә тырыштыгыз. Әниләрегез дә шатланыр. Әйдәгез, әниләргә теләкләр телик. Барыгыз да басыгыз! Һәрберегез әниегезгә нәрсә телисегез килә, чиратлап, шуны әйтегез. (Балалар әниләренә теләкләр телиләр: “Бәхет телим”, “Шатлык телим”, “Исәнлек телим”, “Матурлык телим”, “Татулык телим” һ. б.). Булдырдыгыз! Әниләрне яратыгыз! Аларны борчымагыз!

# *Тугызынчы бүлек.*
# ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

## Тема: БЕЗ ӘКИЯТ ЯРАТАБЫЗ

**Бурычлар:**

1) халык авыз иҗаты – әкиятләр белән таныштыруны дәвам итү; магнитның металлдан ясалган предметларны тарту көче белән таныштыру;

2) кабул итүләрен, игътибарын, тикшерү (эксперимент үткәрү), сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү, диалоглы сөйләмне камилләштерү;

3) балаларда чисталык, пөхтәлек, үзара ярдәм, яхшылыкка омтылу теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** магнитлар, тимер гайкалар һәм борчак салынган банка, пластмассадан ясалган савытлар, соскы, юеш сөлге.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, кулга-кул тотынышып басыгыз! Әйдәгез, башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып: “Хәерле иртә!” – телибез. (Балалар кабатлыйлар.) Балалар, сез әкиятләр яратасызмы? (Балаларның җаваплары.) Бик күп әкиятләрдә хайваннар, кошлар төп геройлар булып торалар. Алар кешеләр кебек үк сөйләшәләр, көләләр, бер-берсенә булышалар, кайчакта хәйләлиләр, усалланалар, бер-берсен алдалыйлар. Әкиятләр сезне нәрсәгә өйрәтә? *(Бер-береңә ярдәм итәргә, бер-береңә карата яхшы, гадел, тугрылыклы булырга, бәладән ничек котылырга, бик күп матур гадәтләргә өйрәтәләр.)* Балалар, бүген мин сезгә бер әкият укырмын. Әкият бер җәнлек һәм бер кош турында. Нинди җәнлек һәм нинди кош турында икән ул? Табышмаклар әйтәм, җавабын тапсагыз белерсез. Кош турындагы табышмакны игътибар белән тыңлагыз:

Борыны озын, боты озын,
Камышлыкта көнозын.
Сазлык җирләрдә йөри,
“Тату торыйк”, – дип сөйли. *(Торна.)*

Хәзер җәнлек турындагы табышмакны тыңлагыз:

Үзе ялагай, үзе хәйләкәр.
Ул нәрсә булыр,
Йә, әйтеп җибәр. *(Төлке.)*

Балалар, димәк, әкият нәрсә турында булачак? (*Торна белән Төлке турында.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, әкиятнең дә исеме “Торна белән Төлке”. Тыңлап карагыз әле! (Тәрбияче әкиятне укый.) (Тәрбияче әкиятнең эчтәлеге буенча балаларга сораулар бирә.) Балалар, әкиятнең исемен әйтегез әле, исегездә калдымы? *(Торна белән Төлке.)* Әйе, димәк әкияттә нәрсәләр катнаша*? (Торна белән Төлке.)* Төлке нәрсәне кунакка чакырган? *(Торнаны.)* Төлке Торна килүгә нәрсә пешергән? *(Ботка*.) Ботканы нәрсәгә салган? *(Тәлинкәгә.)* Төлке Торнаны ничек кыстаган? *(“Аша, дустым, аша*, *иркәм! Үзем пешердем”, – дигән.)* Әйдәгез, Төлкенең Торнага әйткән кыстау сүзләрен бергәләп кабатлагыз! (Балалар кабатлыйлар.) Торна ботканы ашый алганмы? *(Юк.)* Ни өчен? *(Торнаның борыны озын, ә тәлинкә сай. Шуңа күрә авызына ботка эләкмәгән.)* Тәлинкәдә ботка калганмы? *(Юк.)* Торна ашый алмаган бит, ботка кая киткән соң? (*Төлке үзе ашап бетергән.)* Торна кайтып киткәндә, Төлкегә нәрсә дигән? (*Торна Төлкене үзенә кунакка чакырган.)* Төлке Торнаны нәрсә белән сыйлаган? *(Борчак белән сыйлаган.)* (Балаларны активлаштыру.) Борчакны нинди савытка салган? *(Тар муенлы озын чүлмәккә салган.)* (Балаларны активлаштыру.) Төлке ашый алганмы? *(Юк*.) Ни өчен? *(Тар муенлы озын чүлмәккә аның авызы сыймаган.)* Чүлмәктә борчак калганмы? *(Юк.)* Борчак кая киткән? *(Борчакны төлке үзе ашап бетергән.)* (Балаларны активлаштыру.) Төлке ашамагач, нинди хәлдә

калган? *(Ач калган.)* Төлке нишләгән? *(Өенә кайтып киткән.)* Шуннан соң Торна белән Төлке арасында нәрсә булган? *(Аларның дуслыгы беткән.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ничек уйлыйсыз, Төлке белән Торна дөрес эшләгәннәрме*? (Юк.)* Ни өчен Торна да, Төлке дә үзләренә килгән кунакны сыйлый алмаганнар? Аларның нинди начар гадәте булган? *(Алар саран булганнар.)* Дөрес, балалар, саранлык – начар гадәт. Һәрчак юмарт булырга, дусларыңнан сый-хөрмәтеңне кызганмаска кирәк. "Торна белән Төлке" әкияте юмарт булырга өйрәтә. Сез дә үзегездә шушы сыйфатны булдырырга тырышыгыз! Балалар, Торна белән Төлке бик дуслашырга телиләр дә, ләкин бер-берсен кунакка чакырырга борчаклары юк икән. Торна белән Төлкегә булышабызмы? *(Әйе.)* Менә миндә бер савыт бар. Савытның эченә нәрсә салганнар? (Күрсәтә.) *(Борчак.)* Балалар, савытка борчак кына салмаганнар, тимер гайкалар да тутырганнар. Әйдәгез, тимер гайкаларны аерып алабыз да борчакны Торна белән Төлкегә бирәбез. Ничек итеп тимер гайкаларны борчак арасыннан аерып була икән? (Балаларның җаваплары. Алар үз фикерләрен әйтәләр. Магнит кулланырга кирәк дигән фикергә киләләр.) Балалар, кем белә, нәрсә соң ул магнит? *(Ул тимер әйберләрне үзенә тарта, үзенә ябыштыра.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, балалар, менә шундый кызыклы әйбер ул магнит. Торна белән Төлкегә булышабызмы? Сез аларның дуслашуын телисезме? Әйдәгез, эксперимент үткәреп карыйбыз. Менә бу пластмассадан ясалган буш тәлинкәгә тимер гайкаларны салыгыз. Чиста, пөхтә итеп эшләргә тырышыгыз. Борчакларны идәнгә коймагыз!

Тәрбияче өстәл уртасына тәлинкә куя. Һәр балага гайкалар һәм борчак бутап салынган савытлар бирелә. Магнитлар таратыла.

Тәрбияче. Менә, балалар, күрәсезме! Бергә эшләгәндә эш тиз бетә. Эшләве дә күңелле. Торна белән Төлкегә дә булыштыгыз. Аларга булышканда, үзегез дә күп нәрсәгә өйрәндегез – магнит белән таныштыгыз. Борчак эченнән гайкаларны аерып алып, борчакны чистарттыгыз. Торна белән

Төлке дә дуслашачак. Балалар, Торна белән Төлкегә булышкач, сезгә күңелле булдымы? (Балаларның җаваплары.) (Балаларны активлаштыру.) Булдырдыгыз, балалар! Чиста, пөхтә итеп эшләдегез! Эш беткәч, уйнарга ярый!

## *Унынчы бүлек.*
## ЯЗ

### Тема: К. УШИНСКИЙНЫҢ “ХАЙВАННАР БӘХӘСЕ” ӘСӘРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларның сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту; сюжетның эзлеклелеген истә калдырырга ярдәм итү; әсәрне игътибар белән аңлап тыңларга өйрәтүне дәвам итү; балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү;

2) балаларның эмоциональ сферасын, тип-тап-тап, тип-тап-тап, пух-пах-пах, ах-ох-ух, пу-ту-ту, у-у-у, чаң-чаң-чаң, дың-дың-дың, пуф-пуф-пуф, уф-уф-уф аваз ияртемнәре хисабына авазларның дөрес әйтелешен камилләштерү, үстерү;

3) балаларда нәфис сүзгә мәхәббәт, йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** “Балачак аланы”: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия, 111 бит (авторы – К. В. Закирова), А3 форматында бакча сукалаучы ат, яшел үлән ашап йөрүче сыер, йорт саклаучы эт сурәтләнгән сюжетлы картина.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. (Балаларны тәрәзә янына чакыра.) Балалар, карагыз әле урамга, хәзер елның кайсы вакыты? *(Яз.)* (Балаларны активлаштыру.) Яз көне табигатьтә нинди үзгәрешләр була? *(Кояш җирне җылыта, кар эри, чәчәкләр*

*чыга.)* (Балаларны активлаштыру.) Әйе, җирдә кар эреп беткәч, язгы эшләр башлана. Тәрәзәгә карагыз әле, урам себерүчеләр нишли? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, урамнарны кышкы пычраклардан чистарталар. (Ишек шакыган тавыш ишетелә.) Балалар, кем икән ул? (Тәрбияче ишекне барып карый.) Балалар, безгә Хат ташучы Яздан посылка алып килгән, ачып карыйк әле. Карагыз әле, нинди матур картина! Бу картинада нәрсәләр күрәсез? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, бу авыл бакчасы. Бу нәрсә? *(Ат.)* (Балаларны активлаштыру.) Ул нәрсә эшли? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Балалар, ул җир сукалый, шулай итеп җирне яшелчәләр, бәрәңге утыртырга әзерли. Ә бу нәрсә? *(Сыер.)* Ул нишли? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, инде яшел үлән үсә башлаган, сөте күп, тәмле булсын өчен, сыер яшел үлән ашарга чыккан. Балалар, ә бу нәрсә? *(Эт.)* Ул нишли? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Дөрес, ул йорт саклый. Балалар, ат, сыер, этне бер сүз белән ничек атыйлар? *(Йорт хайваннары.)* (Балаларны активлаштыру.) Алар кешеләргә файда китерәме, ярдәм итәләрме икән. Мин сезгә шул турыда Константин Ушинский язган “Хайваннар бәхәсе” әсәрен укырмын. Башта уйнап алырбыз. Без поезд булып, бер-бер артлы тотынышып басып, “авылга кайтып килик”.

Алга таба барабыз тип-тап-тап, тип-тап-тап,
Гөрләп чаба паровоз тип-тап-тап, тип-тап,тап,
Ак төтен артта кала пух-пах-пах, пух-пах-пах,
Вагоннар җырлап чаба ах-ох-ух, ах-ох-ух!
Сыбызгы яңгырап китә пу-ту-ту, пу-ту-ту,
Тавыш еракка китә у-у-у, у-у-у,
Бик күп җирләрне үттек чаң-чаң-чаң, чаң-чаң-чаң,
Урманга да без җиттек дың-дың-дың, дың-дың-дың.
Зур паровоз уфылдый пуф-пуф-пуф, пуф-пуф-пуф.
Бүген бик арыдың ди уф-уф-уф, уф-уф-уф.

Менә, балалар, без килеп җиттек. Булдырдыгыз! Хәзер әсәрне укыйм, игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче әсәрне укый.) Менә шундый хәлләр булган. Балалар, сыер, ат һәм эт нәрсә дип бәхәсләшкәннәр? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Атны хуҗа ни өчен ярата? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Әйе, ул җир сукалый, тырмалый, урманнан утын ташый. Ә сыерны ни өчен ярата? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) (Балаларны активлаштыру.) Эт нәрсә ди? *(Мин аның йортын саклыйм.)* (Балаларны активлаштыру.) Бу бәхәсне кем ишеткән? *(Хуҗа.)* (Балаларны активлаштыру.) Хуҗа аларга әйткән: "Юкка бәхәсләшеп тормагыз, сезнең барыгыз да миңа кирәк, сезнең һәрберегез үз урынында яхшы". Балалар, ат та, сыер да, эт тә кешегә кирәк, алар һәрберсе үзенчә файда китерә. Бу йорт хайваннары яз көне генә түгел, ә елның теләсә кайсы фасылында кешеләргә ярдәм итә. Аларны яратырга, сакларга, алар турында кайгыртырга кирәк.

## *Унберенче бүлек.*
## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

### Тема: Ә. РӘШИТНЕҢ "КОЯШЛЫ ИЛ" ДИГӘН ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ

**Бурычлар:**

1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга булышу; сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү; кайбер сүзләрнең (ашлык, кыр, күк, аяз) мәгънәсен аңлату, бер-береңнең индивидуаль үзенчәлекләрен күрергә өйрәтү;

2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, ишетү хәтерен, иптәшең турында сөйләү теләген үстерү;

3) Туган илгә патриотлыкк хисләре, шигърияткә мәхәббәт һәм бер-берсенә карата ягымлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ашлык үсеп утырган кыр рәсеме, язгы чәчәкләр төшкән рәсем, агач ботагында сандугач сайрап утырган рәсем, җәй, кыш сурәтләре.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, без яшәгән республика ничек атала? *(Татарстан.)* (Балаларны активлаштыру.) Татарстанда шәһәрләр, авыллар бар. Без сезнең белән шәһәрдә яшибез. Без нинди шәһәрдә яшибез? *(Яр Чаллы.)* (Балаларны активлаштыру.) Безнең республикабыз, шәһәребез бик матур, чиста. Балалар бәхетле булсын дип, әби-бабаларыбыз тырышкан, сугышта дошманнарны җиңгәннәр, яңа шәһәрләр төзегәннәр, кырда-басуда эшләгәннәр. Без хәзер бәхетле илдә яшибез. Безнең илебез турында Әхмәт абый Рәшит “Кояшлы ил” дигән шигырь язган. Тыңлагыз әле:

Кояшлы ил – безнең ил, күге аның гел аяз.
Кыш китерсә Кыш бабай, чәчәк алып килә яз.
Сандугачлы урманы, ашлык тулы кырлары,
Бөтен җирдә яңгырый безнең бәхет җырлары.
Һавасы да, җире дә, салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да – безгә якын бары да...

Балалар, Әхмәт абый безнең илне нинди ил дип атый? *(Кояшлы ил.)* (Балаларны активлаштыру.) Тәрәзәдән һавага, күккә карагыз әле. Күк нинди? *(Күк аяз.)* (Балаларны активлаштыру.) Аяз сүзен тагын ничек дип әйтергә була? *(Ачык, болытлар юк.)* Хәзер нинди ел вакыты? *(Яз.)* (Балаларны активлаштыру.) Яз безгә нәрсә алып килә? *(Чәчәкләр.)* Карагыз әле, язын менә нинди чәчәкләр үсеп чыга. (Тәрбияче чәчәкләр төшкән рәсем күрсәтә: тузганак, лалә, нәркис.) (Балаларны активлаштыру.) Урманда нәрсәләр сайрый? *(Сандугачлар.)* (Тәрбияче сандугач рәсеме күрсәтә. Сандугачлар җырын да тыңларга була.) Балалар, менә бу кырлар (Күрсәтә.) Кырларда ашлык өлгерә. Әйдәгез бергәләп

кабатлыйк әле: кырларда ашлык өлгерә. Балалар, Әхмәт абый болай дип яза: “Бөтен җирдә яңгырый безнең бәхет җырлары”. Әйе, кеше бәхетле булса, җырларга ярата. Шигырьне ул мондый сүзләр белән тәмамлый:

Һавасы да, җире дә, салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да – безгә якын бары да...”

Туган илен яраткан кеше өчен бөтен нәрсә якын. Һава да, җир дә, салават күпере дә, яңгыр да, кар да. (Тәрбияче мольбертка ике рәсем куя: берсе – җәйне, икенчесе кышны сурәтли.) Әйе, без җылы җәйләрне дә, салкын кышларны да, ямьле язларны да бик яратабыз.

Балалар, мин шигырьне укып чыгам, сез игътибар белән тыңлагыз. Аннан соң шигырьне үзегез яттан сөйләрсез. (Тәрбияче шигырьне ике кат укый.) Кем шигырьне истә калдырды? (Хәтере яхшы булган балаларны тәрбияче беренче итеп чакыра, аларның сөйләвен бәяли.) Булдырдыгыз. Кем истә калдыра алмады, саф һавага чыккач өйрәнеп бетерербез.

Хәзер уйнап алырбыз. Сез язгы чәчәкләр булырсыз. Яшел үлән өстенә җайлап утырыгыз. Сезгә карап кояш елмая. Хәзер басыгыз һәм менә шулай, (*күрсәтә*) бармакларыгызны җәеп, кулларыгызны өскә – кояшка күтәрегез. Кояш чыкты, чәчәкләр кояшка карыйлар, аның җылысын тоялар. *(Балалар кояшка таба үреләләр.)* Кояш йоклый, чәчәкләр дә йоклый. *(Чүгәлиләр, кулларны аска төшерәләр. Уен 2–3 тапкыр кабатлана.)* Мин сезгә кояшлы көннәр генә телим.

“Ягымлы сүзләр ” дигән уен уйнарбыз. Түгәрәк ясап, җитәкләшеп, уңайлы итеп келәм өстенә утырыгыз. Бер бала каршына килеп, аның күзенә карап, аңа матур сүзләр әйтегез. Сезне тыңлап торган бала, сезнең белән килешеп, башын кага һәм болай дип әйтә: “Рәхмәт. Миңа бу сүзләрне ишетү бик күңелле”. Әйдәгез мин башлыйм. (Тәрбияче сөйләм үрнәге күрсәтә.) Булат, син бүген бик актив булдың. Гөлләргә суны тырышып сиптең. Булат, син нәрсә дип җавап кайтарасың? (Булатның җавабы.)

Уен күнегүе түгәрәк буенча дәвам итә. Әгәр бала авырсынса, тәрбияче аңа мактау сүзләре табарга булыша.

## Тема: “ТАВЫК, ТЫЧКАН, КӨРТЛЕК” ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ

**Бурычлар:**

1) балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга булышу; персонажларның гамәлләрен анализлау сәләтен формалаштыру; чикләнгән территориядә бер-береңә бәрелмичә йөгерүдә күнектерү;

2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, конкрет-образлы фикерләвен, физик сыйфатларын (тизлек, көч) үстерү;

3) татар халык әкиятләренә, уңай геройларга карата уңай мөнәсәбәт һәм уенның кагыйдәләрен үтәү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** коврограф (мольберт), тавык, тычкан, көртлек рәсемнәре, арпа рәсеме, тегермән рәсеме, ипи савытлары сурәтләнгән рәсемнәр, төлке битлеге, ипи төрелгән сөлге.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, минем яныма килегез әле. Мин сезгә бер орлык күрсәтәм. Бу арпа орлыгы. Ул нинди? *(Кечкенә, озынча түгәрәк, аксыл төстә, каты.)* (Балаларны активлаштыру.) Арпа орлыгыннан ипи пешерәләр. Телисезме, арпа орлыгы турында мин сезгә бер әкият сөйлим. Бу татар халык әкияте “Тавык, Тычкан һәм Көртлек” дип атала. Уңайлы итеп утырыгыз. (Тәрбияче әкиятне сөйли, персонажларның гамәлләрен коврографта күрсәтә бара.) Балалар, әкияттә нинди җәнлекләр һәм кошлар турында сүз бара? *(Тавык, тычкан, көртлек.)* (Балаларны активлаштыру.) Мин аларның рәсемнәрен күрсәтәм, карагыз әле. Бу нәрсә? *(Тавык.)* Тавык кайда яши? *(Ишек алдында, сарайда, кеше хуҗалыгында.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес әйтәсез, тавык – йорт кошы,

ул кеше хуҗалыгында яши, арпа чүпли, йомырка сала. Бу нәрсә? *(Тычкан.)* Тычкан кайда яши? *(Кырларда, кеше хуҗалыгында, амбарда.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес әйтәсез, тычкан – кыргый җәнлек, ул кеше туплаган азыкны кимерә, ярмаларны ашый, кешегә зыян сала. Бу нәрсә? *(Көртлек.)* Балалар, көртлекне башкача кыр тавыгы диләр. Көртлек, яисә кыр тавыгы, кайда яши? *(Кырларда.)* (Балаларны активлаштыру.) Дөрес әйтәсез, көртлек – кыр кошы, ул кырда булган ризыкны чүпли, шуның белән туклана. (Тәрбияче кошларның һәм тычканның рәсемен коврографка куя.) Бервакыт Тавык нәрсә тапкан? *(Арпа бөртеге.)* (Балаларны активлаштыру.) (Арпа бөртеге рәсемен дә коврографка куя.) Тавык нәрсә дигән? (Балаларның җаваплары.) Дөрес әйтәсез: "Арпа таптым, арпа таптым, аны тарттырырга кирәк. Кем аны тегермәнгә алып бара?" – дип сораган Тавык. (Тәрбияче коврографка тегермән рәсемен куя.) Тычкан белән Көртлек нәрсә дип җавап биргәннәр? (Балаларның җаваплары.) "Кем онны өйгә алып кайта?" – дип сорады Тавык. Ул нинди җавап ишетте? (Балаларның җаваплары.) "Мин алып кайтмыйм, мин дә алып кайтмыйм", – дип әйттеләр Тычкан белән Көртлек. Тавык онны тегермәннән алып кайткач, нәрсә эшләде? (Балаларның җаваплары.) Дөрес, ипи изде. (Тәрбияче ипи савытлары сурәтләнгән рәсемне коврографка куя.) Тычкан белән Көртлек аңа булыштымы? (Балаларның җаваплары.) Балалар, аннан соң Тавык нәрсә эшләде? (Балаларның җаваплары.) (Мич сурәтләнгән рәсемне коврографка куя.) Әйе, Тавык мичкә якты, ипиләрне мичкә куйды. Ипиләр нинди булып пештеләр? (Балаларның җаваплары.) Ипиләр уңдылар, кабарып, кызарып пештеләр. Тычкан белән Көртлек өстәл артына утырдылар. Балалар, Тавык аларга ипине бирер микән, ничек уйлыйсыз? (Балаларның җаваплары.) Минемчә, Тавык аларга ипине бирмәс, чөнки Тычкан белән Көртлек бернәрсә дә эшләмәделәр. Татар халкында мәкаль бар: кем эшләми, шул ашамый.

Ял итеп алыйк. "Төлке һәм тавыклар" дигән татар халык уенын уйнарбыз. Игътибар белән тыңлагыз. Бүлмәнең бер

ягында тавык кетәгендә тавыклар һәм әтәчләр яши. Бүлмәнең икенче ягында – Төлке. Тавыклар һәм Әтәчләр ишегалдында ярма чүплиләр. Көтмәгәндә алар янына Төлке килеп чыга. Төлкене күрүгә, Әтәчләр канатлары белән кагыналар, "кикри-кү-ү-к" дип кычкыралар. Бу сигналны ишетүгә, Тавыклар өйләренә йөгерәләр. Төлке кемне дә булса тотып алырга тырыша. Әгәр дә тотса, өенә алып китә, тотмаса, яңадан төлке була. (Уен 2–3 тапкыр кабатлана.) Булдырдыгыз.

Балалар, мин әкиятне тагын бер тапкыр укыйм, сез тыңлагыз. (Тәрбияче әкиятне укый.)

Балалар, ипине үстерү бик авыр хезмәт. Ипи ашасаң, тук буласың. Элек, сугыш барган вакытта, ипи бик аз булган, аны кисәкләргә бүлеп биргәннәр, кешеләр туйганчы ипи ашый алмаганнар. Чөнки немецлар кырларны, басуларны яндырганнар, кешеләр ашлыкны аз җыеп алганнар. Шуңа күрә ипинең бер валчыгын да әрәм итмәгәннәр. Ипине сөлгегә салып кискәннәр, бик саклаганнар. (Күрсәтә.) Ипи бик кадерле, шуңа күрә биргән кисәкне ашап бетерергә кирәк.

## *Уникенче бүлек.*
## ҖӘЙ

### Тема: "КҮБӘЛӘКЛӘР НИЧЕК КИЛЕП ЧЫККАН?" ФИЛИППИН ХАЛЫК ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) әкиятнең эчтәлеген кабул итәргә һәм аңларга өйрәтү; җәй турындагы белемнәрен ныгыту;

2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, сүзлек байлыгын, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) әкиятләргә кызыксыну, чәчәкләргә, күбәләкләргә сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** табигать тавышлары (бал кортлары безелди, кәккүк кычкыра, кошлар сайрый, чишмә ага) язылган аудиоязма, татар халык бию көе язылган аудиоязма, бамбук агачы рәсеме.

## Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар, әйдәгез, табигать турында сөйләшик. Нәрсә ул табигать? *(Табигать – ул елга, урман, үсемлекләр, кошлар, хайваннар һ. б.)* Бик дөрес, балалар! Әйдәгез, табигать тавышларын тыңлагыз! (Аудиоязма.) Нинди тавышлар ишеттегез? *(Бал корты безелди. Кәккүк кычкыра. Кошлар сайрый. Чишмә аккан тавыш ишетелә.)* Әйе, балалар, тавышларга бик сизгер, игътибарлы икәнсез. Барлык табигать тавышларын да ишетәсез. Балалар, табигатьтә бу тавышларны елның кайсы вакытында ишетергә була? *(Җәй көне.)* Дөрес, җәй көне. Елның кайсы вакыты якынлаша? *(Җәй.)* Җәй көне табигатьтә нинди үзгәрешләр була, җәй билгеләрен атагыз әле! *(Кояш нык кыздыра, кызынырга, су коенырга була, урманда җиләкләр, гөмбәләр өлгерә, чәчәкләр күп була.)* (Балаларны активлаштыру.) Ә бөҗәкләр турында нәрсә әйтергә була? Җәй көне нинди бөҗәкләр күргәнегез бар? *(Бал корты, чебен, черки, шөпшә, чикерткә, май коңгызы, чуар таракан, суалчан.)* Җәй көне бик күп бөҗәкләр күргәнегез бар икән. Бүген без сезнең белән бер бик матур бөҗәк турында әкият укырбыз. Нәрсә турында икән? Мин сезгә табышмак әйтәм, ә сез җавабын тапсагыз белерсез.

Чәчәкләрдән чәчәкләргә
Көнозын оча-куна
Нектар белән тамак ялгап,
Чыклар белән юына.

Нәрсә соң бу, балалар? *(Күбәләк.)* Бик дөрес, күбәләк. Нәрсә ул нектар? *(Үсемлекләр бүлеп чыгара торган татлы, баллы сыекча, чәчәк балы.)* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: нектар. (Кабатлыйлар.) Нектарны тагын нинди бөҗәкләр эчә?

*(Бал корты.)* Әйе, алар да, чәчәктән чәчәккә кунып, нектар җыялар. Мин сезгә “Күбәләкләр ничек килеп чыккан?” исемле филиппин халык әкиятен укыйм. Игътибар белән тыңлагыз!

Тәрбияче әкият укый. Эчтәлеге буенча фикер алышалар.

Тәрбияче. Әкияттә елның кайсы вакыты турында сүз бара? *(Җәй.)* (Балаларны активлаштыру.) Нинди билгеләр буенча җәй дип әйтергә мөмкин? *(Бакчада чәчәкләр үскән.)* Бу бакча башка бакчалардан нәрсә белән аерылып торган? *(Бу бакчада үскән чәчәкләр башка җирдә үсмәгән.)* Әйе, мондагы гаҗәеп чәчәкләр җир йөзендә башка булмаган. Балалар, гаҗәеп сүзе нәрсәне аңлата? Башка сүзләр белән бу сүзне ничек әйтергә була? *(Искиткеч, сокланырлык, таң калдырырлык.)* Бакча хуҗасы нинди кеше булган? *(Киң күңелле, юмарт.)* (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен аны киң күңелле, юмарт дип була? *(Ул кешеләргә чәчәкләр бүләк итәргә яраткан.)* (Балаларны активлаштыру.) Бакча хуҗасының ни өчен ачуы чыккан? *(Бакчага чит кешеләр, кереп, чәчәкләрне өзә башлаганнар.)* (Балаларны активлаштыру.) Ни өчен бакча хуҗасын тылсымчы дип әйтеп була? *(Ул кешеләрне күбәләкләргә әверелдергән.)* Тылсымчыга моның өчен нинди предмет ярдәм иткән? *(Бамбук таягы.)* Балалар, нәрсә соң ул бамбук? *(Агач.)* Әйе, җылы якта үсә торган буын-буын куыш сабаклы агачсыман үсемлек. (Тәрбияче бамбук агачы рәсемен күрсәтә.) Менә ул бамбук агачы. Балалар, ни өчен соң тылсымчы кешеләрне күбәләкләргә әйләндергән? *(Ул кешеләрнең чәчәкләрне өзүен теләмәгән.)* (Балаларны активлаштыру.) Балалар, менә күрдегезме, күбәләкләр ничек килеп чыккан? Балалар, сезгә әкият ошадымы? (Балаларның җаваплары.) Сез әкияттән нәрсә аңладыгыз? *(Чәчәкләрне өзәргә ярамый.)* Мин сезнең белән килешәм. Чәчәкләрне үстерер өчен күп көч кирәк. Нәрсә эшләргә кирәк соң? *(Җирне казырга, түтәл ясарга, су сибәргә, орлыкларны чәчәргә, аларны җир белән күмәргә һәм тагын су сибәргә кирәк.)* (Балаларны активлаштыру.) Чәчәкләр үсә башлагач та, аларны

тәрбияләп торалар, чүбен утыйлар, төпләрен йомшарталар, су сибәләр. Яратып караганда гына, чәчәкләр бик матур була. Матур чәчәкләргә күбәләкләр куна. Күбәләкләрне дә, чәчәкләрне дә яратырга, сакларга, алар турында кайгыртырга кирәк. Чәчәкләр дә, күбәләкләр дә безне сөендерсеннәр. Аларның матурлыгы безне соклandyрсын! Әйдәгез, биеп алыйк әле.

Бергәләп басыйк әле *(басалар),*
Түгәрәк ясыйк әле *(түгәрәк ясыйлар).*
Менә нинди түгәрәк!
Әйтерсең лә күбәләк *(күбәләк шикелле канат кагалар).*
Тыпыр-тыпыр тыпырдыйбыз *(тыпырдыйлар),*
Бер дә карап тормыйбыз.
Менә шулай ял итәбез,
Бик тырышып биибез *(татар халык биюе бииләр).*

# УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕНДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮЗЛӘШТЕРҮ ДӘРӘҖӘЛӘРЕНӘ ДИАГНОСТИКА

## Диагностика: биремнәр, методикалар

### Сүзлек өстендә эш

**1 нче бирем**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүзлек | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сүзнең мәгънәсен белү | Билгене белдерә торган сүзләр | Хәрәкәтне белдерә торган сүзләр | Гомумиләштерүче сүзләр куллану | Предметның исемен һәм нинди материалдан булуын атау | Предметларны чагыштыру | Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр | Күпмәгънәле сүзләр |
| 1 | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | |

### “Курчак турында сөйлә” диагностик биреме

**1. “Әйтегез әле, нәрсә ул курчак” күнегүе**

– Билгеләмә бирә. *(Курчак ул – уенчык, курчак белән уйныйлар.)*

– Аерым билгеләрен, хәрәкәтләрен белдерә торган сүзләрне әйтә. *(Курчак матур. Ул басып тора.)*

– Биремне үтәми , “курчак” сүзен кабатлый.

**2. “Курчак нинди кием кигән?” күнегүе**

– Дүрттән артык сүз әйтә.

– Икедән артыграк киемне әйтә.

– Әйтмичә генә күрсәтә.

**3. “Курчакка, ул йөгерсен, кулын селтәсен өчен, бирем бир” күнегүе**

– Дөрес формалар бирә. (*Алсу, йөгер әле. Алсу, кулыңны селтә әле.*)

– Фигыльләрне генә әйтә. (*Йөгер. Селтә.*)

– Дөрес булмаган форма бирә.

**4. “Курчакка кунаклар килде. Өстәлгә нәрсәләр куярга кирәк?” күнегүе**

– “Савыт-саба” сүзен әйтә.

– Савыт-сабаның аерым предметларын әйтә.

– Бер предмет әйтә.

**5. “Нинди савыт-сабалар беләсең?” күнегүе.**

– Дүрттән артык предметны атый.

– Ике предметны атый.

– Бер предметны атый.

**6. “Нәрсәдән ясалганын әйт?” күнегүе**

Тәрбияче балага көнкүрештә кулланыла торган савыт-саба предметлары күрсәтә: пыяла стакан, тимер кәстрүл, агач кашык, пластмасса савыт. Тәрбияче әйтә: “Кунаклар курчакка бүләкләр алып килгәннәр. Кайсы предмет нәрсәдән ясалганын әйт”.

– Барлык предметларны атый һәм аларның нинди материалдан ясалганын әйтә.

– Ике предметны атый.

– Атамыйча гына күрсәтә.

**7. “Предметлар нәрсә белән аерылалар?” күнегүе**

Тәрбияче төрле савыт-саба ясалган рәсемнәр күрсәтә.

– Төсе (формасы, зурлыгы) буенча атый.

– Аерым билгеләрен саный. *(Бу чынаяк – яшел, бу – кызыл, бу – биек.)*

– Бер аермалыгын атый.

**8. “Сүзне әйтеп җибәр” күнегүе**

Бу тәлинкә тирән, ә монысы... *(сай)*, бер стакан биек, ә икенчесе... *(тәбәнәк),* бу чынаяк чиста, ә монысы... *(пычрак).*

– Барлык сүзләрне дә дөрес таба.
– Ике биремне үти.
– Бер биремне үти.

**9. “Чынаякның тоткычы бар. Тагын нәрсәләрнең тоткычлары була?” күнегүе**

– Өч-дүрт предметның тоткычын атый. *(Чәйнекнең, үтүкнең, сумканың, кулчатырның.)*
– Ике предметны атый. *(Кәстрүлнең, табаның.)*
– Чынаякның тоткычын күрсәтә.

**2 нче бирем**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүзлек | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Сүзнең мәгънәсен аңлау | Предметларны чагыштыру | Гомумиләштерүче сүзләрне куллану |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

### “Туп турында сөйлә” диагностик биреме

Тәрбияче ике туп күрсәтә һәм балага түбәндәге сораулар бирә:

**1. “Нәрсә ул туп?” күнегүе**

– Билгеләмә бирә. *(Туп ул – уенчык. Ул түгәрәк, резинадан ясалган.)*
– Нинди дә булса билгесен әйтә.
– “Туп” сүзен кабатлый.

**2. “Нәрсә ул ыргыту, тоту” күнегүе**

– Аңлата белә. *(Ыргыту ул – кемгә дә булса тупны ата, ә икенчесе аны тота.)*
– “Ыргыттым” дип, хәрәкәтне күрсәтә (тупны төбәп ата.)
– Хәрәкәтне күрсәтә (сүзләр әйтми.)

**3. “Ике тупны чагыштыр. Алар нәрсә белән аерылалар һәм нәрсә белән охшаш?” күнегүе**

– Билгеләрен атый. *(Икесе дә түгәрәк, резинадан ясалган; туплар белән уйныйлар.)*

– Төс буенча булган аермасын гына атый.

– Бер сүз әйтә.

**4. “Син нинди уенчыклар беләсең?” күнегүе**

– Дүрттән күбрәк уенчыкны атый.

– Икедән күбрәк уенчыкны атый.

– Бер сүз әйтә.

**5. “Күлмәк, чалбар, кофта; чынаяк, кәстрүл, таба сүзләрен бер сүз белән ничек атарга?” күнегүе**

– Гомумиләштерүче сүзне атый һәм сәбәбен күрсәтә. *(Күлмәк, чалбар, кофта –* ***кием****. Аларны өскә кияләр. Чынаяк, кәстрүл, таба –* ***савыт-саба****, анда ашарга пешерәләр һәм аннан ашыйлар.)*

– Гомумиләштерүче сүзне атый. *(Күлмәк, чалбар, кофта –* ***кием****. Чынаяк, кәстрүл, таба –* ***савыт-саба****.)*

– Гомумиләштерүче сүзне атамый.

## Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру

**3 нче бирем**

| **№** | **Баланың исеме, фамилиясе** | **Сүзлек** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **Сүзнең мәгънәсен аңлау** | **Мәгънәсе буенча капма-каршы сүзләр** | **Хәрәкәтне белдерүче сүзләр** | **Этне һәм көчекне чагыштыру** |
| **1** | | | | | |
| **2** | | | | | |

## “Эт һәм көчекләр” сюжетлы картинасын карау” диагностик биреме

**1. “Синең эт күргәнең бармы? Нәрсә ул эт? Ул нинди?” күнегүе**

– Гомумиләштерә. *(Эт ул – хайван; эт өрә. Ул йонлач.)*

– Атый. *(Бу эт. Ул кара.)*

– Тәрбияче артыннан бер генә сүзне кабатлый.

**2. “Эт балаларын ничек атыйлар? Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне дөрес әйтегез” күнегүе**

– Эт тиз йөгерә, ә көчекләр... *(әкрен).*

– Этнең тавышы калын, ә көчекләрнеке ... *(нечкә).*

– Эт баласын дөрес атый, җөмләне тәмамлый.

– Эт баласын “көчек” дип атый.

– Бер сүз генә әйтә.

**3. “Эт нәрсә эшли белә?” күнегүе**

– Өч-дүрт хәрәкәт атый. *(Өрә, йөгерә, сөяк кимерә. Әгәр дә эт, песи күрсә, өрә һәм артыннан чаба.)*

– Ике хәрәкәт атый.

– Бер сүз генә әйтә.

**4. “Этне һәм көчекне чагыштыр. Алар нәрсә белән охшаш һәм нәрсә белән аерылалар” күнегүе**

– Эт һәм көчек турында сөйли. *(Эт зур һәм йонлач, көчек кечкенә һәм йомшак.)*

– Биремне тәрбияче ярдәме белән үти.

– Бер аермалыгын әйтә.

## Сөйләмнең аваз культурасы

**4 нче бирем**

| **№** | **Баланың исеме, фамилиясе** | **Авазлар әйтелешен тикшерү** | **Тавышның көче, сөйләм тизлеге, дикция, сөйләмнең интонацион сәнгатьлелеге** |
|---|---|---|---|
| **1** | | | |
| **2** | | | |

### “Сөйләмнең аваз ягын билгеләү” диагностик биреме

**1. “Шар, тун, коңгыз, куян, балык, трамвай, лампа, көрәк сурәтләнгән картинкалар күрсәтү” күнегүе**

Тәрбияче балага картинкада нәрсә сурәтләнгәнен атарга куша. Тәрбияче бала әйтә алмаган авазларны билгели.

– Барлык авазларны да әйтә.

– Сонор һәм чыжылдаучы кебек катлаулы авазларны әйтә алмый.

– Сонор авазларны да һәм чыжылдаучы авазларны да әйтә алмый.

**2. "Үзеңә таныш булган юаткычны тиз, әкрен, тыныч һәм кычкырып әйт" күнегүе**

– Текстны ачык итеп әйтә.

– Ачык итеп әйтми, тавышның көчен дөрес көйләми.

– Текст әйтелешендә җитди кимчелекләр бар.

**Бәйләнешле сөйләм телен үстерү**

**5 нче бирем**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Күрсәтмәлелек кулланып, предметны тасвирлау | | | Шәхси тәҗрибәдән чыгып сөйләү | Әкияттнең эчтәлеген сөйләү |
| | | Курчакны тасвирлау | тупны тасвирлау | этне тасвирлау | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

**"Хикәяләү (тасвирлау һәм сюжетлы хикәяләү) һәм эчтәлек сөйләүне билгеләү" диагностик биреме**

**1. "Курчакны тасвирла" күнегүе**

Тәрбияче курчакны күрсәтә.

– Курчак нинди, аның белән нәрсә эшләргә була, аның белән ничек уйныйлар? Шул турыда сөйлә.

– Курчакны мөстәкыйль тасвирлый. *(Бу курчак. Ул матур. Аның исеме Алсу. Курчак белән уйнарга була. Яки: Бу курчак. Аның исеме Алсу. Курчакның чәчләре озын. Күлмәге кызыл. Курчак белән уйнарга була.)*

– Педагог ярдәме белән сөйли.

– Җөмлә төземичә генә аерым сүзләр әйтә.

**2. “Туп турында сөйлә” күнегүе**

– Ул нинди, ни өчен кирәк, аның белән нәрсә эшләргә була.

– Тасвирлый. *(Бу – туп. Ул түгәрәк, зур, кечкенә, резинадан ясалган, кызыл төстә. Аны ыргытырга һәм тотарга була. Ул уйнар өчен кирәк.)*

– Билгеләрен атый. *(Кызыл, резинадан ясалган.)*

– Аерым сүзләр әйтә, ләкин алардан җөмлә төземи.

**3. “Уенчык эт турында хикәя уйлап чыгар” күнегүе**

– Хикәя уйлап чыгара.

– Сыйфатларын һәм хәрәкәтләрен атый.

– 2–3 сүз әйтә.

**4. “Хикәя төзе” күнегүе**

Тәрбияче балага “Мин ничек уйныйм”, “Минем гаиләм”, “Минем дусларым” дигән темаларның берсенә хикәя төзергә тәкъдим итә.

– Хикәяне мөстәкыйль төзи.

– Зурлар ярдәме белән сөйли.

– Сорауларга бер сүз белән җавап бирә.

**5. “Эчтәлеген сөйлә” күнегүе**

Тәрбияче кыска хикәя яки әкият укый һәм аның эчтәлеген сөйләргә тәкъдим итә.

– Эчтәлекне мөстәкыйль сөйли.

– Тәрбияче әйтеп җибәргән сүзләрне кулланып сөйли.

– Аерым сүзләр әйтә.

## Диагностика үткәрүгә аңлатма

Биремнәрне бәяләү баллар белән күрсәтелә:

– баланың дөрес, төгәл, мөстәкыйль җаваплары өчен 3 балл куела;

– тәрбияченең этәргеч сораулары буенча җавап биргән һәм зур булмаган төгәлсезлекләр җибәргән балага 2 балл куела;

– баланың җаваплары зурлар биргән сорауга туры килмәсә, сүзләрне тәрбияче артыннан кабатласа, сорауны аңламаганын күрсәтсә, 1 балл куела.

Тикшерү ахырында балларны санау үткәрелә:

– әгәр күпчелек җаваплар 3 баллга тиң булса (2–3 тән күбрәк), бу – югары дәрәҗә;

– әгәр яртысыннан күбрәге 2 балл булса, бу – уртача дәрәҗә;

– әгәр 1 баллы җаваплар күп икән, бу – уртачадан түбән дәрәҗә.

**Эчтәлекне үзләштерү дәрәҗәләре:**

**Югары** – сөйләм осталыгына ия; әкиятләр, хикәяләр уйлап чыгарганда, инициатива, мөстәкыйльлек күрсәтә (хикәянең структурасы турында күзаллаулары бар), башкаларның хикәяләрен кабатламый, сәнгатьлелекнең төрле чараларын куллана; эчтәлек сөйләгәндә, башы, уртасы, ахыры кебек текстның структур өлешләрен төгәл саклап, текст эчтәлеген эзлекле итеп бирә; сүзлек запасы бай; сөйләме сәнгатьле, грамматик яктан дөрес.

**Уртача** – үзе уйлап чыгарганда, хикәяне тасвирлаганда, әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, төшереп калдырулар урын алып тора, логик хаталар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә ул аларны үзе төзәтә; бик актив булмаса да, сөйләмдә аралашуга кызыксынуы бар; җөмлә төзегәндә кыенлыкларга очрамый, грамматик хаталар сирәк була; сөйләмнең сәнгатьлелеге җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

**Түбән** – эчтәлек сөйләгәндә, бәйләнешләр урнаштыруда кыенлыклар кичерү сәбәпле, мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча хаталар җибәрә, сөйләү барышында тәрбияче ярдәменә мохтаҗ; үзе әкиятләр, хикәяләр, кызыклы хәлләр турында сөйләгәндә, тасвирламалар төзегәндә, структур өлешләрне төшереп калдыра, мөстәкыйльлеге дә җитәрлек түгел (иптәшләренең хикәяләрен кабатлый); сүзлек запасы ярлы; грамматик хаталар җибәрә; сөйләме сәнгатьле түгел.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. *Агнабаева, Ф. Г.* Гөлбостан: Балалар бакчасында телләр үстерү өчен методик кулланма / Ф.Г. Агнабаева, Г. Р. Елкыбаева, А. З. Нарынбаева, М. Р. Харисова, Р. И. Әминева. – Өфе: Китап, 2010. – 416 б.

2. *Алексеева, М. М.* Методика развития речи и обучения родному языку дошкольников / М. М. Алексеева, В. И. Яшина. – М., 2000. – 400 с.

3. *Алексеева, М. М.* Речевое развитие дошкольников / М. М. Алексеева, В. И. Яшина. – М., 1998.

4. *Алешина, Н. В.* Ознакомление дошкольников с окружающим и социальной действительностью. Младшая группа. Конспект занятий. – Изд. 4-е. / Н. В. Алешина. – М.: УЦ. ПЕРСПЕКТИВА, 2008. – 96 с.

5. *Арушанова, А.Г.* Речь и речевое общение детей. Развитие диалогического общения: Методическое пособие для воспитателей. – Изд. 2-е испр. и доп. / А. Г. Арушанова – М.: Мозаика-Синтез, 2005. – 128 с.

6. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / төз.: К. В. Закирова, Р. А. Борһанова. – Казан: Хәтер, 2000.

7. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / төз. К. В. Закирова. – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б.

8. *Бородич, А. М.* Развитие речи дошкольников / А.М.Бородич. – М., 1969.

9. *Вагыйзов, С. Г.* Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы / С. Г. Вагыйзов, Р. Г. Вәлитова. – Казан: Мәгариф, 2001.

10. *Венгер, Л. А.* Восприятие и обучение / Л. А.Венгер. – М., 1969.

11. *Виноградова, Н. Ф.* Умственное воспитание детей в процессе ознакомления с природой / Н. Ф.Виноградова. – М., 1982.

12. *Выготский, Л. С.* Мышление и речь /Л. С.Выготский. Соч., т. 2 – М., 1973.

13. *Гвоздев, А. Н.* Вопросы изучения детской речи /А. Н. Гвоздев. – М., 1961.

14. *Гербова, В. В.* Занятия по развитию речи во второй младшей группе детского сада. Планы занятий. – Изд. 2-е испр. и доп. / В. В. Гербова. – М.: Мозаика-Синтез, 2008. – 112 с.

15. *Гербова, В. В.* Развитие речи в детском саду: Программа и методические рекомендации / В. В. Гербова. – М.: Мозаика-Синтез, 2006. – 56 с.

16. Гөлбакча (Балалар бакчалары өчен хрестоматия): Балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

17. Диагностика уровней освоения программы: вторая младшая и средняя группы / авт.-сост. Н. Б. Вершинина. – Волгоград: Учитель, 2010. – С. 5–23; 76–84.

18. *Давыдов, В.В.* Проблемы развивающего обучения / В.В.Давыдов. – М., 1988.

19. *Дыбина, О.В.*Ознакомление с предметным и социальным окружением. Система работы в средней группе детского сада / О. В. Дыбина – М.: Мозаика-синтез, 2012. – 96 с.

20. *Затулина, Г. Я.* Конспекты комплексных занятий по развитию речи (вторая младшая группа): Учебное пособие / Г. Я. Затулина. – М.: Центр педагогического образования, 2009. – 144 с.

21. *Зубарева, Н. М.* Дети и изобразительное искусство / Н. М. Зубарева. – М., 1968.

22. *Козлова, С. А.* Дошкольная педагогика / С. А. Козлова, Т. А. Куликова. – М., 2005.

23. *Короткова, Э. П.* Обучение рассказыванию в детском саду / Э. П. Короткова. – М., 1982.

24. Кроха: метод. рекомендации к программе воспитания и развития детей раннего возраста в условиях дошкольного учреждений / Г. Г. Григорьева, Н. П.

Кочетова, Д. В. Сергеева и др. – М.: Просвещение, 2007. – 207 с.

25. *Лифиц, Е.А.* Развитие речи, движения и мелкой моторики. Комплексные занятия: Практическое пособие / Е. А. Лифиц, И. В. Лифиц. – М.: Айрис-Пресс, 2010. – 160 с.

26. *Лурия, А. Р.* Речь и мышление / А. Р. Лурия. – М., 1976.

27. *Люблинская, А. А.* Воспитателю о развитии ребенка / А. А.Люблинская. – М., 1972.

28. *Мелик-Пашаев, А.* Общение и речь: развитие речи у детей в общении со взрослыми / А. Мелик-Пашаев, З. Новлянская. – М., 1985.

29. Методические рекомендации к «Программе воспитания и обучения в детском саду» //сост. Л. В. Русскова. – М., 1986.

30. Модели комплексно-интегрированных занятий с детьми 1,5–7 лет / сост.: С.С. Дреер, А. М. Потыкан. – Волгоград: Учитель, 2011. – 137 с.

31. *Мөбәракшина, Р.М.* Балалар бакчасында җырлар, уеннар: Методик кулланма / Р. М. Мөбәракшина, В. К. Вәлиева. – Яр Чаллы, 1997. – 68 б.

32. *Мухина, В. С.* Детская психология / В.С.Мухина. – М., 1985.

33. *Немов, Р. С.* Психология / Р. С. Немов. – М., 1995.

34. От рождения до школы: Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования / под ред. Н. Е. Вераксы, Т. С. Комаровой, М. А. Васильевой. – М.: Мозаика-Синтез, 2010. – 304 с.

35. *Пиаже, Ж.* Речь и мышление ребенка / Ж. Пиаже. – М., 1978

36. *Поддьяков, Н. Н.* Мышление дошкольника / Н. Н. Поддьяков. – М., 1977.

37. Развитие речи дошкольников // под ред. Ф. А. Сохина – М., 1984.

38. Развитие речи детей 3–5 лет. – Изд. 2-е, перераб. и доп. / под ред. О. С. Ушаковой. – М.: ТЦ Сфера, 2012. – 192 с.

39. Развитие связной речи детей: образовательные ситуации и занятия. Средняя группа / авт.-сост. О. Н. Иванищина, Е. А. Румянцева. – Волгоград: Учитель, 2013. – 239 с.

40. Раушан көзге (Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия): Педагогия училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 1993. – 255 б.

41. *Родари Джанни*. Грамматика фантазии. Введение в искусство придумывания историй / Дж.Родари. пер. с итал. – М., 1978.

42. *Рубинштейн, С. Л.* К психологии речи / С. Л. Рубинштейн // Проблемы общей психологии. – М., 1973.

43. *Рубинштейн, С.Л.* Основы общей психологии. – Т. 1 / С. Л. Рубинштейн. – М., 1989.

44. *Смирнова, Е. А.* Использование наглядности в формировании повествовательной речи дошкольников / Е. А. Смирнова, О. С. Ушакова // Развитие речи детей и обучении языку. Тезисы выступлений на научном совещании. – М., 1989.

45. Содержание и методы умственного воспитания дошкольников // под ред. Н.Н. Поддьякова. – М., 1980.

46. Социально-эмоциональное развитие детей 3–7 лет: совместная деятельность, развивающие занятия / авт.-сост. Т. Д. Пашкевич. – Волгоград: Учитель, 2012. – 123 с.

47. *Стародубова, Н.А.* Теория и методика развития речи дошкольников / Н. А. Стародубова. – М.: Изд. центр «Академия», 2006. – 256 с.

48. *Сухомлинский, В. А.* Йөрәгемне балаларга бирәм / В.А.Сухомлинский. – Казан: Татар. Кит. нәшр., 1976.

49. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

50. *Тихеева, Е. И.* Развитие речи детей (раннего и дошкольного возраста) / Е. И. Тихеева. – М., 1981.

51. *Тумакова, Г. А.* Ознакомление дошкольника со звучащим словом / Г. А. Тумакова. – М., 1981. – 128 с.

52. *Ушакова, О. С.* Методика развития речи детей дошкольного возраста: Учеб. метод. пособие для воспитателей ДОУ / О. С. Ушакова, Е. М. Струнина. – М.: Гуманит. изд. Центр ВЛАДОС, 2003. – 288 с.

53. *Ушинский, К. Д.* Родное слово. – Соч. Т. 2 / К. Д. Ушинский // М., Л., 1948.

54. *Федоренко, Л. П.* Методика развития речи детей дошкольного возраста / Л. П. Федоренко. – М., 1984. – 240 с.

55. *Флерина, Е. А.* Эстетическое воспитание в детском саду / Е. А. Флёрина. – М., 1961.

56. *Фонарёв, А. М.* Развитие ориентировочных реакций у детей /А.М.Фонарёв. – М., 1977.

57. *Чуковский, К. И.* От двух до пяти / К. И. Чуковский. – М., 1966

58. *Шанский, Н. М.* Лексикология современного русского языка / Н. М. Шанский. – М., 1972.

59. *Шәрәфетдинова, З. Г.* Хәзерге татар телендә иялтемнәр: Монография / З. Г. Шәрәфетдинова. – Казан: Дом печати, 2007. – 208 б.

60. *Эльконин, Д. Б.* Развитие речи детей / Д. Б. Эльконин. – М., 1958.

**ЭЧТӘЛЕК:**

**Аңлатма язуы** 3

**Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү юнәлеше буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру төрләре** 9

Танып белү өлкәсе 9

Сөйләм телен үстерү (коммуникация) өлкәсе 125

Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе 191

**Уртанчылар төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика** 241

**Кулланылган әдәбият исемлеге** 249

***Туган телдә сөйләшәбез***

***4–5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек***

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11. 09. 2013
Форматы 60x90 1/16, офсет кагазе.
Шартлы басма табагы 16,0
Тиражы 3000 д. Заказ № Т -806

“Татмедиа” ААҖ филиалы -“Идель-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексы
420066, Казан, Декабристлар ур.,2